Мәдәни җомга

КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

№6 (133)
6 февраль
1998 ел

елның июленнән
башлап чыга

Атналык гәзит

Бүгенге санда:

2 **Фоат УРАЗАЕВ.** Бүген татарның морзаларын, күренекле фикер ияләрен барлау, аларны җанландырып җибәрү — милләтебезнең киләчәге өчен үтә дә мөһим гамәлдер.

8 **Рәшит ДИВАЕВ.** Татар-башкорт җырләрен "ирекле сатып алу" милләтләрне җирсез калдырып, аларны бетерүнең яңа ысулы булып калмасмы икән?

14 **Амур ШАКИРҖАНОВ.** Озакка сузылган дәгъвалар берничә татар мәктәбе ачылуга гына кайтып калгач, халык хыялый өметләре белән саубуллашып, Русия Федерациясе Конституциясе кушканча яши башлады шикелле.

15 **Касыйм ТӘХАУ.** "Минем дулкынландыргыч картиналарда нам язылмаган әле, аларда маңгайга чиртеп әйтелмәгән фәлсәфә булырга тиеш", — ди кырыктан артык гүзәл картиналар ясаган язучы Гариф Ахунов.

Җырлап елатсаң да ярыйдыр ул, Җырлап елмайтсаң да ярыйдыр!..

Мөхәррир мөнбәре

Хакимият башлыгы һәм халык депутаты... Беренче карашка, бу ике вазифаны бер үк кешенең иңенә салу гайре табигый хәл сыман күренә. Ут белән суны үзара килештереп булмагандай, канун чыгаручы белән аны үтәүченең вәкаләтләре һичшиксез бүленергә тиешләр кебек. Һәрхәлдә, демократик илләрдә бу мәсьәлә шул рәвешле хәл кылына да бугай. Ә бездә, ни гаҗәп, ут белән суны яраштыруның да рәтен-юлын таба беләләр. Хәер, моның өчен әлләни баш ватып торасы да юк икән: Төп Канунга бер-ике сүз өстәп язасың да (әлбәттә, үз мәнфәгатеңне кайгыртып!) — шуның белән вәссәлам. Аннан соң инде, халык җырындагыча, „закун безгә нипагум" дип җырларга да ерак калмый...

Газинур МОРАТ

Мин әйттем

Кешелек дөньясы яңа гасыр бусагасын атларга җыена.

Инде тулысынча чал тарих хозурына күчеп баручы бүгенге мең еллык, белгәнебезчә, татар дигән бөек халыкның милләт буларак укмашу чорын да, дәүләтчелеген югалтып, зур фаҗигаләр кичерү чорын да үз эченә ала.

Дөнья цивилизациясенә үзеннән зур өлеш керткән бу милләтнең кояшлы көннәре караңгы төнгә әйләнүенең төп сәбәпләре нәрсәдә соң? Ни өчен зур талантларга бай, эш сөючән, түземле һәм батыр халык, үзенең әүвәлге егәрен кайтарып, бүгенгәчә мантып китә алмый? XVI йөзләрдә башланып татар халкының дәүләтчелеген бөтенләй югалтуга китергән милли торгынлык чоры ни сәбәпле бүгенгәчә дәвам итә?

Фоат УРАЗАЕВ

Татарлыкмы, әллә тарлыкмы?

Төптәнрәк карасаң, ышанычлы киләчәк өчен милли хиснең тулып, ташып чыгуы гына аз икән. Дөнья халыклары арасында үзеңә лаеклы урын яулау өчен, гавамдә бара торган глобаль процессларны дөрес аңлап, киләчәгеңнең хокукый, икътисади һәм сәяси нигезләрен дә алдан ук өзерләп кую мәслихәт икән.

Кайбер милләтләр дөнья белән идарә итүгә дәгъва кылса, шул ук вакытта әле шактый милләтләр этник "бомж"лар хәлендә кала бирәләр. Бүген дөньяда барлыгы ике меңгә якын этнос исәпләнсә, шуларның бары тик ике йөзгә якыны гына үз дәүләтләрен булдыра алганнар. Шул ук вакытта милләтләр арасында ике глобаль тенденция күзгә чалына: бер яктан, зур милләтләрнең кечкенәләрен йотуы нәтиҗәсендә этнослар саны кимесә, икенче яктан, өзерлекләре көчле булган милләтләрнең үз дәүләтләрен булдырулары нәтиҗәсендә, бәйсез дәүләтләр саны арта бара. Әлбәттә, дөнья белән идарә итүгә дәгъва кылучылар икенче тенденцияне сүлпәнләндерү һәм бөтенләй туктату өчен кулдан килгәннең барысын да эшлиләр. Шул ук вакытта беренче тенденцияне көчәйтү юнәлешендә дә искиткеч зур эш алып барыла. Чөнки алар өчен кирәгеннән артык этник һәм дәүләти "чуарлык" өстәмә мәшәкатьләр чыганагы гына булып тора.

Бүген дөнья белән идарә итүгә дәгъва кылучыларның сәясәте моңа ирешүнең фәнни (океан артындагы төрле фәнни тикшерену һәм анализлау институтлары челтәре), хокукый (кеше хокукларының милләт хокукларыннан өстенлеген раслау), икътисади (халыкара икътисади интеграция, ЕС һ.б.), финанс (халыкара финанс олигархиясе, МВФ һ.б.), хәрби (НАТОны киңәйтү) нигезләрен ныгытуга юнәлдерелгән. Бары тик дини һәм рухи каршылыкларны гына нейтральләштерәсе калып бара.

Һәр милләтнең оешканлык дәрәҗәсе, аның киләчәген билгеләүдә нинди әһәмияткә ия икәнлеген ачыграк аңлау өчен, дөньяда таралып яшәүләре ягыннан татарларга охшаш булган яһүд милләтен һәм чегәннәрне алып карыйк.

Чегәннәр бик үзенчәлекле, талантлы һәм борынгы халык. Нинди генә җил-давыллар булса да, үзләренең яшәү рәвешләрен һәм милли үзенчәлекләрен саклап кала алганнар. Аерым дәүләтләре булмаган һәм бүген дә моңа омтылмыйлар. Алыйк яһүдләрне. Алар да борынгы халык. Үзләренең оешканлыклары һәм уртак максатка буйсына белүләре ягыннан дөньяда башка мондый халыкны табуы кыен. Кайчандыр үз дәүләтләрен югалткан булсалар да, милләт буларак сакланып кала алганнар. Үз милләтләрен үстерүнең фәнни нигезгә корылган тәгълиматын булдырып һәм милләт үсеше өчен дәүләтчелекнең әһәмиятен аңлап, күп гасырлардан соң үз дәүләтләрен яңадан булдыруга ирештеләр. Кайсы гына илдә яшәмәсеннәр, бар җирдә дә хакимияткә йогынтылары бик көчле һәм уртак максатка эшли беләләр. "Бердәм һәм бүленмәс" Русия империясе җирлегендә "Православие, державность, народность" идеологиясе астында гасырлар буена формалашкан халыкның менталитетын да уртак максатка хезмәт иттерүгә ирешә алдылар. Бүгенге көндә дөньяда йогынтысы иң көчле булган милләтләрнең берсе. (Әле күптән түгел генә булып узган XXXIII Бөтендөнья яһүд конгрессының эш нәтиҗәләре моны тагын бер кат раслады).

Инде үзебезнең татарларга тукталыйк. Безнең халкыбыз да бик борынгылардан санала. Аның дөнья үсешендә тоткан урыны турында тарих пәрдәләре бүген инде бераз ачыла төште кебек. Хәер, бу зур теманы тарихчылар хөкеменә калдырып торыйк. Чөнки бу язманың төп максаты алда куелган сорауларга җавап бирүдә бит.

Мәгълүм булганча, Казан ханлыгының соңгы еллары илдә ханнарның бик еш алышынып торулары һәм, ике партиялелек барлыкка килеп, Мәскәү яклы партиянең көчәеп китүе белән үзенчәлекле.

Ни өчен соң татар морзалары дәүләтне һәлакәткә китергән бу сәбәпләрне алдан ук күрә алмаганнар? Ни өчен милләтнең киләчәге хакында төптәнрәк уйламаганнар? Күрәсең, аларга ул вакытта дөньяда бара торган глобаль процессларны аңлап бетерү җитмәгән. Шуңа күрә, үзара тарткалашулар фаҗига төсен алган, нәтиҗәдә бу татарның дәүләтчелеген югалтуга китергән, милләтне һәлакәт алдына куйган.

Милләтебезнең бүгенге халәтенә күз салсак, ни аяныч, шул ук ызгыш-талашларга һәм бүлгәләнүләргә, шул ук сукырлыкка тап булырбыз. Әйтерсең, чал тарих безне бер нәрсәгә дә өйрәтмәгән. Әллә инде үзара өзгәләшүләр һәм таркаулык халкыбызның милли үзенчәлегенә, тискәре мәгънәсендә "татарлык"ка әйләнеп барамы? Әллә бу дөньяга караш тарлыгын тудырган фикер тарлыгы нәтиҗәсе генәме?

Билгеле, мондый шартларда татарга читтән "ярдәм" итүчеләр дә аз түгел. Бүген күпертелә торган күп кенә "тәгълимат"ларның океан артында һәм Мәскәү диварларында туганлыгы да яхшы аңлашыла. Җентекләп уйланылган бу "тәгълимат"лар нигездә, милләт мәнфәгатьләрен сатып, кесә калынайтучыларга һәм сай акыллыларга исәп тотып эшләнәләр.

Бүген инде татарны бүлгәләү һәм таркатулар милләт өчен чын мәгънәсендә хәвефле төс ала башлады. Керәшеннәргә, мишәрләргә, кырым татарларына, себер татарларына һәм хәтта типтәрләргә бүлгәләүдән тыш, таркату эше милләтнең үсеше өчен мөһим булган һәр юнәлештә дә алып барыла.

Әйтик, татарның бүгенге көнгә иң абруйлы оешмасы булган II БТК тарафыннан латин имласына күчү турында карар кабул ителгән иде. Ләкин шуңа да карамастан, кайбер "акыллы баш"лар әле һаман да гарәп әлифбасына һәм хәтта руни язмага күчү турында да сүз куерталар. Шул рәвешле татарның "кирилл" хәрефләреннән арынуына комачаулыйлар. Ә бит "кирилл" хәрефләреннән арыну ул – урыс йогынтысыннан арынуга бер адым.

Милләтне рухи яктан таркату бүген бигрәк тә фаҗигале төс ала бара. Монда океан артыннан туендырыла торган төрле мәзһәбләрдән (секталардан) тыш, эш хәтта Исламны кире кагып, Милләтне тәңречелеккә өндәүгә кадәр барып җитте. Шул ук вакытта, Совет чорында диннән тәмам биздерелгән халыкны Ислам фундаментализмына чакырып, чынлыкта аны исламнан өркетүгә юнәлдерелгән гамәлләр дә юк түгел. Чөнки мондый чакыруларның милләт өчен зыяны 90нчы еллар башында халыкны "катнаш никахлардан туган балаларны юк итәргә кирәк" дигән ахмак фикер белән дәүләт бәйсезлеге идеясеннән өркетүгә тиң.

Бүген дин әһелләренең үзләре арасында бара торган ызгыш-талашлар да милләтебезнең Исламга кайтуына бер дә файда итми.

Күргәнебезчә, милләтне бүлгәләүгә юнәлдерелгән әлеге "каршылыклар", нигездә, мөстәкыйль Татарстан белән Мәскәү тарафдарлары арасындагы каршылыкка кайтып кала, ягъни Татарстанда төрле фиркаләрнең шактый булуына да карамастан, зурдан алганда, татар милләтендә шул ук ике партиялелек сакланып кала.

Тарихның ачы сабаклары безнең өчен, чыннан да, файдага булмады, ахрысы. Чөнки кайберәүләр бүген инде мөстәкыйльлекне генә түгел, гомумән, дәүләтчелекнең милләт үсешендәге әһәмиятен дә шик астына куялар. Нәрсә бу – ахмаклыкмы, әллә шаһгаличелекме? Милләтнең ышанычлы киләчәген булдыруда дәүләтчелекнең әһәмиятен аңлау өчен шул ук яһүдләр тәҗрибәсенә күз салу да җитә. Дөрес, дәүләтчелекне булдыру өчен, милләтнең дә моңа өзерлекле һәм көчле булуы мәслихәт.

Аңлашыла ки, татар милләтенең ышанычлы киләчәген булдыруда төп йөкне Татарстан дәүләте (татар халкының бүгенге көндәге бердәнбер дәүләтчелек формасы) тартырга тиеш. Ләкин моның өчен аның үзенең дә хокукый, икътисади һәм финанс нигезләрен ныгыту, рухи һәм фәнни потенциалын күтәрү кирәк. Бүгенге геосәясәт, Русиянең үзендә бара торган икътисади һ.б. процесслар, чиктән тыш зур территориянең энергоресурсларны куллану өчен нәтиҗәле булмавы, империянең киләчәктә берничә өлешкә бүлгәләнәчәгенә шик калдырмый. Ләкин бу милләтләрнең, Советлар Союзы таркалгандагы кебек, үзләреннән-үзләре ирек алуларын аңлатмый. Бары тик рухи яктан көчле һәм икътисади нигезе нык булган милләтләр генә бу бүлгәләнү вакытында үз куышларын белеп кала алачаклар. Менә шуның өчен дә, бүгенге базар мөнәсәбәтләренә күчү чорында, милләтнең икътисади һәм финанс нигезләрен булдыру, аның рухын ныгыту икеләтә әһәмияткә ия.

Хокукый нигезләргә килгәндә, бүгенге көндә парламентыбыз тарафыннан кабул ителәчәк Татарстан гражданлыгы һәм җир турындагы законнарның да әһәмияте искиткеч зур. Бу законнар һичшиксез, Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгытуга юнәлдерелгән һәм татар халкының мәнфәгатьләрен чагылдырган булырга тиешләр.

Татар халкы зур талантларга бай, һәм без бүген үзебезнең данлыклы шәхесләребез белән хаклы рәвештә горурланабыз. Ләкин алар арасында милләт язмышы өчен борчылучын мәгънәсендә милләт мәнфәгатьләрендә эшләүчеләре бик аз. Милләтебезнең интеллектуаль өлешен тәшкил итүче морзаларыбыз һәм башка зыялыларыбыз гасырлар буенча юк ителеп килгәннәр. Ләкин шуңа да карамастан, татар милләтенең киләчәген кайгырткан төпле фикерләр ишетелгәли һәм матбугат битләрендә саллы-саллы язмалар да күренгәли. Әмма эш шуннан ары китми. Шуңа күрә дә, бүген татарның морзаларын, күренекле фикер ияләрен барлау, аларны җанландырып җибәрү, милләтебезнең киләчәге өчен үтә дә мөһим гамәлдер.

Бүген Татарстан Фәннәр академиясе, аның каршында эшли торган шактый гына фәнни-тикшерену институтлары бар. Шул потенциалга таянып, татар халкының үткәненә һәм бүгенге халәтенә фәлсәфи, психологик, хокукый һәм икътисади анализ ясау мәслихәт. Шуның синтезы буларак, дөньяда бара торган глобаль тенденцияләрне исәпкә алган, милләтебез үсешенең хокукый, рухи һәм икътисади юнәлешләрен билгеләүче фәнни караш, милли тәгълиматыбызны булдыру, бүген халкыбыз алдында торган иң мөһим бурычларның берседер.

Әйе, дөнья халыклары белән бергә татар дигән бөек халык та яңа гасыр бусагасын гына түгел, ә яңа мең еллык бусагасын да атларга җыена. Үткән данлы һәм ташанлы чакларын кайтару өчен тарих аңа соңгы мөмкинлеген бирә. Үзенең фидакарь улы Дәрдмәнд бокисәткәнчә, алдагы юлын армас борын күреп, "таяк" салырга өлгерерме ул барыр юлына тәмам юлдан язмас борын?

ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР

Җидегән 5 6 7 1 2 3 4

Мөнәсәбәт

Машиналар чаба, машиналар...

Казаныбыз – тирә-яктагы иң зур калаларның берсе. Миллионнан артык халкы да бар. Шөкер, метро төзелеше дә башланып китте. Әмма пассажирлар ташкыны җир астына күчкәнче, ай-һай, озак вакытлар трамвай, троллейбус, автобус, автомобиль хезмәтеннән файдаланырга туры килер әле. Кисмәктәге килкә кебек булсаң буласың, әмма барасы җиреңә барып җитәргә кирәк, рәхмәт төшкере. Суыкта бу рәхәт тә әле. Кысыла-кысыла, бер-береңнең аягын таптый-таптый, җылынып, энергия туплап барасың.

Ә кайвакытта милиционер юлыңа аркылы төшә дә, бар транспорт, хәтта җәяүлеләр дә туктап кала. Сәбәбе дә җитди: дәүләт, хөкүмәт җитәкчеләре каядыр бара, Казанга кунаклар килә яки бай коммерсантлар уза. Хәтта КГБ, ФСБ, милиция транспортына да юл ачыла.

Күп тапкырлар Казандагы транспорт хәрәкәтенең, җитәкчеләр, кунаклар утырган автомобильләргә юл биреп, пробка-бөке хәлендә калганын күргәнем бар. Ул көтү мәлләрендә шоферларның теленнән нинди генә ачы сүзләр чыкмый да, җитәкчеләр адресына нинди генә усал сүзләр әйтелми. Ләкин бит, чынлыкта, Президентыбыз да, Премьер-министр да Казанда көнгә өч-дүрт тапкыр юл яптырып, әллә кайларга йөрмиләр. Алар эш бүлмәләрендә, Мәскәүдә мөһим мәсьәләләр хәл кылганда, башкалар, ягъни үзләрен Алланың кашка тәкәсе санаучылар юл хәрәкәтен боза-боза, кызыл утка керә-керә, чамадан тыш тизлек белән каядыр чабалар. Узган җомгада шундый хәлгә тап булдым. Сиреналар кычкыртып, алдагы машинадан: "Юл бирегез!" – дип кычкыра-кычкыра, шәһәр транспортын тулы паралич хәленә китереп, кемдер каядыр ашыга иде. Ә тизлек... Әгәр янгын сүндерү машинасы яки "Ашыгыч ярдәм" автомобиле шулай чапса, кайдадыр янгын, кемдер үлә, дип уйлар идең. Бу кешеләр кая шулай ашыга икән?! Икътисадны да, сәясәтне дә ашыгып, чабып, башкаларның юлын ябып кына хәл итү мөмкин түгел ич.

Казаныбызны сиреналар акырту шәһәре итүдән бераз чиклисе иде. Кунаклар каршы алганда да, озатканда да тыйнаклык күрсәтү кирәктер. Ярый, Борис Ельцин килгәндә юлларны да каплыйк, ди. Әмма безгә андый кунаклар көн саен килеп тормый бит. Җирле җитәкчеләргә дә, машиналарына мигалка куеп, үзләрен башкалардан өстен санаучыларга да чама белү, тыйнаклык күрү кирәктер...

Сәрмәдия СӨЛӘЙМАН.

Шаляпин бәйрәмнәре

■ Казанда бөек урыс җырчысы Федор Шаляпинның тууына 125 ел тулуга багышланган тантаналар башланды. Актерлар йортында "Безнең Шаляпин" дип исемләнгән җәмгыяви-хәйрия концерты узды. Анда Мәскәү кунаклары, аерым алганда халыкара бәйгеләр лауреаты пианист Карен Кириенко һәм Казан театрлары җырчылары катнашты. Концерттан җыелган акча бөек якташыбызның Казанда һәйкәлен төзүгә тотылачак.

■ Татарстан һәм Русия хөкүмәтләре карары нигезендә 12 гыйнвардан 12 февральгә кадәр җырчыга иң яхшы һәйкәл проекты өчен бәйге үткәрелә.

■ 5 февральдә Казанда инде гадәткә кереп киткән Шаляпин фестивале ачылды. Ул М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры сәхнәсендә үткәрелә. Фестиваль 14 февральгәчә дәвам итеп, анда Русия шәһәрләреннән, БДБ илләреннән, АКШ, Австрия, Чехия, Германия һәм Польшадан килгән иң яхшы опера җырчылары катнашачак.

■ 2562 санлы кече планетага Ф.Шаляпин исеме бирелде. Бу планетаны Русия Фәннәр академиясе хезмәткәре Людмила Журавлева ачкан иде.

Әдип бүләк өләшә

Казан укучылары Римма Гыйльматова белән Ләйсән Гыйльметдинова язучы, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Туфан Миңнуллин фонды бүләге лауреаты булдылар. Римма – 11 нче, Ләйсән 5 нче сыйныфта укый. Икесе дә Киров районының 154 нче татар мәктәп-гимназиясендә белем ала. Аларга шулай итеп татар теле һәм әдәбиятын өйрәнүдәге уңышлары өчен Гимназия көне бәйрәмендә акчалата бүләк бирелде.

Танылган драматург, матур гадәт буенча, бүләкләрне шәхсән үзе тапшырды. Моңа чаклы мондый премияне дүрт укучы алган иде.

Тансыкка бер тамаша

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә Мәскәүнең А.Чехов исемендәге Кече академия театры артистлары чыгыш ясап китте. Татарстан тамашачысы "И жизнь, и слезы, и любовь" дип исемләнгән бер күренешле спектакль-дивертисмент карап биһуш булды.

Танылган сәхнә осталары Валентин Гафт һәм Ольга Остроумова катнашкан "Нетеатральные встречи" спектаклен дә күрдек. Мәскәү актерлары Станислав Любшин һәм Алексей Жарков исә Мольерның "Тартюф"ыннан композиция тәкъдим иттеләр.

Тамашалар вакытында С.Любшин үзе белән Мәскәүнең Щепкин училищесында укыган иҗатташлары – Камал театры сәхнәсендә дан-шөһрәт казанган осталар Г.Исәнгулова, Н.Ихсанова, Р.Таҗетдинов, Ә.Шакиров, шулай ук драматург Т.Миңнуллин белән дә очрашты. Сабакташлар бер-берсен бик сагынышкан иде шул.

Гәзитләр үзәктә басылыр

Матбугат дөньясы да әкренләп яңара бара, мөһим программалар кабул ителә һәм аларны гамәлгә ашыруда төрле чаралар күрелә. Әйтик, кечкенә, һичнинди шартлары булмаган район типографияләрендә дөнья күрә торган гәзитләр киләчәктә дүрт үзәктә – Казанда, Чаллыда, Норлатта, Бөгелмәдә басылачак.

***

Буада исә ул үзәкләр оешканны көтеп тормыйча, редакциягә яңа җиһазлар, гәзит баса торган заманча техника, күчерү машинасы белән тәэмин иткәннәр. Район гәзите редакциясенә техника сатып алуда район хакимияте, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы ярдәм иткән.

Авыр көннәр

Февраль аенда ***7, 10, 16, 22, 26, 27***се көннәрендә табигать үзгәрешләр кичерә һәм геофизик хәлләр күзәтелә. Бу көннәрдә сәламәтлегегез турында кайгыртучанлык күрсәтегез, якыннарыгызга игътибарлы булыгыз.

Хөрмәтле укучылар! Татарстан Элемтә министрлыгы 1 февральдән 31 мартка кадәр 1998 елның икенче ярты еллыгы өчен гамәлдәге бәядә "Мәдәни җомга"га льготалы язылу үткәрә. Димәк, почта бүлекләренә барып, тагын 27 сум акча түләсәгез, гәзитебез сезгә ел ахырына кадәр килеп торачак. Бу хакта туганнарыгызга, күршеләрегезгә, танышларыгызга да әйтсәгез икән.

Әйткән сүз – аткан ук

Василий ЛИХАЧЕВ, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, Федерация Советы вице-спикеры:

"Республиканы бик җитди рәвештә кадрлар революциясенә әзерләргә кирәк".

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Мәгариф өлкәсендәге уңышлары өчен Татарстан Республикасы мәгариф министры урынбасары, Татар республика башлангыч һөнәри белем берләшмәсе генераль директоры **ГАФУРОВ Таһир Гафур улына,** педагогик кадрлар әзерләүдәге уңышлары өчен Казан дәүләт педагогика университетының милли мәктәптә урыс теле укыту кафедрасы доценты **МИРОШНИЧЕНКО Людмила Васильевнага "Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы"** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Радиотапшырулар өлкәсендәге уңышлары өчен "Татарстан" дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе дикторы **ИСХАКОВА Фәйрүзә Мәсхут кызына "Татарстан Республикасының атказанган артисты"** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Президенты Указы белән Татарстан Республикасының инвестиция фонды мәдәният үзәге директоры **АЛЕХИН Александр Ивановичка;** "КамАЗ" акционерлык җәмгыятенең мәдәният комплексы тынлы оркестр дирижеры **МАРЧЕНКО Виктор Константиновичка**; Мөслим районының мәдәният бүлеге мөдире **СӘХБЕТДИНОВ Илфат Садретдин улына "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре"** дигән мактаулы исем бирелде.

"Нурлы Казан"

"Казан" милли мәдәният үзәгендә рәссам Равил Заһидуллинның "Нурлы Казан" дигән вернисажы ачылды. Күргәзмәдә нәкыш, графика әсәрләре һәм шәмаилләр урын алган.

"Татар-Информ" ябылды

Татарстан Президенты М.Шәймиев Указы (1998 ел, 31 гыйнвар) нигезендә "Татар-Информ" мәгълүмат агентлыгы ябылды һәм аның вазифалары Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгына йөкләнде.

Җомгадан – җомгага

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Татарстан Премьер-министры Ф.Мөхәммәтшин Русия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе В.Черномырдин хозурында булды.

Федерация Советы Рәисе урынбасары В.Лихачев Татарстан Республикасының Санкт-Петербургтагы даими вәкиллегендә шәһәрдә яшәүче татарларның милли-мәдәни иҗтимагый оешмалары җитәкчеләре белән очрашты.

Ураза бәйрәме уңаеннан Татарстан Диния нәзарәтенә барча мөселманнарны тәбрикләп РФ Хөкүмәте вице-премьеры Р.Абдулатыйповтан, милләтара мөнәсәбәтләр министры В.Михайловтан, РФ Дәүләт Думасының милләтара мөнәсәбәтләр һәм дини конфессияләр комитеты рәисе В.Зорькальцевтан һәм Финляндиядәге Ислам җәмгыяте рәисе О.Таһирдан котлау телеграммалары килде.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында мәшһүр галим, мәгърифәтче Ш.Мәрҗанинең 180 еллыгына багышланган тантаналы кичә узды.

Мәскәүнең "Һилал" хәйрия фонды Кол Шәриф мәчетенә яңа исәп белән 5 миллион сум акча күчерде.

"Независимая газета" биш ел дәвамында (1993-1997 еллар) Русиядә иң йогынтылы егерме сәясәтченең исемнәрен игълан итеп, Татарстан Президенты М.Шәймиевнең әлеге исемлектә унөченче урынында торуын билгеләде.

Г.Тукайның Казандагы әдәби музеенда танылган рәссам Э.Зариповның "Багышлау" сериясенең шагыйрь Р.Фәйзуллинга багышланган өченче экспозициясе ачылды.

Шәһәрләрнең халыкара мирас оешмасына Казан каласы әгъза-күзәтүче буларак кабул ителде һәм шуны раслап халыкара оешманың махсус дипломы тапшырылды.

Кукмара районында якташ язучылар катнашында әдәби атналык булып узды.

Алабуга музей-тыюлыгында "Музыка культурасы тарихыннан" дигән күргәзмә ачылды.

"Мәгърифәт" газитенең баш мөхәррире итеп хәзергә кадәр "Бизнес в Татарстане" журналының баш мөхәррире булып эшләгән Х.Вәлиәхмәтов билгеләнде.

Сәхифәдә редакция журналистлары, авторларыбыз, "Татар-информ" һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

Беренче биттә – **Ә.ШАКИРҖАНОВ** фотосы.

Күп сәгать саен яңалык

Галим мөнәҗәт әйтә

Татарстанның Зур концерт залында Ураза бәйрәменә багышланган кичә үткәрелде. Кичәдә мөнәҗәтләр, бәетләр һәм тарихи җырлар яңгырады. Аларны филология фәннәре кандидаты, доцент, Казан дәүләт университетының Шәрекъ телләре кафедрасы мөдире Җәмил Зәйнуллин башкарды.

Руханилар берләшергә ниятли

Татарстанның мөселман даирәсе телгән һәм уртак мөнфәгатьләрен истә тотып, Русия һәм Аурупаның БДБ илләре мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте (аңа мөфти Тәлгат хәзрәт Таҗетдин җитәкчелек итә) вәкилләре белән Казанда очрашу булды. Нәтиҗәдә җөмһүрият мөселман руханиларын берләштерү корылтаен үткәрү өчен бердәм оештыру комитеты төзелде.

Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе мөфти Габдулла хәзрәт Галиулла белдерүенчә, Диния нәзарәте уставы нигезендә, корылтай 1998 елның 16-17 февралендә үткәрелә.

Татарстанда тагын бер кала артты

Халык депутатларының Нурлат берләштерелгән Советының чираттан тыш сессиясе булды.

Сессия Татарстан Дәүләт Советының Нурлатка республика дәрәҗәсендәге шәһәр статусы бирү, Октябрь районын Нурлат районы итеп үзгәртү турындагы карарын тикшерүгә, шуның белән бәйле рәвештә халык депутатларының берләштерелгән Советының яңа рәисен һәм Нурлат районының хакимият башлыгын сайлау мәсьәләләрен тикшерде.

Депутатлар Нурлат берләштерелгән Советы рәисе итеп район һәм шәһәр хакимияте башлыгы Фатыйх Сибагатуллинны сайлап куйды.

Чаллыда – милләтпәрвәрләр җыены

Иртәгә Чаллы шәһәре мэриясенең С.Садыйкова исемендәге Концерт залында бирердәге Татар иҗтимагый үзәгенең VI корылтае уздырыла.

Җыенда милли хәрәкәтнең үткәне, бүгенгесе, киләчәге, армия, Эчке эшләр министрлыгы, КГБ, суд, прокуратура, җир, паспорт, дин һәм милли хәрәкәт, мәгариф һ.б. мәсьәләләр карап тикшерелер, дип ният ителә. Корылтайда шулай ук халкыбызның социаль хәле, балалар һәм яшүсмерләр тормыш-көнкүреше, киләчәге хакында да җитди сөйләшү булырга тора.

Каюм бабай бүләге

Татарстан Мәгариф министрлыгы коллегиясенең чираттагы утырышы үткәрелеп, анда Каюм Насыйри исемендәге еллык бүләкне бирү буенча җәмәгать комиссиясенең тәкъдиме тикшерелде. Беренче бүләкне республиканың мәктәпкәчә учреждениеләрендә һәм мәктәпләрендә милли мәгарифне үстерүдәге уңышлары өчен Балтач районының Карадуган ясле-бакчасы коллективына; мәгариф өлкәсендә шәхси уңышлары өчен икенче бүләкне татар теле һәм әдәбияты буенча оригиналь дәреслекләр авторлары Альберт Яхин, Фирaз Харисов һәм Чулпан Харисовага бирергә дигән карар кабул ителде.

Кампитр... аракы ясый

"Татспиртпром" җитештерү берләшмәсенең Чистайдагы ликер-аракы заводында сәгатенә 12шәр мең шешә эчемлек чыгара ала торган линия файдалануга тапшырылды. Ул җитештерү куәтләрен ике мәртәбәгә арттыру мөмкинлеге бирә.

Яңартылган линия тулысынча кампитрлаштырылган. Бусы чыгарыла торган продукциянең сыйфатына контрольлек итүне күпкә яхшырта.

Кореядән килгән Будда

Рәссам һәм сынчы Илдар Хановның исемен ерак илләрдә дә беләләр һәм аның изге эшкә алынуы да бар дөньяга мәгълүм икән. Әнә, аның тынычлыкны, халыкларны бердәмлеген вә берлеген берләштергән музее өчен ерак Кореядән Будда сынын җибәргәннәр. Бу зур бүләк Татарстаныбызны тану, хөрмәтләү билгесе булып та тора.

Мөселман үзәге кирәк

Казан мөхтәсибәте һәм "Әл-Мәрҗани" җәмигъ мәчете әһелләре мөселманнар өчен үзәк булдыру кирәклеге турында хакимиятке мөрәҗәгать итеп, Кабан күле һәм Камал театры янәшәсендә ял итү, гыйбадәт кылу урыны, мөселман рестораны, мәдрәсә-академия, музей, китапханә, картлар йорты, ятим балалар өчен приют, спорт мәйданчыгы булырына ният кылалар.

Пычак кем кулында?

Элеккеге "Татлеспром" берләшмәсе генераль директоры Марс Рәмиев шул ук берләшмәнең баш хисапчысын яллап үтертүне оештыруда гаепләнә.

1994 елның 12 гыйнварында баш хисапчы Фаяз Мирзахмәтовның үле гәүдәсе үзе яши торган йорт подъездында табыла. Аңа күп тапкыр пычак белән кадаганнар.

Тикшерү органнары ул вакытта ук директорның бу "эштә" катнашы барлыгын шөбһәләгәннәр дә, шәһәр комитетының элеккеге беренче секретаре, министр вазифасында ("Татлеспром" – элеккеге Ягулык министрлыгы) һәм Казан шәһәр советы депутаты буларак, кагылгысыз кешене тоткарларга төвәккәлләмиләр. Хәзер исә Рәмиев директор да, депутат та түгел. Аның белән тагын "башкаручылар" дип уйланган, күздә тотылган дүрт кеше кулга алынды.

М.Рәмиев беренче күрсәтүләрен дә биргән. Экс-директорның әйтүенә караганда, чынлап та аның баш хисапчы белән мөнәсәбәтләре начар булган, чөнки Мирзахмәтов директорның кайбер күрсәтмәләрен үтәргә теләмәгән. Мөгаен, ул күп нәрсәләрне белгәндер...

Банк... бөлгенлеккә төште

Әле кайчан гына банкирлар арасында финанс тотрыклылыгы белән данланган Татпромстройбанк 29 гыйнвар көнне бөлгенлеккә төшү сәбәпле лицензиясез калды.

Акча санаганны ярата, дигән әйтемне бу банк әһелләре истән чыгарган, күрәсең.

"Ике урман арасы" – дәгъвачылар арасында

Кабат Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә кандидатлар күрсәтер чак җитте. Татарстан язучыларының ПЕН үзәге бьелгы бүләккә шагыйрь Зөлфәтнең (Дөлфәт Маликов) "Ике урман арасы" дигән китабын тәкъдим итте.

Газраил планын арттырып үти

1997 елның 10 аенда җөмһүриятебездә үлүчеләр саны туучылардан 7325 кешегә артып китте. Татарстан статистика дәүләт комитетыннан алынган мәгълүматларга караганда, үлем-китем дәрәҗәсе – былтыргыча, ә менә туу 1,2 процентка кимеде.

Халык аеруча йөрәк, кан тамырлары чиреннән кырыла. Шул сәбәпле вафат булучылар, былтыргыныы шул чоры белән чагыштырганда, 2,8 процентка артты. Әлеге хаста 22519 татарстанлыны алып китте.

5431 кеше яман шештән үлде, 5465е һәртөрле бәхетсезлек, имгәнү һәм агулану очрагы корбаны булды.

Әдип тагын шаккатыра

Мәскәүдәге татар мәдәни үзәгендә танылган язучы Морат Аджи белән кызыклы очрашу үткәрелде. Мәгълүмдер, бу әдип – хәзерге төрки халыкларның иң борынгы бабалары турында өч китап авторы булырак шөһрәт казанган шәхес. Аджиның "Полынь половецкого поля" дип исемләнгән романы тиз арада киң катлам укучыларның ихтирамын казанды.

Русия башкаласында уздырылган әлеге очрашуда авторның "Тайна Святого Георгия" дип аталган өченче китабын тәкъдир итү булды. Әдип әлеге әсәрендә кыпчак халкының тарихын дөрес итеп чагылдырырга кирәклеген яклап чыга.

Очрашуда Морат Аджи үз укучыларының күпләгән сорауларына җавап бирде, тарих тегермәне ташлары арасында калып сытылган, изелгән халык турында гыйбрәтле мәгълүматлар китерде.

"Иске" акчаның яңа бәясе

Аллага шөкер, яңа яуган кар кебек шыгырдап торган әр-яңа унлыкны да кулга алырга насыйп булды. Аны күргәч, күңелем йомшарып китте. Ул миңа күптәнге танышымны – иске акчаны хәтерләтте. И-и рәхәт иде ул әлек: кая гына кермә – дәүләт куйган бер үк бәяләр. Трамвай билеты өч тиен, телефон-автомат – ике тиен, шырпы кабы – бер тиен. Эх, бар иде заманалар. Әле дә менә, яңа-иске акчаны кулга алу белән хыялга бирелеп киттем. Әммә, нишлисең, акча алышынды дип кенә ычкынган бәяләр кире үз кысасына кайтмады, отыры котырды. Әнә, күрше абзый 73 (мең) сумга бер савыт җилем алып кайткан. Килешү-килешү дигән булалар. Минә инде 10 елдан артык базарда яшим, белмим, кем белән кем килешедер. Миннән әле берәүнең дә, килешәсеңме, дип сораганы юк. Хәер, хезмәт хакын да килешү буенча бирсәләр, эчне төртеп тишмәс иде.

ӘЛФИР.

Карета яңарырга Мәскәүгә китә

Екатерина Икенченең данлыклы каретасын – Казан музееның иң кыйммәтле экспонатларының берсен – Мәскәүгә Корал палатасына алып китәләр, диләр. Бу хакмы?

С.МОРТАЗИНА.
Казан.

Кызганыч, карета дөрестән дә, Русия башкаласына китә, тагын да аянычы – каретаны кисәкләргә бүлеп озаталар. Җитмәсә, бу бәяләп бетергесез кадерле экспонат артыннан башкалага берничә йөз мең миллион акча җибәрергә дә ниятлиләр. Дөрес, бу очракта әлеге эш бар байлыкны республикалардан, төбәкләрдән үзенә суырырга гадәтләнгән үзәк куышы буенча башкарылмый. 200 ел тирәсе әлек ясалган каретаны күптән инде сиплөп алырга вакыт. Мәскәү белгечләре шушы эшне үзләре башкармакчы. Билгеле инде, акчаны Казан түли. Яшәртелгән экспонатны, тиешле эшләре тәгәлләнгәч, Корал палатасында калдырмаска, туган якларына кайтарырга вәгъдә итәләр.

Китап тоткынлыктан котылды

Узган ел ахырында Айдар Хәлимнең нииндидер яңа китабы тирәсендә шаушу күтәргәннәр иде. Аның язмышы ничек булып бетте соң? Әгәр бу китап сатуга чыкса, аны кайдан табарга мөмкин?

Ф.СИБГАТУЛЛИН.

Сүз А.Хәлимнең "Убить империю!" дигән китабы турында бара. Нәшриятта ук кулга алынган һәм дүрт ай буена дөньяга чыгарылмыйча тотылган әлеге басма Казанда нибары өч урында – Бауман урамындагы 1 нче китап кибетендә, Гвардия урамындагы "Военторг" кибетендә һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры киоскында сатыла.

Әзиләр кабат җыела

Күпсанлы тамашачыларның соравы буенча, 17 февральдә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры "Мишәрләрем – нани, канәт, әзиләрем" исемле концерт программасын тәкъдим итә. Әлеге концертта мишәрләр яшәгән төбәкләрдә туып-үскән, бүген профессиональ сәхнәдә танылган драма артистлары, җырчылар Хәйдәр Бигичев, Рафаэль Ильясов, Ринат Таҗетдинов, Исламия Мәхмүтова, Наил Шәйхетдинов, Рузия Мотыйгуллина, Рәшит Шамкай, Мөнир Якупов, Ания Туишева, Искәндәр Бикташиров, Рамил Төхфәтуллин, Халисә Шәрәпова, Кәүсәрия Сиражетдинова, Резидә Төхфәтуллина, Әсхәт Хисмәтов, Харис Төхфәтуллов, Рөстәм Вәлиев, Илдар Кыямов, Фәйрүзә Сибгатуллина, Ренат Вәлиев һ.б. катнаша.

Концерт 18 сәгать 30 минутта башлана.

ШОРНЫЕ ИЗДЕЛИЯ

Хомут, узда, вожжи, седелка горбатая, подпруга, чересседельник, ленты, тесьма, шнуры.

Адрес: г.Чебоксары, ул.Калинина,68 ОАО"Лента" Код (8352), тел.23-25-30. Тел/факс 23-48-46, 23-29-40.

8 февральдә Г.Камал театры бинасында Арыслан Мөбәрәков исемендәге Сибай башкорт дәүләт драма театры гастрольләре башлана. Театрыбызның Казанга беренче килүе 1987 елны булды. Ул шулай ук Татарстан районнарында да әледән-әле чыгышлар ясап торды.

Сибай театрының гаҗәеп бай тарихы бар. Аның оешуына быел 68 ел тулачак. Сибай театры бүген Башкортстанның иң алдынгы театрларыннан берсе. Театрның үзенә генә хас үзенчәлеге дә бар: ул – башкорт халкының мәдәниятен чагылдыручы, саклаучы һәм үстерүче. Төрле халыклар белән мәдәни бәйләнеш учагы буларак та аның башкарган эшләре бихисап.

Сибай театры сәхнәсендә бик күп сәхнә йолдызлары үзләренең иҗат юлын башлады. СССРның халык артисты, театрның беренче сәнгать җитәкчесе Арыслан Мөбәрәков, данлыклы җырчы, Башкортстанның һәм Русиянең халык артисты Мәгафур Хисмәтуллин, мәшһүр курайчы, актер, Башкортстанның халык, Русиянең атказанган артисты Ишмулла Дилмөхәммәтов һәм башкалар Сибай театры елъязмасында җуелмас эз калдырды. Талантлы режиссер-

Башкортстандагы унҗиде театрның ундүрте ябыла, ә Баймак колхоз-совхоз театры үзенең эшчәнлеген туктатмый. Зур җитмәүчелек һәм матди кыенлыкларга карамастан, халыкны рухи ныклыкка, җиңүгә дәртләндерүче героик характердагы спектакльләр сәхнәләштерелә. Су-

дә, тугандаш халыклар драматурглары әсәрләрен дә, дөнья классикасы үрнәкләрен дә кыю рәвештә сәхнәләштерә килә. Сибай театры сәхнәләштергән әсәрләрнең жанрлар төрлелегендә, югары зәвыклы һәм проблемалы булуында бигрәк тә тугандаш татар халкының Ш.Камал, М.Фәйзи, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, Н.Исәнбәт, Т.Миңнуллин, И.Юзеев,

курай" драматик легендасы "Колончык" исемле балалар һәм үсмерләр өчен спектакльләрнең I республика фестивалендә җиңүче булды, "Кодача" музыкаль комедиясе (З.Исмәгыйлев, Б.Бикбай) Мәскәү каласында узган Башкортстан көннәрендә данлыклы Е.Вахтангов исемендәге театрда башкала тамашачыларының кайнар алкышларын яулады. Сәлихьян Әфләтунов сәхнәләштерүендә Н.Гогольнең "Өйләнү", А.Островскийның "Банкрот" әсәрләре, бүгенге көн әсәрләреннән Г.Әхмәткуҗинаның "Абыстай" психологик драмасы югары профессиональ кимәлдә сәхнәләштерүләре белән уңай бәяләнде. Вәкил Йосыповның "Уйламый сөйләсәң..." (С.Лобозеров), "Каһәрле мәхәббәт" (Ф.Бүләков), "Мәхәббәт турында җыр" (Ә.Атнабаев) кебек спектакльләр тамашачыга үзләренең тормышчан булулары белән якын.

Монннан тыш, Русиянең атказанган артисты Олег Ханов сәхнәләштергән "Башмагым" музыкаль комедиясенең бүгенге көн версиясе, Русиянең халык артисты Рифкать Исрафилов куйган "Дон Жуан" (Ж.Б.-Мольер) комедиясе – театрның йөзен билгеләрдәй, аның

Унбер елдан соң очрашу

лар, сәхнә осталары Гыйният Ушанов, Кадыйр Бакиров, Сәхи Сәетов, Гайфулла Сарбаев, Фәтхелислам Галәүтдинов, Рафаэль Әюпов, Лек Вәлиев Сибай театры сәхнәсендә югары кимәлдәге әсәрләр сәхнәләштереп, башкорт театр сәнгатенең ныклы нигезен булдырдылар һәм аның үсешенә зур көч куйдылар.

1935 елда Баймак колхоз-совхоз театры (хәзерге Сибай театры) Мәскәү каласында үткән Бөтенрусия колхоз-совхоз театрлары смотрында А.Таһировның "Алатау", Д.Юлтыйның "Карагол" спектакльләрен күрсәтеп, 2 нче урынны яулый.

Бөек Ватан сугышы елларында

гыш азагында һәм аннан соңгы елларда Баймак колхоз-совхоз театрының тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итүче атаклы сәхнә осталары Сәхи Сәетов, Гайфулла Сарбаев, Зәкирьян Ханов, Шәмсенур Сираҗетдинова, Каюм Хөсәенов, Гәшия Абзгильдина, Биби Мәһәҗиева, Җәмилә Әбитаева, Гәшүрә Ирназарова, Хәмзә Курсаев, Кифая Хәбибуллина һәм башкаларның хезмәте бәяләп бетергесез.

Бүгенге көндә Мөбәрәков исемендәге Сибай башкорт дәүләт драма театры Башкортстанның иң уңышлы эшләп килгән театрларыннан берсе. Ел саен репертуар яңа әсәрләр белән байый бара. Иҗат коллективы үз милли сәхнә әсәрләрен

Р.Хәмид кебек күренекле әдипләренең иҗаты бик зур әһәмияткә ия. Бүген дә бу иҗади бәйләнеш өзелми.

Хәзерге көндә театрның иҗади йөзен билгеләүдә Дамир Галимов, Башкортстанның атказанган артисты Сәлихьян Әфләтунов, Башкортстанның халык артисты Вәкил Йосыпов кебек режиссерлар күп көч куя. Дамир Галимов сәхнәләштерүендә Ф.Бүләковның "Сөясеңме – сөймисеңме?" трагикомедиясе, "Кызлар ни өчен елый?" мелодрамасы, Н.Гаетбаевның "Төн" трагедиясе һ.б. күп кенә спектакльләр театр тәнкыйтьчеләре, тамашачылар тарафыннан югары бәя алды, ә узган елда З.Биишеваның "Тылсымлы

сулышын, профессиональ көчкуәтен күзаллардай спектакльләр бүгенге репертуарда мөһим урынны били.

Сибай театры гастрольләре 15 февральдә бөтен иҗат көчләре катнашындагы зур концерт белән тәмамланачак.

Без Казан тамашачысы белән кабат очрашуыбызга бик шат. Аларга илһам, шатлык, ял минутлары теләп, үзебезнең тамашаларга көтеп калабыз.

Рәгыйдә ИСТӘКОВА,
Сибай башкорт дәүләт
драма театрының
әдәби бүлек мөдире.

Долли сарыгы – коммунизм хыялы

Мәгълүм булганча, коммунизм өр-яңа идеология сеңдергән кешеләргә нигезләнеп төзелә. Дөньяда коммунизм төзүченең әхлак нормаларына җавап бирә торган (ул дини әхлактан урланган) идеаль җәмгыять төзелгәч, рәхәтләнеп яшәргә мөмкин булыр иде. Бу турыда Маркска чаклы яшәгән социал-утопистлар да хыялланган. Кешене өр-яңадан тәрбияләү (хәтта аерым бер илдә) мөмкин булмавына тәмам инангач, дөнья пролетариаты юлбашчысы Ленин, үз "алласы" Маркс идеяләренең дөрескә чыкмавыннан гаҗиз калгач, авырып җан тәслим кыла.

Аның каравы, Сталинның бу идеяне тормышка ашыруда ярты юлда туктап каласы килми. Ленинның бөтен дөньяга мәгълүм булган "без башка юлдан китәрбез" гыйбарәсен шигарь итеп, ул СССР халыкларын концлагерьларда тәрбияли башлый. Прәннектән битәр камчыга күнеккән Русия халкына Сталинның каты кулы хуш килә, һәм алар аны бар халыкларның атасы дип атыйлар. Төрмә тоткыннарының түләүсез хезмәтен файдаланып, бөек коммунизм төзелешләре башлана, соцгородлар төзелә. Кеше тәрбияләүдә "Ядрә теләсә нинди әхлактан өстен" дигән шигарь белән алып барылган үз ысулының өстенлекләренә ышанган Сталин зур ышаныч белән, мин әле коммунизм чорында да яшәячәкмен, ди. Сталин аеруча вөҗдансызлык белән күбрәк кеше үтергән саен, халык аны ныграк ярата, ә бу инде аңа, Ленинннан аермалы буларак, үлгәндә коммунизмнан җаны бизмичә һәм вөҗдан газабы кичермичә җан бирергә ярдәм итә.

Ул вакытларда инде партия Үзәк Комитетында, Политбюрода кешеләрне тәрбияләп үзгәртү мөмкин түгеллегенә, монда төрмә дә, көчләп сәяси укытулар да нәтиҗәсез икәнлегенә тәмам ышанган сәясәтчеләр өлгереп җитә. Бүрене бүреккә салсаң да урманга карый шул, геннарны үзгәртү кыен. Хәтта коммунизм идеалларында тәрбияләнгән кешеләрдән дә каннарына

буржуйлык сеңгән балалар туа. Коммунизм кешесен тәрбияләү өчен генетика
фәнен белергә кирәк. Ә аңа Сталин үз
вакытында "ялган фән" дигән мөһер сук-
кан иде. Сталинның наданлыгы аңа ком-
мунизмда яшәү мөмкинлеге бирмәде. Әгәр
ул Мәскәүгә, Судоплатов үтереп мактаган
атом серләрен кайтартмыйча, "Оксфорд
бишлеге" супер-шпионнары аркылы Шот-
ландия генетиклары хезмәтләрен кайтарт-
кан булса, Долли сарыгы үзебездә –
Мәскәүдә китереп чыгарылган булыр иде.
Ләкин Русия хакимиятенә Долли сарыкла-
ры түгел, шул сарыклар кебек аңгы-
райтылган ышанычлы коммунистлар гына
кирәк. Мәсәлән, Шотландия генетиклары-
на берничә миллион Черненколарны клон-
лаштыру, ягъни пачкалап тудыру берни
түгел! Хәер, Сталинның үзен дә, Долли
сарыгы кебек, миллионлап чыгарырга бу-
ла. Сталин геннарыннан торган 10 милли-
он игезәк чыгарылса – дөньякүләм ком-

мунизмны эһ дигәнче төзеп була! Алар исә, бернинди водород бомбасы кулланмыйча, Американы сырты белән каплап куя алачаклар. Бүгенге Дәүләт Думасы – клонлаштыру өчен тәҗрибә питомнигы гына, монда һәр депутат – коеп куйган чын коммунист бугай. Әле аның иң мөһиме шунда: мондый игезәкләрне миллионлап тудырыр өчен күкәй күзәнәкләре дә кирәк түгел – һәркайсы депутатның теләсә нинди җиреннән бер чеметем тәнен кисеп аласың... һәм – булачак игезәкләр өчен бихисап геннар әзер!

Сталин (кешелек бәхетенә!) геннар серенә үз вакытында төшенеп җитми калды, әмма аннан соң эшләгән яшерен совет лабораторияләре, шиксез, бу проблема буенча армый-талмый эшләгәндер. Кем белә, бәлки, бездә Долли сарыгы серләре генә түгел, "перестройка" вакытында ябып, яшереп куелган һәм вакыты җиткәч дөньяны хәйран калдырачак искитмәле нәрсәләр дә бардыр әле! Чөнки Русиядәге кайбер яшерен объектларны соңгы 10 ел эчендә үзгәртәбез дип бармак та селкетмәделәр. Янәсе, бу алдынгы технологияне җимерү илгә хыянәт итү белән бер. Шуңа күрә, нәрсәдер үзгәрткәнче, алар Сталин портретын кочаклап, рельсларга ятарга әзер. Кем белә, галимнәребез бәлки шул яшерен серләрне ачмас өчен Нобель бүләгеннән дә коры калганнардыр. Тагын бер 10 елдан соң, әйтте диярсез, геннар инженериясе буенча ясалган ачышларыбыз дөньяга танылa алмый калды, дип зарланачаклар...

Локман ЗАКИР.

Фуат МАНСУРОВ:

Музыканы аңлаган кеше вәхши дә, залим да була алмый

Татарстанның һәм Казакъстанның халык артисты, Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, профессор Фуат Шакир улы МАНСУРОВка 70 яшь тулды.

– Фуат Шакирович, безнең гәзит яңа гына чыга башлаган яшь басма әле. Моңа кадәр "Мәдәни җомга" битләрендә күренгәнегез дә булмады. Шуңа күрә Сезнең турыда укучыбызга тәфсилләбрәк мәгълүмат бирергә кирәк дип саныйм. Сезнең күңелегезгә музыка ничек килеп керде, кайчаннан бирле яши ул анда?

– Мин Алматы шәһәрендә, гап-гади хезмәткәр гаиләсендә туганмын. Кечкенәдән математикага сәләтле булганмын, шахмат уенына оста идем. Әнием театрда эшли, аның янына барып, барлык хезмәткәрләрен шахмат уенында отып кайта идем.

Гаиләбездә музыка белән бернинди бәйләнеш юк. Бүтән гаиләләрдәге кебек, "Зәңгәр шәл"ләр, "Зиләйлүк"ләр, башка халык җырлары җырлангандыр инде...

Математикага, музыкага, телләргә сәләтем барлыгын берәүнең дә белми калуы да ихтимал булган, чөнки...

Ишегалдыбыздагы бер фатирга отставкага чыккан офицер күчеп килде. Озакламый бу үлеп тә китте. Ашказанында рак булган, диделәр. Балалык уем белән аның ашказанына рак (кысла була инде ягъни!) кергән дә шул ашап үтергән дип күз алдына китергән идем.

Офицерның хатыны – Расторгуева Татьяна Николаевна – тол калды. Ул күп телләр белә, музыкага үтә дә һәвәс кеше иде. Аларның граммофоннары, бик күп пластинкалары бар иде. Теге чакларда бу – сирәк очрый торган хәл. Мин, 3-4 яшьлек бала, шул граммофон тавышын сихерләнеп тыңлаганмын, шуны тыңлый-тыңлый аларның тәрәзә буенда үсә торган хуш исле ясмин куаклары арасында йокыга китә торган булганмын. Тора-бара, юкка чыксам, шуннан гына эзләп ала торган булганнар. Шул чакларда тыңланган Ференц Листның "Венгр рапсодияләре", Карл Веберның "Танецка чакыру" әсәре, Джакомо Мейерберның "Пәйгамбәр" операсыннан Маршы бүген дә колагымда яңгырап тора. Бу әсәрләрнең исемнәрен, авторларын мин соңыннан гына белдем, әлбәттә.

Бүтән уен белән мавыккан малайларның шул музыканы тыңламауларын мин сабый башым белән һич кенә дә аңлый алмый идем.

– Музыкаль белем алуыгыз ничек башланды?

– Әлбәттә, Татьяна Николаевна минем музыкага тартылуыма игътибар итми калмаган. Ул мине, әтиемнән сорап, балалыкка алмакчы булган. Әмма, тормышы авыр, үзе авыру булса да, әтием моңа ризалык бирмәгән. Шуңа карамастан, мине тәрбия итүгә Татьяна Николаевна күп көч куйган. Биш яшемдә ул мине музыка мәктәбенә биргән. Сәләтең булса, әлек бит теләсә ничә яшьтән алганнар. Мәктәптә музыка коралларыннан виолончель генә булганлыктан, мине виолончельдә уйнарга өйрәткәннәр.

– Укыган чактагы кайбер эпизодлар исегездә калмаганмы?

– Музыкадан беренче укытучым Отто Оттович Узинг дигән немец иде. Бер уйнаганда нотаны ноктасына хәтле тотып җиткерә алмадым. Шуның өчен укытучым җәза бирде. Яңадан укырга бармыйм, дип, күз яшьләремне агызып, өйгә кайтып кердем. Әнием, Татьяна Николаевна бар бит әле, ул ничек әйтсә, шулай булыр, дип, мине аның янына алып керде. Татьяна Николаевна исә әйтте: Отто Оттович юкка рәнҗетә торган кеше түгел, үзең кирәгенчә уйнамагансыңдыр, диде. Музыкада бер нәрсәгә дә вак-төяк эш итеп карарга ярамый, дип тә өстәде. Аннары ул миңа Никколо Паганини турында сөйләде. Әтисе аны, әйбәт уйнасын, дип, сәгатьләр буена өстеннән бикләп куя торган булган. Людвиг ван Бетховенның да әтисе шәфкатьле булмаган: малаеның осталыгы нәтиҗәсендә җыелган акчаны эчеп бетерә торган булган...

Бервакыт, инде танылган дирижер булгач, чит илдә, немец дусларның оркестрына дирижерлык иткәндә, аларга шушыларны сөйләдем һәм:

– Сез, Людвиг ван Бетховен, Иоһанн Себастьян Бах кебек мәңге үлмәс композиторларның ватандашлары, шушылай шапшак уйнарга ничек оялмыйсыз? – дидем.

– Сезнең белән уйнавы үтә дә авыр, колагыгыз искиткеч сак, юк кына төгәлсезлекне дә ишетәсез, үткәреп җибәрмисез, – дип акланды алар. Әйе шул, музыкада һәр нотаның үз урыны бар, ул чама белән түгел, ә нәкъ менә үзе яңгырыйсы урында яңгырарга тиеш, дип өйрәттеләр мине.

– Фуат Шакирович, телләргә сәләтем, дидегез. Шунда берочтан спортка мөнәсәбәтегез хакында да әйтсәгез иде, альпинист та дип ишетә беләм мин сезне?

– Татьяна Николаевна мине бик кечкенәдән француз теленә өйрәтә башлады. Китапны чит телләрдә бик иртә укый башладым. Хәзер, татарчадан тыш, инглиз, француз, итальян, испан, төрек, казакъ телләрендә иркен сөйләшәм. Немец телендә докладлар сөйлим. Миңа еш кына чит илләрдә гастрольләрдә булырга, чит оркестрларга дирижерлык итәргә туры килә. Мондый хәлдә тәрҗемәче аша эшләү бик кыен; һәр халыкның үз телендә аңлашырга-сөйләшергә кирәк була.

Менә шунда инде мин, күп еллардан соң, беренче укытучым Татьяна Николаевнаны чиксез рәхмәт хисләре белән искә алам.

Спортка мөнәсәбәтме? Минемчә, кеше гомере буена үзен төрле яклап тәрбияләргә, чыныктырырга, камилләштерергә тиеш.

Бу урында Фуат Мансуровның 70 яшьлек юбилее уңаеннан Русиянең халык артисты Владимир Андропов язган мәкаләдән түбәндәге юлларны китерәсе килә: "За плечами его университет, далее – с отличием оконченная консерватория, где его имя занесено на Золотую доску лучших выпускников, он дважды мастер спорта СССР, покоритель трех семитысячников и неоднократный чемпион по конькам, теннису и шахматам, он удостоен Золотой медали на YII Всемирном фестивале молодежи и студентов в Москве".

– Кешене формалаштыру, калыпка салу еллары – чынлыкта балачак бит...

– Мәктәптә мин яхшы укыдым. Ләкин үҗәтләнеп, бөтен фәннәрдән дә бишле алырга тырышмадым. Әйткәнемчә, көчле шахматчы идем. Математикадан олимпиадаларда җиңеп килдем. Әтием музыкант булуымны теләмәде, һәм ул аны һөнәргә дә санамады. Математика буенча укуымны теләде. Һич югында милиционер (!) булырсың, диде. Әтиемнең теләгенә каршы килмәдем: Алматы университетының математика бүлегенә укырга кердем. Бер үк вакытта консерваториядә белем алдым. Әтием генә укып бетергәнемне күрә алмыйча үлеп китте.

Университетны тәмамлагач, мине Персидский дигән атаклы математика профессоры үз кафедрасында калдырды. Фәнни эш белән шөгыльләндем. Анда да уңышка ирештем. Ләкин барыбер музыка җиңде.

– Фуат Шакирович, сез бит инде консерваторияне тәмамлаганчы ук казакъ халык музыка кораллары оркестрына дирижерлык иткәнсез...

– Әйе, нәкъ шулай булды.

– Соңрак дирижерларның Бөтенсоюз конкурсында лауреат булдыгыз.

Жюри члены, атаклы дирижер Борис Хайкин "Советская культура" гәзитендә бу турыда менә ни дип язган иде: "... Из всех лауреатов Мансуров наиболее гармонично сложившаяся творческая личность, он одинаково силен во всем, очень требователен и настойчив, в то же время в нем привлекает располагающее спокойствие, что само по себе является признаком мастерства".

"Кирилл Кондрашин рассказывает" дигән китапта (ул да мәшһүр дирижер) автор Д.Шостакович белән очрашуын сурәтли; шушы конкурста Максим Шостаковичның үз мөмкинлекләреннән беркадәр түбәнрәк чыгыш ясавын акларга тырыша, ләкин һәрвакыт объектив булган Дмитрий Дмитриевич аңа каршы килә: "... Я с Вами не согласен, только Мансуров сильнее Максима. Из всех тех, кто там участвовал, он гораздо сильнее", ди.

Һәм сез 1969 елдан бирле Русиянең Зур театрында дирижерлык итәсез...

– Шул ук вакытта 1986 елның февраленә кадәр Мәскәү консерваториясендә дә укыттым.

Мәскәү консерваториясендә укытканда Ф.Мансуров 15 ел дәвамында студентлар оркестрына дирижерлык итә. 1971 елда әлеге оркестр яшьләр оркестрларының Г.Караян исемендәге Халыкара конкурсында беренче урынны яулап ала һәм Алтын медальгә лаек була.

– 1986 елдан соң Татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестрына җитәкчелек итә башладым.

– Һәм хәзер Казанда төпләнеп тә алгансыз икән – күрәм, фатирыгыз әйбәт булган. Әле берничә ел элек очрашканда без сезнең белән кунакханәдә сөйләшеп утырган идек бит.

– Ю-у-ук, Саимә ханым, бу минем фатир түгел, бу да – кунак өе. Мин килсәм – мин яшим монда, мин киткәч – бүтән кеше яши.

– Телефоннан сөйләшкәндә өйгә килегез, дигәч, мин инде фатир мәсьәләгез хәл ителгән икән, дип сөенгән идем. Ничек инде ул, ун еллар буена кунакханәдә... кеше ишек төбендә, дигәндәй?..

Бу хәлне ишеткәч бик күңелем төште. Шушындый кешегә карата үзебездәге мөнәсәбәткә аптырадым. Бу ОСТАНЫ Аллаһы тәгалә үзе чыгарып куйган лабаса юлыбызга. Нигә шуның кадерен белмәскә! Белүемчә, аның аяк басмаган иле юк. Аны эшкә чакырмаган ил, кыйтга юк. Кияү үзебезнеке, дигән сыман, үпкәләмәс әле, дип, ишек төбенә генә утырткач, ашарына да җитәрҗитмәс кенә биргәч, көннәрдән бер көнне бу хәлләрдән туеп, хурлаулардан сабырлыгы төкәнеп, ул мондагы эшен ташлап китмәсме, дигән шом керде күңелгә. Мин бик тә пошаманга калдым.

София Гобәйдуллиналарны һәм башкаларны (яза башласаң озынга китә) сыйдырмаганбыз бит үзебездә... Нишләп соң без юньле кешеләребезнең кадерен белмибез икән?! Шушы уйларымнан әсәрләнеп, мин аннан:

– Сезне монда ни тарта соң, Фуат Шакирович, ник килдегез Сез монда? – дип сорадым.

– Йөрәк түремдә яткан сизем-тоем чакыра мине, кан тарта. Монда тумасам да, канымда бер көч бар, шул тарта!

– Сез безнең оркестрны чит илгә дә алып чыга башлагансыз. Анда нинди музыка башкарасыз?

– Мин җитди музыка башкарам. Классик музыканың эчтәлеге дә җитди була. Гомумән, җитди музыка мәгънәсез, эчтәлексез була алмый. Китап укырга өйрәнгән кебек, музыканы да тыңларга өйрәнергә кирәк. Һәр мәдәниятле кеше классик музыканы белергә, аны яратырга, тыңларга тиеш. Борынгы греклар, мәсәлән, фәлән кеше шулхәтле культурасыз, ул хәтта йөзә дә белми, дия торган булганнар. Ә инде шигъриятне, музыканы алар махсус өйрәнгәннәр.

Пушкин поэмаларын бүлеге-бүлеге белән, Тукай, Такташ шигырьләрен күпләп яттан белүчеләр бар бит, андый кешеләрнең сөйләшүен тыңлау да күңелле... Музыка да кешене сафландыра, затлыландыра. Музыканы белгән, аңлаган кеше, минемчә, вәхши дә,залим да була алмый.

– Ә бездә симфонияне тыңларга язучы халкы да, хәтта композиторлар да бик ашкынып тормый... Тыңлаучыны тәрбияләү мәсьәләсенә ничек карыйсыз?

– Иртәгә залга килергә тиешле кешене тәрбияләү бик мөһим эш. Бу – төп мәсьәләләрнең берсе. Балалар филармониясе оештырырга кирәк...

– Безнең үзебезнең музыкабыз ни дәрәҗәдә? Аны читкә алып чыгарлыкмы?

– Мин инде дөньядагы бөтен классиканы уйнап бетердем. Ә безнең халыкның музыка мәдәнияте хакында читтә дөрес фикер юк. Анда безне "тартар" дип атыйлар, сезнең үзегезнең музыкагыз бармы соң, диләр. Минем төп максат – оркестрны бик югары дәрәҗәгә җиткерү, аннары шушы оркестр ярдәмендә татар музыка мәдәниятен Җир йөзенә тарату. Хәзер безгә Сәйдәшевтән башлап, Җиһанов, Мозаффаров, Фәйзи, Ключарев, Мәлеков, Бакиров, алардан соң килә торган Яхин, Әхмәтов, Еникеев кебек композиторларның әсәрләрен Аурупага тыңлатырга, анда музыкабыз мәдәнияте хакында дөрес фикер тудырырга кирәк.

– Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры белән мөнәсәбәтегез ничек?

– 1968 елда килеп, мин анда "Травиата", "Алтынчәч", "Җәлил" кебек спектакльләрне куйдым. Ә хәзер бер-беребезне кирәксенмибез... "Алтынчәч" дөнья классикасыннан, әйтик, "Снегурочка"лардан бер дә ким түгел. Менә шуны күрсәтергә кирәк чит илдә. Икенче бөтен дөнья татар конгрессында да шуны кирәк иде күрсәтергә: читтән килгән милләттәшләребезгә татар музыкаль мәдәнияте турында азмы-күпме фикер туар иде...

– Ә безнең опера театрыбыз чит илгә һаман шул "Богема"ны өстери... Һаман урыс театры булып кала бирә...

Йәгез алайса, бер дога, дигәндәй, Фуат Шакирович, Сезне гәзитебезнең барлык укучылары исеменнән олуг бәйрәмегез белән кайнар котлыйбыз, изге ниятләрегездән барысының да тормышка ашуын чын күңелдән телибез.

Әңгәмәне **Саимә ИБРАҺИМОВА** үткәрде.

Халык һәрчак яктылыкка баккан. Тәрәзәләрен дә кояшлы якка каратып уйган. Өмет һәм ышаныч яктылыгына да карадыр. Бәлки шуңа да тәрәзәләр турында шигырь-җырлар туадыр. "Төшермим тәрәзәм пәрдәсен!" — дип яза бер шигырендә Гакыйл Сәгыйров. Шатланып-очынып, өметләнеп-куанып укып йөргәндә, үсмер чагында авырып китеп гарип кала ул. Операциядән соң инде урынга ятарга туры килә. Хәтта утырып та тора алмый. Тәрәзә янындагы караватында яткан хәлдә, дөньяның яктылыгын-караңгылыгын күрә.

Үсмер чактан гарип калу. Әмма шул хәлдә дә яшәү мәгънәсен җуймау, яктылыкка багу. Кешенең рухи көчен раслау, шуңа бүтәннәрне дә ышандыра белү үзе бер батырлык, үзе бер каһарманлык!

Гакыйл Сәгыйров кулына каләм тота алмый. Әмма ул, каләмне тешләренә кысып, рәсемнәр ясый, шигырьләр яза. Ничә еллар буена шулай... Иҗат тәрәзәсенең, күңел тәрәзәсенең пәрдәләрен япмый-төшерми ул.

Бу көннәрдә ул яшәгән якка — Самара өлкәсенең Кошка районы Иске Фәйзулла авылына котлау һәм соклану хатлары ява: Гакыйл Сәгыйровка алтмыш яшь тулды! Без дә сине тәбриклибез, иҗатыңа һәм рухи көчеңә сокланабыз, каләмдәш!

Гакыйл СӘГЫЙРОВ:

"Төшермим тәрәзәм пәрдәсен!.."

Безнең гомер

... Җаным белән сизеп торам яшәү гамен,
Күңелем белән күреп торам яшәү ямен.
Әй, камчылыйм үз-үземне — яшәүдә мин! —
Сүнәм-сүнәм диеп тора гомер шәмем.
Безгә кадер җирдә булган чиксез үлек...
Һәм безне дә китәр үлем тиздән өзеп.
Оҗмахта да, тәмугта да урын җитмәс —
Кая барасың, кешелек, мәет тезеп?..

Без үлгәч тә, йөз ел үтәр, мең ел үтәр,
Вакыт машинасы, ялсыз, җебен сүтәр.
Җирдә туар яңа уйлы яңа Җаннар,
Яңа дәвер йолдызлары кабынып янар.
Һәм, өйрәнеп без яшәгән гасырларны,
Баш чайкарлар — булмаган, дип, акыллары:
Яшәгәннәр ахмакларча үлә-үлә,
Кеп-кечкенә шушы Җирне бүлә-бүлә!..

... Безнең өчен чиксез авыр газап булып,
Җәберләнгән бар нәрсәдән азат булып,
Күз салганда безгә ерак биеклектән,
Гаҗәптер шул гөнаһ тулы безнең йөкләр...
Тик барыбер Шатлык калыр шатлык булып,
Үлем йөрер ак сакаллы картлык булып.
Авыз итми калмас алар чын шәрабтән:
Без калдырган Кайгы, Сагыш, Мәхәббәттән.

... Имән орлыгыннан үсә мәгърур Имән:
Тамыры — тирән, ә түбәсе күккә тигән.
Тик Ул гына гасырларны буйлый ала,
Давылларга каршы торып уйный ала.
Заманалар юлын барлап узам кебек...
Безнең гомер — юлдагы бер тузан кебек...
... Сискәндереп, карт имәнгә яшен сукты —
Күтәлмәгән гәрселдәүдән котым чыкты.

Сәрби әби

... Ике тәрәз арасында ялгыз чебен
Куырылып каткан — өзгән гомер җебен.
— Бәбкәләрем, калмады шул берегез дә,
Җәй көнендә нигә инде тидем сезгә?

Йоклап ята карты әнә — ак сакаллы...
Искә төште егет чагы — аулак өйдә
Ну бии дә иде яңа чабатаның
Чаткыларын чәчрәтеп любой көйгә.

... Ямау тәмам. Җәйнең җебен өзәргә дип
Авызына күтәргән кул кире төште.
Кеткел-кеткел көлдә карчык: яшь чакмыни,
Ничек өзсен — авызында ике теше.

... Җәй буена оныкларын кунак итте,
Ике кызчык "Әлхам"ны өйрәнеп китте.
Искә төшкән саен шушы тиктормаслар,
Карчык йөзен куанычлы сагыш баса...

Төнге юл

... Ризыгың булса, саулыгың,
Дусларың булса — җитә:
Шатлыклы көннәр эчендә
Гомер сизелми үтә.

Ач булсаң, ялангач булсаң,
Җитмәсә — бер ялгызың:
Хәсрәтле шомлык эчендә
Төнге юл бигрәк озын.

Сириннәр

Г.гә

Сириннәрем иртүк уянганнар,
Мин кайтканны өлгә тоймаганнар.
Быел язда мине көтә-көтә,
Чәчәк атып, чәчәк койганнар.

Сириннәрнең яшел яфрагында
Җем-җем килә көмеш саф чыклар.
Кая калды икән төннәр буе
Сине озатып йөргән яшь чаклар.

Сириннәргә кунган сандугачның
Өзелеп тыңлыйм моңлы тавышын.
Белә микән өлгә мәхәббәтнең
Миңа язган кайгы-сагышын.

Өзмәсәм дә сирин чәчәкләрен,
Табар идем чәчәк бүләккә.
Мин, күрмәсәм сине, яши алмыйм,
Күрсәм дә бик кыен йөрәккә.

Пар күгәрчен

Кияүгә киткән кызыннан
Әнисе сорый икән:
— Тату яшисезме? Кияү
Җәберләмиме, бәбкәм?
Әнисенең соравына
Кыз җавап биргән көлеп:
— Гөрләшәбез генә, әнкәй,
Пар күгәрченнәр кебек.
Тәрәзәдән бик еш йә — мин,
Йә — киявең очып чыга.
Аннан икәү йөгерәбез
Пыяла куючыга!..

"Карт — прав!.."

... Ике кайгы
минем башымда:
берсе — хатын,
берсе — машина.

... "Жигули" сатып алдым,
Бик хөтәр эшкә тардым:
Бу "матур"ны җайлый-майлый,

Автор рәсеме.

Өйдә бик сирәк булам,
Ансын-монсын карый-карый,
Янында хәтта кунам.
Кая барып килсәм дә,
Янә чистартам-юам;
Ялтыратып сөртәм дә
Урнына кертеп куям.
Тотмас идем пәхтәләп,
Бик кадерле җанымга:
Төште минем җилкәмә
Утыз мильон ярымга!

... Бермәлне курше карты
Яныма килеп басты.
Сынап карап торды да
Болай дип авыз ачты:
— Монысы бетсә, син тагын
Алырсың яхшырагын.
Ә хатын... берне алабыз
Без гомерлеккә диеп.
Син бит аның тирәсендә
Йөрмисең болай биеп.
Әгәр шулай карасаң,
Иркәләсәң-назласаң,
Матураер гына иде,
Бар сафлыгын күрсәтеп.
Картайгач та, гел яшь калып,
Яшәр иде нур чәчеп!!!

... Сүзсез калдым аптырап:
Нәрсә әйтим? Карт — прав!

"Пәйгамбәр"

(Агай-эне авызыннан)

... Кызык та бу тормыш: көннәр буе
Диңгезенә төшеп кайныйсың;
Әллә ниләр эшләп кыланасың,
Әллә кемнәр җаен җайлыйсың.

Пәйгамбәр күк хис итсәң гүя,
Бөтен дөнья серен аңлыйсың, —
Куенында яткан хатыныңның
Ни уйлавын белә алмыйсың...

Кичке юлда

Һәр Матурлык —
Үзенә бер могҗиза ул...
... Кояш батты... Офык өстендәге
Болытларга кинәт ут капты —
Дөрли алар...
Хәтерләтеп имән утыннан
Калган күмерләрә гөжләп торган,
Эссе бөргән гигант учакны.
Мин туктадым, төштем машинадан,
Күпме юлда йөреп, күпме яшәп,
Күргәнем юк иде шәфәкъләрнең
Матур булганлыгын бу чаклы!..

... Килеп җиттем... Тоныкланып калган —
Күк йолдызлар белән чуарланган;
Соклануым бетми һаман,
Кытыклады минем җанны.

— Мин дә кызыгып карап тордым аны,
Иллә шәп иде берге! — диде хуҗам. —
Шундый минутларда тула күңел:
Син — ни рәссам, ни сүрәтче түгел;
Ник кенә яшисең, тинтәк? — диеп,
Үз-үземне шулчак тиргәп куям.

Йөз чакрым ара...
Ике йөрәк
Бер гүзәллек белән сихерләнгән.
И, Табигать, сөю-яшәү өчен
Илһам алды бүген күпме бәндәң!..

шигырь ... нечкәлек билгесе белән языла

Тамаша заллары чакыра

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры

8-15 февраль – Башкортстанның Сибай театры гастрольләре.
8-15 февраль – "Йөрәк маем" (Т.Миңнуллин), "Күрәзәче" (Зөлфәт), Артист-шоу, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт төбәкләрендә гастрольләр.

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры

6-7 февраль – Юморина. Студентлар өчен КВН.
8 февраль (көндез) – "Алтын алма" (Ш.Фәрхетдин).
8 февраль (кич) – "Җаным җөл түгел сиңа" (Г.Зәйнашева).

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры

5 февральдән Ф.И.Шаляпин исемендәге фестиваль.
5 февраль – "Пиковая дама" (П.Чайковский).
6 февраль – "Царская невеста" (Р.Корсаков).
7 февраль – "Севильский цирюльник" (Д.Россини).
8 февраль – "Тоска" (Дж.Пуччини).
9 февраль – "Князь Игорь" (А.Бородин).
10 февраль – "Реквием" (Д.Верди).
11 февраль – "Травиата" (Д.Верди).
12 февраль – "Богема" (Дж.Пуччини).
13 февраль – "Борис Годунов" (М.Мусоргский).
14 февраль – Гала-концерт.

Цирк

6-13 февраль – Зур Мәскәү циркы йолдызлары тамаша күрсәтә.

Татар яшьләр театры

6 февраль – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), 103 нче мәктәп, 401 нче балалар бакчасы.
7 февраль – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), Осиноводагы татар гимназиясе.
7 февраль – "Әй, син исәнме!" (Г.Мамлин), Осиноводагы татар гимназиясе.
10 февраль – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), 132 нче мәктәп.
11 февраль – "Мисс убырлы" (Ф.Галиев), 247 нче балалар бакчасы, 383 нче балалар бакчасы.
11 февраль – "Шаушулы көн" (В.Розов), "Казан" санаторие.
12 февраль – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), 4 нче гимназия.
13 февраль – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), 106 нчы мәктәп.
13 февраль – "Керпе малае дуслар эзли" (Р.Корбан), 72 нче мәктәп.

Зур концерт залы

7 февраль – Вокаль музыка кичәләре. Урыс романслары. Башкаралар Р.Аббасов, Н.Варшавская, Г.Антонов, Л.Маслова, Г.Ибушев, С.Кадыйрова, Н.Сөгыйрова.
14 февраль – Татарстан дәүләт симфоник оркестры концерты. Программада В.Моцарт, Р.Шуман, С.Барбер, О.Ресниги әсәрләре. Солистка – Мариам Джива Женье (Австрия). Дирижер – Т.Камалов.

Курчак театры

6 февраль – "Глаза змеи" (И.Зиннуров).
7 февраль – "Кот, петух и лиса" (А.Янкелевич).
8 февраль – "Кот в сапогах" (Ш.Перро).
13 февраль – "Аистенок и пугало" (Б.Лопеска).

Караш

ҖИРСЕЗ милләт булырмы?

Мин пенсия яшендә булсам да үзебезнең Башкортстанда чыга торган матбугатка язылганда, Казанда чыга торган басмаларны – гәзит-журналларны алдырып укып барырга күнегеп киттем. Бигрәк тә "Мәдәни җомга", "Юлдаш" гәзитләрен, "Казан утлары" журналын күптән укып барам. Шуларны укыганда Татарстан җитәкчелегенең республикадагы авыл хуҗалыгы җирләрен "ирекле сатуга" риза булганлыгы ачыкланды. Сездә ничектер, моңа безнең Башкортстанда яшәүче башкорт-татар халкы битараф калмады, күпләр гаҗәпләнде, чөнки Татарстанда бу мәсьәлә тормышка ашырыла башласа, ул Башкортстанны да читләтеп үтмәячәк дияргә кала. Болай да Башкортсан белән Татарстанның ике тугандаш республика буларак якын мөнәсәбәттә яшәве, күпмедер дәрәҗәдә суверенлык яулавы күп кенә урысларның, Мәскәү чиновникларының эчен пошыра. Алар бу ике республиканың сәяси, икътисади, мәдәни үсешенә бик үк риза түгелләр. Әгәр халкыбызның борын-борыннан килгән төп байлыгын, туендыручысын сатарга ирек куйсак, урыс байлары, чит ил коммерсантлары татар-башкорт җирләрен һич чирканмый сатып алып бетерәчәкләр, Татарстан һәм Башкортстанның уңдырышлы сөрүлек җирләре, табигый байлыклары, урман-суларына тулы хуҗа булып, татар-башкорт халкын үзләренең батраклары, коллары дәрәҗәсендә калдырырга, күпләрен яшәгән җирләреннән куарга да күп сорамаячаклар. Мин уйлыйм, моны татар халкы яхшы аңларга тиеш. Ярый, безгә, олы яшьтәге кешеләргә, алар китерәчәк михнәтләрне күрергә туры килмәс. Әмма шушы төбәктә туып-үскән яшьләребез – милләтебезнең киләчәге нишләр икән?! Урысларның бер вакытта да татар-башкорт халкын кызганмаячагы, шовинистларның аларны җир йөзеннән юкка чыгару уе белән янулары тарихта яхшы мәгълүм. Бу исә татар-башкорт "ирекле сатып алу" юлы җирләрен һәм башкортларны белән, татарларны милләтен бетерүнең җирсез калдырып, миллләтен бетерүнең яңа ысулы булып калмасмы икән? Шулай булачак та. Ныклап урыслаштыруга да китерәчәк. Хәзер безгә җирләребезне сатып яшәргә кала, башкача чара калмаган булып чыга түгелме соң?

"Җире юкның, теле юкның – милләте дә, дәүләте дә юк", дигән мәкальне дә онытмаска иде бит әле.

Әгәр алдагы чорда, авыл хуҗалыгы җирләре мәсьәләсендә шундый карарга киленсә, хөрмәтле Исхак Лотфуллин әфәнденең "Мәдәни җомга"ның 47 нче санында басылып чыккан язмасындагы ("Козгын каркылдаса, хәвеф була") вакыйгаларның хәзер үзебездә туачагы көн кебек ачык. Бу очракта козгын каркылдап кына калмас, милләтне чукып, ашап бетерәчәк. Мондый очракта милләтебезне, телебезне үстерүнең, Бөтендөнья татар конгрессы үткәрүнең, латин алфавитына күчү, мәдәниятебезне үстерү турында сөйләшүләрнең нинди мәгънәсе кала?

Ни өчен без шуңа барып җитәргә уйлыйбыз соң әле? Безнең татар-башкорт халкының икмәк үстереп яшәрлек сәләте калмаган дияр идек, Татарстан авыл хезмәтчәннәре үз басуларының һәр гектарыннан 37 центнердан артык икмәк үстереп, ил амбарларына миллионлаган тонна икмәк тапшырдылар. Безнең Башкортстан игенчеләре дә авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүдә әлегәчә күрелмәгән, тирә-яктагы барлык өлкәләрдәгедән югарырак уңыш алды.

Шулай булгач, бездә бу яктан хафаланырлык урын юк дип уйлыйм. Хәзерге көндә авыл хуҗалыгы тармакларына үги караш яшәп килүе, аның икътисади ягын күтәрүгә әһәмият бирелмәү генә күңелләрне борчый. Авыл хуҗалыгы продуктларын сату бәяләре чагыштырмача түбән дәрәҗәдә. Өстәвенә, икмәк һәм башка төр продуктлар сатканга акчаны вакытында ала алмыйлар. Кайчак акча урынына вексельләр генә бирәләр, ә аларга берни алып булмый. Малчылык продуктлары сатудан да хуҗалык кассаларына акча керми, күп өлеше салымнар түләүгә китеп бетә. Эшләүчеләргә эш хакы бирерлек тә калмый. Промышленность тауарларының бәясе артык югары. Авыл хуҗалыгындагы җир эшкәртү техникасы артык кыйммәт булганлыктан искергән техниканы яңага алыштыру өчен хуҗалыкларның көче җитми. Аерым хуҗалык, фермер комбайн-трактор сатып ала алыр дип күз алдына китерүе дә кыен. Шуның өчен дә авылдагы хуҗалыкларны, минемчә, җирләрне ирекле сату юлы белән түгел, ә коллектив, кооператив хуҗалыкларга тапшырып, аларга дәүләт ярдәме күрсәтеп, авылны өстенлекле үстерү ысулларын кулланып авылны аякка бастыру кирәктер. Сәнәгатьне бер яклап үстерә барып, игенчелекне җимерә бару – ил халкын ач калдыру ул. Безнең ике тугандаш республикада да сәнәгать предприятиеләре җитәрлек. Шул заводларда аерым цехлар ачып, ике республика килешү юлы белән – җир эшкәртү техникасын да арзанлы итеп җитештерү мөмкин булыр иде.

Рәшит ДИВАЕВ.
Башкортстан.

Мөнәсәбәт

Шытымнар сулмасын

Аллаһыга шөкер, соңгы елларда моңарчы хыялларда гына йөрткән үзгәрешләр дә күренә башлады. Шуларның иң сөендергәне балаларны ана телебездә, татар телендә укытудыр. Шәһәрдә саф татар гаиләсендә туып-үскән балалар да үз телен белми иде бит. Бу коры, тапталган сүзләр генә түгел, бу – олы тарихлы бөтен бер халыкның кара фаҗигасе. "Яшь ленинчы" гәзитендә эшләгәндә бу фаҗига белән без көн саен диярлек очрашып тордык. Шагыйрьләр, язучылар, журналистлар Казан мәктәпләренә барабыз. Укучыларга шигырь укыйсы, әдәбиятыбыз, телебез, әдипләребез турында сөйлисе... Тик, мәктәпнең ишегә төбенә җиткәч, туктап, авыр сулыйбыз. Чарасызлык йөзләргә чыккан.

Әйе, үз телендә әни дип тә әйтә белмәгән дәвамыбызга ничекләр итеп шигъри сүзнең төмен, ләззәтен, Тукай, Туфан шигъриятенең бөеклеген, ана телебезнең байлыгын төшендерәсе? Инде менә андый авыр сораулы көннәр дә артта калды шикелле. Шәһәр мәктәпләрендәге татар теле укытучылары да шактый җиңел сулыш алды. Мәктәпләрнең җитәкчелеге, укытучылар коллективы алар белән дә исәпләшә башлады. Димәк ки, татар телен таный башларга мәҗбүр булдылар. Сөенечле хәл бит! Шушы куаныч эчендә аерым бер сөенеч бар. Ул да булса, хәтта катнаш никахлы гаиләләрнең дә шактые балаларын татар гимназияләрендә, татар мәктәпләрендә укыта. Димәк, "боз кузгалды". Хәзер инде үсеп килүче шушы яшь буынга милләтебезнең рухи байлыгын бирү, аларны милли гореф-гадәтләребез үрнәгендә тәрбияләү генә кала. Шушы урында катлаулы бер сорау туа: милли рухта тәрбия кылу өчен бездәге мөмкинлекләр ни дәрәҗәдәрәк соң? Русиядә яшәүче татарларның саны урыслардан кала икенче урында булуын искәртеп, татарча телевидение, радио тапшыруларының вакытын күз алдына китерик. Чагыштырсаң, диңгездән бер тамчы бит! Мәскәү тапшыруларының төрлелеген, байлыгын, киңлеген карагыз да Татарстан тапшыруларына күз салыгыз. Кычкырып еларлык. Әмма бу күренеш безнең республикада талантлар булмавыннан түгел, ә бәлки аларның хезмәтенә игътибар булмаудан!

Татар язучыларының әсәрләрен дөньяга чыгару мәсьәләсенә килсәк тә, уфтанырга гына кала. Татарстанда берденбер әдәби журнал – "Казан утлары". Ә, әйе, "Аргамак"та бар икән бит әле... Ә урыс телендә чыга торган әдәби журналларны саный китсәңме?.. "Новый мир", "Дружба народов", "Знамя", "Иностранная литература", "Сибирские огни", "Октябрь"... тагын әллә ниндиләр. Кыскасы, өлкә саен бер калын журнал.

Татар китапларын чыгарырга акча булмау турында әйтеп тә, язып та ардык бугай инде. Нәшрияттагы китаплар бишәр-алтышар ел буе чират көтеп ятсалар да, барыбер, дөнья күрә алмыйлар. Татар язучысына, аның хезмәтенә бездәге карашны шушы хәл үзе үк күрсәтеп тора. Татар китабы чыкмаса да, шәһәр китапсыз түгел. Чат саен саталар китапны. Тышлыклары шундый матур: калын, ялтырап тора, рәсемле, күзеңнең явын ала. Эчтәлеге – секс, үтереш, талау, көчләү... Бүгенге яшь укучы шушы китапларны укып үсә. Шәһәрдәгеләр генә түгел, китап укудан бизмәгән авыл яшьләре дә шушы темалар белән мавыга. Бигайбә, өстәлгә ни куелса шуны ашыйлар, дияргә генә кала. Нишләсеннәр соң: авыл китапханәләрендә моннан егерме-утыз ел элек кайтартылган Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, М.Җәлил, Л.Толстой, В.Маяковскийларның таушалып, сүсәрләнеп беткән китапларыннан башка яңа китаплар юк диярлек.

Җитмешенче еллар уртасында, Таллиннга баргач, китап кибетләрендә йөргән идем. Анда күргән манзаралар һаман күз алдымда. Кайсы гына китап кибетенә кермә – затлы кәгазьләргә зәвыклы итеп бизәлгән эстонча китаплар. Үз язучыларының әсәрләре, дөнья классикасы эстон телендә. Соклanудан сүз әйтә алмый торуым хәтердә. Урысча басылган китаплар да бар. Алары күп түгел, бер генә бүлектә.

Бу юлларны укыгач, авыз читен чалшайтып елмаеп куючылар да табылыр. Алар бит союздаш республика иде, диярсез. Ул кадерсен мин дә беләм. Кайсын Кулиев, Давыт Көгелтдинов, Рәсүл Гамзатов, Олжас Сөләймановлар иҗаты урыс дөньясын шаулатканда безнең Һади Такташ, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиевләрнең шигъриятен урыс укучысы күпме белә ине? Чөнки, автономияле республика язучыларының Мәскәү рөхсәтеннән башка томнар чыгарырга һич кенә дә хокукы юк иде. Югыйсә, бу шагыйрьләрнең шигърияте – дөнья классикасына тиң шигърият!

Һәркемгә дә таныш булган бу мескенлекне бүген тагын нигә кабатлыйм соң? Кабатларга мәҗбүрмен. Әдәбиятның бүгенге хәле ул чордагыдан күпкә мескен хәзер. Хокук та бар шикелле. Милли әдәбиятыңны, сәнгатеңне, мәдәниятеңне үстерү өчен Мәскәүдән рөхсәт тә алмыйбыз кебек. Әмма... Әллә инде бу өлкәдә Мәскәү килеп безгә ярдәм итәр дип көтәбезме? Югыйсә, мөстәкыйльлеккә омтылган Татарстанның берденбер үз байлыгы (ул аның рухи байлыгы!) – теле, әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте ләбаса! Шушы байлыкларга гына ул чын мәгънәсендә үзе хуҗа! Татарстан үз рухи байлыгын үзе үстермәгәч, аны кем үстерер?

Татар әдәбиятын, сәнгатен, мәдәниятен үстерү турында сүз кузгалдымы... тиз туктаталар. Акча юк, замана авыр... Тагын әллә ничә төрле сылтау. Казанны урап алган өчәр-дүртәр катлы коттеджларга күз салсаң, заманалар авыр, акча җитмиише сүзләрне әйтерлек тә түгел. Төзесеннәр, мин һич тә кешенең яхшы яшәвенә каршы түгел. Әмма монда бер "тик" бар: бездәге хәләл хезмәт хакына андый коттеджлар төзеп буламы соң?

Менә шушы тигезсезлекне күреп, чит илнең очсызлы әдәбиятын укып, көчләү белән дыңгычлап тутырылган киноларны карап безнең киләчәгебез үсә.

Сүземнең башында әйтелгән үзгәрешләр әле шытым хәлендә генә. Ул шытымнарның туфрагын ашлап, кирәк чакта суын сибеп, кояш нурлары белән җылытып үстерәсе иде. Корымасыннар, сулмасыннар, шаулап үссеннәр иде ул матур шытымнар. Җылы туфракта үссеннәр иде.

Сәйдә ЗЫЯ.

Исеме ил йөрәгендә

Яңа, 1998 ел башы Татарстан сынлы сәнгатенә бик зур шатлык китерде: җөмһүриятебез тарихында беренче мәртәбә Татарстанның һәм СССРның халык рәссамы, Татарстан, РФ һәм СССРның дәүләт бүләкләре иясе Харис Габдрахман улы Якупов Русия Сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайланды. Бу вакыйга шәхсән аның иҗатын зурлау белән бергә гомумән татар сынлы сәнгатенең югары үсеш алганлыгын да тагын бер кат раслау булды.

• "Габдулла Тукай (шагыйрь истәлегенә)". 1986.

Дөресен әйтик, дистә еллар дәвамында мондый югары исемнәргә фәкать Мәскәү һәм Ленинград (Санкт-Петербург) рәссамнары гына ирешә алды, ә инде периферия саналган Урал, Кавказ, Идел буе һәм Ерак Көнчыгыш төбәкләре һаман онытыла килде. Югыйсә, анда да бит иҗатлары киң танылган мәшһүр рәссамнар бар иде. Ни аяныч, Харис ага белән дә нәкъ менә шулай килеп чыкты. Гәрчә аның әсәрләре бүгенге көндә Мәскәүнең Третьяков галереясында һәм Шәрекъ халыклары сәнгате Дәүләт музеенда, Татарстанның күп кенә музей һәм галереяларында, алай гына да түгел, ерак чит илләрдә, мәсәлән, АКШ, Бөекбритания, Франция, Италия, КНДРда саклանса да.

Әйе, бүгенге көндә ул танылган Оста. Ул 25 ел дәвамында (1951-1975) Татарстан рәссамнар берлеге белән идарә итте, аны Бөтенсоюз мәйданына алып чыгу өчен күп көч куйды.

Аның сәнгате, мәктәп укучысына да, президентка да якын, аңлаешлы. Якупов турында байтак язмалар, буклетлар, монографияләр чыккан. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки аның дөньясы – саф, якты төсләрдән генә тора, анда олы җанлы, батыр йөрәкле кешеләр яши. Ул дөнья һәркемне ирексездән үзенә җәлеп итә, күңелдә ышаныч, өмет уята. Рәссамның бер рәсеме нәкъ шулай атала да – "Таң атыр, ышан!.."

Әмма рәссамның бөтен халык тарафыннан танылуга кадәр үткән юлы бер дә алай җиңел булмый. Яшь Якуповны тәүге мәртәбә сугышка кадәр Мәскәүдә үткән Казан рәссамнары күргәзмәсендә күреп алалар. Анда аның "Идел моңнары" исемле рәсеме һәм данлыклы гаскәр башлыгы, армия генералы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое И.Д.Черняховский портреты куелган була. Аларга күренекле сәнгать белгече Машковец игътибар итә. Соңрак, 1944 елның язында Харис Якупов хезмәт иткән 60 нчы армия Тернопольны штурмлаганда, генерал очраклы рәвештә землянкадагы өстәл өстендә рәссам үзе ясаган альбомны күреп ала, анда төшерелгән рәсемнәрне җентекләп карап чыга һәм аларга зур көч салынуы турында әйтә. Әйтерсең лә алдан күргән! Бүгенге көндә "Хөкем алдыннан", "Михаил Девятаевның батырлыгы", "Минем шәлелеләрем", "Татарстан алтыны", "Габдулла Тукай" картиналарын, "Көчле кешеләр" сериясен кем генә белми дә, алар кайсы гына илләрдә булып кайтмаганнар.

...Якупов 1940 елны Казан сәнгать училищесының бишенче курсыннан 10 сабакташы белән бергә армиягә алына. Диплом эшләренә билгеләрне, чөнки дә эскизлар буенча куялар, илдә фин сугышы бара. Шул көннән алып 6 ел буе хәрби хезмәттә була. 148 нче Саратов укчы дивизиясендә хезмәт итә. 1941 елда, дивизия Татищев лагерьларында булган чакта сугыш башланып китә, һәм алар 26 июньдә эшелоннарга төялеп, сугышка китеп баралар. 7 нче июль көнне Якупов беренче мәртәбә утка керә, Варшава – Мәскәү автострадасын Гудериан танкларыннан саклауда катнаша. Әлбәттә, аяусыз, канлы көрәш барганда рәсем ясау кайгысы булмый. Туган илне дошманнарга калдырып чигенүләр дә йөрәкне яралый. Борынгы урыс шәһәре Трубчевски өчен сугыш бигрәк тә дәһшәтле була, ул өч тәүлек бара, анда 700 танк катнаша.

– Минем җанда рәсем ясау теләге 1941 елның декабрендә, Мәскәү өчен канлы бәрелештә җиңү яулаганнан соң яңадан уянды, – ди рәссам. – Шуннан соң бик күп рәсем ясадым, янган авыллар, дошманның җимерек техникасын, хәрби әсирләрне, үзебезнең солдатларны, күзем нәрсә күрде, шуны кәгазьгә төшердем. Көндезләрен рәсем ясарга вакыт булмый иде, күбрәк төннәрен шөгыльләндем, ядрә кыйпылчыгыннан әмәлләгән "тычкан уты" яктысында иҗат иттем. Җитмәсә, рәсемнәремне солдатларга күрсәтергә дә ояла идем. Илдә сугыш бара, ә мин... Әмма күргәч бик яраттылар, ярдәм итә дә башладылар әле. Бүген миндә 3 поход альбомы саклана, анда ике йөзләп рәсем бар. Берсе фашист танкы тарафыннан яндырылган машинада көл булды.

Харис Якупов II Бөтендөнья сугышының күп кенә бәрелешләрендә катнаша, Сталинград янында, Курск дугасында сугыша, Днепрны кичә, Львов шәһәрен, Польша, Германия, Чехословакияне азат итешә. Җиңү көнен Прагада каршылый, шунда "Җиңү белән, старшина Якупов!" исемле атаклы рәсемен ясый.

Сугыштан соң яңадан туган Казанына әйләнеп кайта.

– Без фронттан буш урынга кайтып төштек, – дип искә ала Харис ага. – Дөресен генә әйткәндә, энтузиазмнан гайре бер нәрсә дә: остаханәләр дә, заказлар да юк иде. Барысын да нульдән башларга туры килде. Без Татарстан сынлы сәнгатен үстерергә, аны Бөтенрусия, Бөтенсоюз мәйданына алып чыгарга омтылдык, шул ук вакытта киләчәк өчен дә нигез салдык – рәссамнар өчен остаханәләр, балалар сәнгать мәктәпләре, изостудияләр, күргәзмә заллары булдырдык. Боларның барысын да безнең буын вәкилләре эшләде. 40 нчы – 50 нче елларда, профессиональ рәссамнар бармак белән генә санарлык иде бит. Башка шәһәрләрдә югары уку йортлары тәмамлаган иҗатчыларны чакыртып, аларга фатирлар юнәттек, Татарстан шәһәрләрендә рәссамнарны бергә тупладык. Юк, ул еллар безнең өчен бер дә торгынлык еллары булмады, киресенчә, милли татар сәнгатенең үсеш алган, чәчәк аткан чоры булды.

• "Рәссам. Фронт юллары". 1985.

Ул елларда без Харис аганы төрле сыйфатларда күрдек: нәкышче һәм остаз, оештыручы һәм сәнгать белгече, хәтта мәдәниятебезне яклап көрәшүче дә булды. Сүз уңаеннан шуны искә алыйк: нәкъ менә Якупов 50 нче еллар башында "Кызыл Татарстан" гәзите битләрендә милли әдәбият, сәнгать һәм тарих мәсьәләләрен тирәнтен яктыртучы татар гәзите кирәклеге турында фикер әйтте. Ярый, рәссамның бу хыялы, соңга калып булса да, тормышка ашты, Татарстанда хәзер "Мәдәни җомга" гәзите чыга. Мәгәр аның тагын бер хыялы да тормышка ашсын, Казан сәнгать мәктәбе яңадан торгызылсын да, архитектор К.Мюфке тарафыннан махсус шушы мәктәп өчен төзелгән бинасы законлы хуҗаларына, ягъни рәссамнарга кайтарып бирелсен иде. (Хәзер анда КТУ, элекке КАИның 2 нче бинасы урнашкан). Ул чагында Идел буе һәм Урал төбәге сынлы сәнгате өчен илле дә мәгәр зур шатлык булыр иде!

Республикабыз сынлы сәнгате өчен Якуповның остаз буларак, Сәнгать Академиясенең Казан рәсем остаханәсе җитәкчесе буларак эшчәнлеге дә гаять әһәмияткә ия. Анда байтак кына талантлы рәссамнар: Татарстанның халык рәссамы Шамил Шәйдуллин, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Владимир Акимов, Зөфәр Гыймаев, Олег Сильянов, рәссамның улы Фәрит Якупов, Станислав Слесарский, Шамил Нигъмәтләр сәнгать нечкәлекләренә төшенделәр. Бүген дә биредә осталарының канаты астында яшь аспирантлар Фиринат Халиков, Резидә Яманова, Андрей Шляпкин, Евгений Мясников, Ирина Антонова, Айдар Хисамовлар олы сәнгать мәктәбе үтәләр.

Рәссамның иҗат юлы авыр да, сикәлтәле дә. Олы әсәр иҗат итү өчен аңа алны-ялны белми, көнетөне фидакарьләрчә хезмәт итәргә туры килә. Микельанджело, Репин, Суриков кебек бөек осталар шулай иҗат иткәннәр бит. Харис Якупов та нәкъ менә шулай яши һәм иҗат итә һәм үзенең шәкертләрен дә бертуктаусыз хезмәткә өнди. Тырышкан табар, ташка кадак кагар, ди ул. Шулай итеп дөньяга тиңсез сәнгать туа.

Мария ИЛЬИНА,
сәнгать белгече.

• *Харис Якупов.*

Солдат язмышы мине Тын океан ярларына китерде. Кытай җирендә япон самурайлары белән исәп-хисап ясап, 1945 елның 2 сентябрендә Икенче Бөтендөнья сугышы тәгамәлләнгәч, без озакка Сары диңгез буенда калдык. Кырыс солдат хезмәтен үтсәк тә, диңгез һәм кыялар иленең табигате белән кызыксына идек. Бүген дә хәтердә сакланганнары бар.

Мәрди РАФИКОВ

Сары диңгез буенда

Тарихлар

Кояш суда коена

Ярсу вә шашкын диңгез иртәнге гадәти җилсезлек сәгате җитү белән юашланып калды. Күз чикләмәс су дәрьясында кыялы ярга төбәп килгән ак сыртлы авыр дулкыннар юкарып сабыр гына тәгәри башладылар. Тынлык урнашты.

Тирә-як гаҗәеп матур иде. Диңгез бу мәлдә мөлдерәп торган киң табакны хәтерләтә. Кинәт чайкалып китеп суы түгелер төсле. Ә ул иртәнге чакта – штильдә чайкалмый. Аның еракта кучкылланып каймаланган офыгы да ачык булып күренә. Офык арты бөтен торышы белән шыкаеп, хәрәкәтсезләнеп калган бушлыкны хәтерләтә иде.

Сул канатта су өстеннән күтәрелгән йомарлак утрау ягына килбәтсез диңгез бакланнары очты. Арырак офык тарафына шуып баручы балыкчы көймәсе күренде. Кытай балыкчысы гадәтенчә көймә артына сын кебек баскан да сыңар ишкәк белән, "юли-юли" дип, бораулап иштерә, көймә артында су шадраланмыйча да кала. Таңдагы шушы гүзәл манзарага яңа бизәк өстәп тагын "юли-юли"ләр пәйда булды, алары да утрау тирәсендәге балыклы урынга тын гына йөзәләр иде.

Диңгез табигатенең шушы яменнән хозурланып та рәхәтләнергә булыр иде. Ә ул тагын бер могҗизасы белән таң калдырырга тели икән ләбаса!

Күз күреме җирдә, офык сызыгы ниргәсендә тимерче сандалындагы кебек чүкеч тигәнче очкынланган кызгылт шар барлыкка килде. Башта ул бераз сүрән саргылт төсе белән каймалы офык читендә генә күренде. Аннары... Әй, диңгез ярына басып кояш чыкканны күзләү соклангыч бер тамаша бит! Әнә ул "диңгез төбеннән" күтәрелде дә бөтен җетелеге белән алтын дирһәм кебек офык сызыгына бакты. Менә-менә тәгәрәп китәр дә чулт итеп суга чумар төсле иде. Юк инде, дөньяга килгән дөньяны ташламый. Кояшка да диңгезеннән күтәрелеп гөмбәзгә җитәргә язган. Ул бу мизгелдә җем-җем нурларын чәчте, ярга, минем тарафка ачыктан-ачык тасма итеп кызгылт шәүләсен сузды.

Матур иде, якты иде. Каядыр тын диңгезне ярып ике мачтасын да да ак җилкән киергән шхуна килеп чыкты. Ул тулы куәтенә бара алмаса да штильле диңгезне уятып дулкынын күтәрде. Шхуна артыннан су кабарып, күбекләнеп калды. Дулкыннары күзгә бәрелеп як-якка җәелделәр. Яшь кояш диңгезендә чайкалды. Юк, чайкалып кына калмады, ул дулкыннар кочагында чумып-чумып алды: кояш җылы гөмбәзенә күтәрелгәндә су керә иде.

Ә ул саф һәм пакь хәлдә аерыла икән диңгезеннән, аерыла да, тагын тугыз сәгатьтән минем Чирмешән буендагы туган авылым Түбән Балтай тавы артыннан таң сөреп, иртәнге кояш булып чыга.

Тозлы диңгез

Иртәнге тын һавада диңгез артыннан күтәрелгән кояш акрын гына ахак нурларын сибеп өйләсенә үрли. Эсселеге арта. Аяк астындагы чуерлар төшкә табан ялан тәпине өтеп алырлык хәлгә җитәләр. Тау-сопка итәгендәге гаолян һәм кукурузлар киң яфракларын сәлперәйтеп, изрәп төшәләр. Табигатьнең үзенә ут кабар сыман тоела.

Ә тоз плантациясендә шундый ике кояш янып торса да сөенерләр генә иде.

Плантациягә калкулыктан беренче мәртәбә сәерсенеп караган идем. Диңгез култыгының сөзәк яры бер урында футбол кыры кебек тигезләнгән, тирәсе дамба белән уратып алынган. Рәт-рәт шундый берничә тартма күренә. Соры таулар, яшел басулар күләгәсендә өсте җемелдек гыйнвар кары яткан кебек тоела. Саркыган тоз икән!

Ак диңгезне – бозлы диңгез, Сары диңгезне – тозлы диңгез, диләр. Һәй, тозы нинди генә әле!

Бервакыт эссе көндә походтан әлсерәп кайткан солдатлар җыйнаулашып Сары диңгезгә су керергә төштек. Күбекле ак дулкыннар иренеп кенә тәгәриләр, йөзгәндә күкрәккә бәрелеп чупылдыйлар. Рәхәт, күңелле, солдатка сирәк эләгә торган иркенлек, бәләкәй азатлык: фәрмансыз, теләгәнчә йөзәсең, чумасың... ул да түгел старшина биргән сабынны алып юынырга керештек. Башны, тәнне куе итеп сабынладык. Ә солдат сабыны Сары диңгезнең тозлы суында юылмый икән ич! Солдатлар көлешәләр, бер-берен үртиләр. Җитмәсә колак, борын яфракларына, иңбаш чокырларына мул булып тузандай тоз утырды, чәчләр киезләнеп калды. Ярга чыгып, тәнне сөлге белән тазартырга керештек. Кызарганчы ышкылыйбыз. Юк, сабынны, тозны казармага кайткач кое суы белән генә юып төшерә алдык. Диңгез шулай беренче сабак бирде.

Ә кытайлар Сары диңгезнең тоз байлыгын рәхәтләнеп файдаланалар икән. Плантацияләрен корганнар. Диңгез күтәрелгәндә дамбадагы төп капканы ачалар да плантациягә су бирәләр. Кытайның күзе кысык булса да үлчәүне ялгышмый, капканы вакытында яба. Шашкын диңгездә арыган су плантациядә тынычланып кала, тозы катлам булып төпкә утыра. Диңгез төшкәндә бераз суын да агызалар. Калганы утлы кояш нурларында буланып бетә. Аяк астында шыгырдап торган, пудрадай ак, тыгыз тоз катламы кала.

Диңгездән йолып-аралап алган тозны көн уртасында җыялар. Камыш тарткыга җигелгән качырларны күрәсең. Көрәк белән эшләүчеләр бар. Тозны бер почмакка китерәләр. Унлаган, кайчак йөзләгән кеше – көянтәле ирләр тозны кәрзиннәргә тутырып коры мәйданга илтәләр дә өемнәргә салалар.

Тоз җыйганда плантация буранланып тора: аның тузаннары кояш нурларында төрле-төрле төсләргә кереп җемелдиләр. Ә тоз тавы үзе очкынланып солдат күзләрен камаштыра. Хәтта төнлә ай яктысында фирүзә булып чәчелеп хәйран итә. Диңгездә шхуналар күренде. Кичкырын да тоз иленә йөзәләр. Көянтәле кытайлар төнлә дә эшли. Алар өемдәге тозны иртән озату өчен шхуналарга төйиләр. Сәере шул, мондагы халык тозны ашка, шулай ук көнкүрештә файдаланмый, аның белән сәүдә итәләр. Сары диңгезнең аш тәмләткеч пудра тозы солдат котелогына да керә.

Судагы йолдыз

Диңгез буенда язгы җилләр исә. Тынчу казармалар бушап калды. Хәрбиләр Бохайвань култыгы буена җәйләүгә чыкты. Яр дигәне – дулкыннар юып китергән ком дамба самурай кылычы кебек дугаланып берничә чакрымга сузыла. Шул җирне тузганак мамыгыдай ак палаткалар яулап ала. Аның Идел буенда үскән малайлар өчен шаклар гына катарлык бер үзенчәлеге бар: алты сәгать саен суы арта, алты сәгать саен кими. Диңгез күтәрелгәндә суында йөзәсең, чумасың, диңгез төшкәндә култык буйлап тездән су ярып йөрергә була. Бер чыгуда ике-өч чакрымга барып кайтырга мөмкин.

Беркөнне Ляняньцзин авылы якынында хәрби уеннар үткәреп лагерьга иртәрәк кайткан идек. Палаткага Шәриф керде.

– Ялыкмадыңмы? Әйдә, диңгезгә чыгып керәбез.

– Старшина ни әйтер?

Старшина палаткасын су читенә үк корган. Тәвәккәлләп янына кердек. "Диңгез күреп кайтасы иде", – дибез. Сәерсенеп карап куйды да, авызын ерып җибәрде:

– Конхиломеннар түгелсездер ич?

Аңламадык. Шәриф – миңа, мин аңа карыйм.

– Коллекциягә диңгез кабырчыгы җыясысзмы әллә дим?

– Ә, юк, диңгез йолдызы күрәсе иде, – ди Шәриф. – Безнең Иделдә йөзмиләр алар.

Старшинаның йөзе җитдиләнде.

– Ике сәгатьтән прилив башлана. Су күтәрелгәнче кайтыгыз. – Арттан кычкырып калды: – Кыздырмага бер-ике балык алып кайтыгыз.

Су чигенгән. Комда уч табаны кадәр краблар күренә. Гаҗәпләндереп, ян белән йөриләр. Әрле-бирле килеп үлгән балык, әкәм-төкәм эзлиләр.

Су чупырдатып диңгезгә киттек. Дулкыннар еракта ук сүнәләр, монда чайкалу гына сизелә.

Шәриф нидер табып алды. Йөнтәс йомарлак. Әйләндереп карыйбыз. Диңгез керпесе икән. Кыяр бакчасындагы безнең керпеләр кебек чәнчеми үзе. Суга төшердек тә, тагын киттек. Әкәмәт бер нәрсә очрады. Диңгез медуза калдырып киткән. Дулкыннар арасында йөзгәндә яшьлект-кара кыңгыраулар күрәсең. Чайкалып-биеп торалар. Кул яисә ишкәк белән орынсаң, ярты метрлы гәүдәсен җыерып су чыгаралар һәм, саклану өчендер, төпкә китәләр. Ә бусы фаҗигагә тарыган һәм диңгез чүбе кебек сай җиргә бәреп чыгарылган.

Комлы ярдан кузгалып киткәнгә чакрым булгандыр. Су тезгә җитә. Ниһаять, диңгез йолдызының үзенә тап булдык. Миңа калса, яшькелтен, ком төслесен, хәтта таң шәүләсе сыман алсуын күргәнем бар иде. Ә монысы – зәңгәрсу, аеруча матур. Чын-чын йолдыз, биш канатлы. Унбиш канатлысы була икән. Шәриф шунысын күрергә хыяллана. Бар, эзлә, тап! Кайдадыр устрица кимереп, йә балыкчы җәтмәсендә буй-буй диңгез алабугасы йолкып маташадыр әле. Күктәге йолдызлар кеше затын җемелдәшеп сөендерәләр, ә су йолдызлары күрер күзгә җыйнак һәм гүзәл булсалар да диңгез дөньясы өчен бәләкәй ерткыч саналалар. Ыржык һәм үткен тешләре бар, астыртынлыкка өйрәнгәннәр.

Шәриф кулына алган йолдызның кытыршы гәүдәсен сыйпап торды да, солдат дусларга да күрсәтим әле дип, иңенә аскан сумкага салды.

Старшина әйткән прилив сизелә башлаган иде инде. Диңгез күтәрелгәнче ярга чыгыйк дип, кайту юлына борылдык. Шәриф бераз баргач кесә фонаре белән шомарып беткән япьле таяк чыгарды. Су төбен яктыртып бара. Бер җирдә балык көтеп туктап калды. Яктыга килгән балыкны бастырып алды да, саңагыннан эләктерәп сумкага салды. Шулай берничә мәртәбә тукталды. Һәй, мәрхәмәтле старшинага шәп тә кыздырма була инде!

Без су билгә җиткәндә генә ярга чыктык. Ян белән йөрүче краблар һаман да ризык эзлиләр иде әле.

Актан-ак дөге

Җирләре, җирләре...

Гүя бакыр яккан. Туфрагы – көрәнкызгылт, тузанлы. Җил күтәрелсә, һава кызгылт-сары төс ала. Хуанхэ кузгалса, Ляоха купса, бассейндагы Ялуцзян күтәрелеп ташый башласа, шул "бакыр туфрак" ташкын белән диңгезгә ага һәм диңгез үзе рәссам полотносындагы кебек сары төскә керә. Ак диңгез бар, Карасы, Кызылы, ә монысын Сары дип тамгалаганнар.

Аның ярларында Хуанхэ белән бөтенләй дә ярышмаган, тын гына, ярларыннан сикереп чыкмыйча ага торган елга-инешләре күп. Алары гади сулык-чыганаклар гына түгел, алары – алтын!

Шундый инешләрнең саф һәм төче сулы берсе тау-калкулыклар аралап Ляодун култыгына йөгерә. Тамагында, диңгез буенда үзәнлек булып җәелә. Кытайлар суын тотканнар, шакмак-шакмак итеп төзегән дамбалы басуларга җибәргәннәр. Ә анда сокландырып дөге үсә.

Башта әле аның дөге икәнлеген белмисең. Басуда пычтыр-пычтыр килеп агач сука тарткан качырлар йөри – җир сөрәләр...

Тәмле дөге боткасы. Майлысы бигрәк тә йөрәккә ята. Ә үсентеләрен баткаклы дуен-туфракка утырталар һәм инештән төче су җибәрәләр. Күз алдында камышлы күл җәйри. Камышлары юк, әлбәттә. Дөге камыш кебек күренә, арасында балыклар да үсә. Дөгенең сыгылып суга тигән авыр бөртекле себеркәчләрен сикереп-сикереп йолкыйлар. Үсемлекләр арасында, әллә безнең якныкылар инде, үрдәкләр чумырдый. Кыр үрдәкләре. Чын-чын саз кошлары диярсең, чуар сыртлы комсыз чуллыкка кадәр бар.

Саз саз инде – кошлар дөньясы. Ә монда – дөге плантациясе. Мылтык тавышлары яңгырый. Сазларына куалар әрәмтамакларны, киекләргә кыргый-табигый сулыклар таман, диләр.

Гаҗәеп татлы дөге боткасы, туклыклы. Ә уңышын плантациянең суын агызгач, тездән пычрак ерып, йә суын агызмыйча, көймәдә йөзеп уралар, көлтәләрен калкулыктагы ындырга китереп сугалар. Кояшлы көн булып, кулыңа көшелдән кушуч бөртек аласыңмы – энҗеләргә хас җемелдәү тоясың. Ә өстәлдәге боткасы актан-ак, аны һәр җирдә – ошбу диңгез буенда да, туган ягым Апаста да дөге диләр, иң кадерле кунакка бәлешенә кадәр китереп ашаталар. Ерактан килгән затлы ризык дип сыйлыйлар.

Солдаттан кайткач, майлы боткасы миңа да эләгер. Ә хәзер калкулыктан плантациясенә карап утырам.

Тарихи тарихчы

Гаяз Исхакый – чын тарихчы. Бу сүз, бәлки, бездә гадәти нәрсә булып калган "дежур" сүз, рәсми бәя булып тоелыр. Нигезе булмаган ясалма мактау, күпертүнең, төтен очыру гына булып күренүе дә мөмкин. Әмма мондый нәтиҗә ясарга ашыкмыйк. "Инкыйраз"ын, "Идел-Урал"ларын искә төшерик. Мәкаләләрендә, язмаларында татарлар арасында революцион оешмалар, партияләр, шәкертләр хәрәкәте, әдәбият, журналистика, нәшрият тарихына кагылышлы күзәтү-гомумиләштерүләрен хәтерлик. Әйе, татар онында байтак хәлләргә карата чын тарихи караш формалаштыруда һәм бик күп фактларны барлап, мәйданга чыгарып калдыруда ул күренекле тарихчыларыбыз белән ярыша ала. Фәнни тарихыбызны язу эшендәге күп кенә табыш-казанышларыбыз нәкъ менә аның каләме аша килә. Билгеле сәбәпләр аркасында, кызганыч, алар әле һаман барланмаган, кулланышка кертелмәгән хәлдә кала бирә. Шул максатка җәмәгатьчелек игътибарын карату йөзеннән, аның библиографияләренә дә керми калган ике мәкаләсен укучылар игътибарына тәкъдим итәбез. "Борынгы заманда хөкүмәт һәм халык". Бу мәкалә "Казан мөхбире" гәзитенең 29.9.1906 (N 158) һәм 1.10.1906 (N 159) саннарында "Ч" имзасы белән басылган. "Чыңгыз" псевдонимының кыскартылган варианты "Ч" Гаяз Исхакый имзасы икәне күпләр өчен сер түгел. Гәзит материалларының җентекләп өйрәнелмәве сәбәпле генә ул галимнәр күзеннән читтә калган. Мәкалә XYIII-XIX гасырларда татар крәстиәннәре арасында зур бер төркемне тәшкил иткән "лашманнар" турында бай мәгълүмат бирә.

Шул ук "Казан мөхбире"нең 4.2.1907 (N 213) санында Г.Исхакыйның игътибардан читтә калган тагын бер зур булмаган язмасы бар. "Биктимернең кодасы Бикмуллага хаты" сериясеннән. Чистай төрмәсендә язылган. Иң гадәти памфлет, полиция-жандармнарның халык хокукларын аяк асларында таптауларына, реакция башланган көннәрдәге сайлауларга сатира. Шул ук вакытта, әдипнең тарихи карашы үткенлегенә тагын бер мисал. Империя тарихының "мәңгелек" (җуелмас) нигез принципларын, империянең полициячел жандарм-опричниклык нигезләрен һәм яшәеш рәвешен, Русиядә реакциянең котылгысыз өстенлек алуы механизмын ача да сала. Җитди нәрсә түгел, шаяру-шамакайлану гына бу дип тәкъдим ителгән "узгынчы" язма да тарихны яктырта, чын фәнни тарих менә шундый орлык, ярalгылардан гына үсеп чыга ала. Исхакыйның бу язмалары, минемчә, бүгенге көн өчен дә бик гыйбрәтле.

Мәсгуд ГАЙНЕТДИН.

Борынгы заманда хөкүмәт һәм халык

Соң вакытларда крәстиәннәрнең хәлләре актык чиккә җитеп, ачлык, хокуксызлык бәласенә сабырлары беттеке күренмәктәдер. Әүвәлдә, җир күп, тамак тук булганга, хокуксызлык сизелми, сизелсә дә чыдала иде. Крәстиәннәрнең кайчаннан бирле аяк астында тапталганын карт бабайларның хикәятләре буенча язып, яшьләргә бер ядкәр калдырмак буламын. Картларның сөйләвенә караганда, баяр крәстиәннәреннән башка һәммә халыкны – ясашный, лашман атлы ике зур кыйсемгә бүлеп, һәрберсеннән бер төрле истифадә итсә дә, җир өчен налогны икесеннән тигез алмакта иде. Ясашныйлар җир өчен түләгән налог өстенә, өч сукага бер солдат, ягъни нәселдә хезмәткә яраклы өч кеше булса, берсен тотып солдатка биргәннәр. Солдатка алу хәзерге тәртиптә булмаган. Ата йә ана, кечкенә балалары хезмәткә ярарлык булгач кына, өч бала арасыннан үзләре яратмаганрагын биргәннәр. Кечкенә бала хезмәткә ярагач кына, каюсы – зур, каюсы кечкенә углын биргәнгә, солдатлар, хәзерге кеби, яшьтә тигез булмаган. Хезмәт мөтдәте 25 ел булганга, 40та солдатка китеп, 65 яшендә, сакаллары агарып, шәех, фани булып, үләренә кайтканнары да бик күп булган. Йортта хезмәткә ярарлык өч кеше булмаса, нәселдән, шул нәселнең аксакаллары киңәше берлә, берсен тотып җибәргәннәр. Йортта, яки нәселдә өчнең берсе дә солдатка ярамаслык булса, шул өч хезмәтченең берсе, 25 ел эчендә, һәр җәй көне, падишаһлык файдасына, кирпеч сугу, утын кисү кебек агыр хезмәт иткән. Байтак кешеләр, балалары урынына, яллап, солдатка кеше җибәргәннәр. Наемщикны докторга күрсәтеп, солдатка ярарлыгын белеп, яз көне яллаганнар да, җәй буе сыйлаганнар. Наемщиклар, галәбән, бик усал булганга, аңар каршы килгәч, көз көне прием вакытында кабул итмәү куркынычы булганга, йорттагы кызларны, карендәш-ыруларына яшереп, ул ни теләсә, аны булдырырга тырышканнар. Хәтта җәй көне чана җиктереп авыл буенда гуляйт итүчеләре дә булган. Ашап-эчеп, бөтен йортны бәлдерүчеләре бик күп булган. Наемщиклар халыкның үзәгенә үткәнгә, хәзер дә, усалрак кешеләрне "наемщик" диеп кенә атыйлар. Наемщиклар арасында да, бик сирәк кенә булса да, аракы урынына – чәй, фрукта урынына пичтә куырган борчак берлә канәгатьләнүчеләре дә булган. Наемщиклар, бер җәйлек сыйлануга алданып, бөтен гомерлеккә диярлек солдат булып йөргәннәр.

Лашманнар җир өчен налог түләүдә ясашныйлар берлә тигез булсалар да, падишаһлыкка бөтенләй башка рәвештә хезмәт иткәннәр. Алар, солдатка бару урынына, хәзинәнең кораб вә башка заводларына олуг урманнардан агач кисеп ташыганнар. Август башларында җәяүле лашманнар, үзләренең урак, арыш чәчү кеби йорт хезмәтләренә карамай, урманнарына барып, агач кисеп хәзерләп, чана төшкәч кенә өйләренә кайтканнар. Алар кайткач, шул кискән агачны атлы лашман барып ташып бетереп, актык чана җулларына гына кайтканнар. Лашманга да, ясашныйлар солдат биргән кеби, өч хезмәтчегә бер кеше, бер ат барган. Ләкин ата кайсы углын теләсә, шулсын тотып бирергә ихтыярлы булмаган. Шобага яки ялланып барганнар. Атсыз фәкыйрьләр байларны яллап биргәннәр. Лашманга барганда хәзерге Казан тегүчеләренең Мәкәрҗәгә баргаңда: "Кая барасыз?" – дип сораучыга: "Мәкәрҗәгә! Мәкәрҗәгә!", кайтканда: "Кайдан кайтасыз?" – диючегә: "Мәкәрҗәдән лә..." диеп җавап бирүләре кеби, атлы лашман да фәкыйрьләргә җалланып, акчалары күп, тамаклары тук булганга: "Кая барасыз?" диючегә: "Лашманга! Лашманга!" дип, "Кайдан кайтасыз?" диючегә: эшләп-изелеп каннары кибеп беткәнгә: "Лашманнан ла..." – диеп җавап биргәннәр. Бер губерна, йә өяз ясашный, яки лашман булмаенча, һәр өяздә ясашный һәм лашман да булган. Бу ике таифә бер-берсен ким күреп, мәсхәрәләп йөргәннәр. Хәтта араларында, алмаштырышудан башка, кыз бирешү дә булмаган.

XYIII гасыр ахырларында, халык кашында "Әби патша" дию мәгъруф икенче Екатерина заманында, "Генеральски размежевание" – җирләрне үлчәп, ике авыл арасын аеру булган. Бу үлчәү урыс патшаларының иң әүвәл җирне үлчәүләре һәм гадәләтле булган. Һәр авылның төп җирен үлчәп язып, пичәт басып крип ясап биргәннәр. Крәстиәннәрнең шул крипләре булса, хәзерге удель җирләре һәм баярлар алдап алган җирләре крәстиәннәргә кайтыр иде. Ләкин крипләр югалып, тугрысын әйткәндә, крәстиәннәр кулыннан алынып беткән. Хакканият берлә җирләрне үлчәү Әби патшаһ фәрманы берлә булганга, крәстиәннәр арасында, Мәхкәмәи шәргыямез дә аның фәрманы берлә ачылганга, хосусан мөселман крәстиәннәре арасында Әби патшаһның шаны олугланып сөйләнәдер.

Соңрак заманда падишаһ нәселләре, байлардан көнләп, баярлар крәстиәне кеби, анларның да крәстиәне булуны теләгәннәр дә, 1833 елда, һәр авылларның җирләреннән, хәзерге запашка кеби, душка бер сажин кисеп алып, шул авыл халкыннан эшләтеп, җирдән чыккан файданы падишаһ нәселенә тәхсис кыйлганнар. Һәм шул халыкны – "удель крәстиәне" диеп атаганнар. Димәк, хөр халыкны җәберләп коллыкка керткәннәр. Һәр зур шәһәрләрдә "Удельный контор"лар корылып, ул конторлар да крәстиәнне җәберләүдә баярлардан күп калышмаганнар, кайвакытта арттырып та җибәргәннәр. Волостьның иң усал кешесен сайлап, шул волостьтагы удель җирләрен карар өчен, начальник итеп куйганнар. Удель җире, ат юклыктан, йә башка бер сәбәп белә, кушкан көнне сукаланмаса, яткырып бик каты сукканнар. Удель җирләрен эшләтеп кенә канәгатьләнми, һәр вакытта диярлек, крәстиәннәрнең чәчкән игеннәрен сукаланмый калса да, кирпеч сугарга, утын кисәргә-ташырга вә башка авыр хезмәтләргә, көтү-көтү, авыл

(Ахыры 12 нче биттә).

Җавап – сәвап

Улым Чичән сугышыннан кайтканнан соң (Аллага шөкер, исән-сау) белергә тели: Русия дәүләте ул күргән газаплар, михнәт һәм сугыш яраларын ничек бәяли? Аларның хокуклары нинди законнар, карарлар белән гарантияләнә?

Н.ГАБДРӘҮФОВА.
Казан.

Чичән территориясендә барган сугышта катнашканнарга тиешле ташламалар Русия Федерациясенең "Хәрби хезмәткәрләр статусы турында"гы Закон һәм контракт, башка документлар белән билгеләнә:РФ Хөкүмәте Карары (№1360, 1994 ел),"Чичән республикасындагы кораллы конфликт шартларында хәрби бурыч үтәгән хәрби хезмәткәрләрнең хокуклары һәм ташламалар турында"гы Президент указы (1996 ел) һ.б. Бу документларда Чичән сугышында катнашучыларның мохтаҗлыгын тәэмин итү буенча (Сезнең улыгызга да кагыла) кайбер чаралар каралган. Өлешчә, кайбер ташламалар болардан гыйбарәт: әгәр призыв буенча хәрби хезмәткә алынган кеше яраланып, гариплек алса, аңа контракт белән хәрби хезмәт итүче (һәм шул ук вазифаны үтәүче) окладлы исәбеннән акча түләнә: алар дәвалау-сәламәтләндерү учреждениеләренә юлламалар (путевка) белән беренче чиратта тәэмин ителәләр, Оборона министрлыгы сугышта яраланган, гариплек яки контузия алган хәрби хезмәткәр гаиләсеннән 2 кешене яшәү урыныннан дәвалау урынына (яки киресенчә) илтү-кайтару чыгымнарын күтәрә, дәвалау урынында булганда, шулай ук, юлдагы (бару һәм кайту) көннәре өчен матди ярдәм (суточные) күрсәтә. Һәм башка шундый ташламалар каралган. Аларны җентекләп өйрәнү өчен Сезгә югарыда аталган актларга мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Минем кызым бүгенге көндә хосусыйлаштырылмаган фатирда – әбисе янында яши. Кызым әле балигъ булмаган, ә менә әбисе белән ул-бу була калса, фатирга аның хокукы бармы?

Т.ГАЛИМОВ.
Зеленодол.

Бүгенге хокукый нормаларны исәпкә алганда, әбисе белән аның хосусыйлаштырылмаган фатирында яшәүче кызыгызның (Сез әйткән шартларда) хокуклары чикләнгән. Аның нибары пропискасы һәм анда яшәү хокукы гына саклана. Ләкин кызыгызның әбисеннән соң да бу торак мәйданындагы пропискасы, ул анда яшәмәсә дә, саклана. Әмма шуны истә тотыгыз: Русия Федерациясе Гражданлык Кодексының 54 нче статьясы нигезендә, кызыгыз балигъ булмаганга күрә, аның әтиәнисе буларак Сез дә бу фатирга пропискага керә аласыз. Әгәр кызыгызга әбисе үлгәндә 18 яшь тулган булса, Сез бу фатирга кызыгыз рөхсәтеннән башка пропискага керә алмыйсыз.

Яңа йортка күчкәндә (расселение) улыбызга 2 бүлмәле, ирем белән миңа бер бүлмәле фатир бирделәр. Кызыбыз кияүгә чыкты һәм 2 бүлмәле фатир сатып алды, ләкин берничә елдан иреннән аерылды.

Ирем үлгәч, миңа бер бүлмәле фатирымны кияүгә (кызымның ире) калдырып, кызым янына күчәргә туры килде. Хәзер без кызым белән хосусыйлаштырылган 2 бүлмәле фатирда яшибез. Кызым – фатир хуҗасы. Миннән соң улымның бу фатирга хокукы бармы?

Г.САДРЕТДИНОВА,
пенсионер.

Әгәр фатир хуҗасы кызыгыз икән, сездән соң да фатирга ул хуҗа булып калачак. Башка җирдә яшәүче улыгыз кызыгыз үлгән очракта ул фатирның мирасчысы була ала. Ләкин кызыгыздан соң аның мирасына хокукы булган исән туганнарыгыз калмаган очракта гына, (532 статья), ир һәм кыз туганнар, (әти-әни, ир, балалардан кала), ир йә кыз туган, абый-апа, әнә-сеңел икенче чираттагы мирасчы санала.

Г.МИРЗОЕВ,
Русия адвокатлар гильдиясе хезмәткәре.

(Мир новостей).

Китап күңел үстерә

Татарстан китап нәшрияты узган ел Сафуан Мулла Галинең "Йөрәктәге төеннәр" дигән китабын бастырып чыгарды. Аның төп өлешен "Биздерсәләр туган җиреңнән" исемендәге шигъри повесть алып тора.

Бу повестенда гына түгел, аерым шигырьләрендә дә Сафуан Мулла Гали халкыбыз язмышын – шатлыгын-кайгысын тасвирлый. Җыентыкта Кешене Кеше итеп бәяләргә өндәгән шигырьләр дә бар.

Тәндә җан барында,
И, туган җир,
Гаделсезлеккә
ник тезләним, –
Алдашалар синдә,
Алдыйлар һәр көнне –
Бу хурлыкка башка түзәлмим...

... Гаделлекне күтәрәсе иде,
Көн бирәсе иде кешегә, –
Күз алдында
шиңә кызларыбыз,
Егетләрнең рухы күшегә... –

дип яза үзенең җитмеш яшьлеген бәйрәм иткән шагыйрь.

"Дулкын баласы" – бик тә үзенчәлекле повесть. Әсәрдә безнең татар гаиләсендә үскән кырым татар кызы Сәбриянең язмышы тасвирлана. Автор аны гаҗәеп мавыктыргыч сюжетка корган. Кояш Тимбикованың башка әсәрләре кебек үк бу повесть та йөгерек тел, бай сурәтләүләр, тирән мәгънәле чагыштырулар белән язылган.

"Дулкын баласы" дигән китапта авторның яңа хикәяләре һәм публицистик язмалары да урын алган. Алар барысы да киң катлам укучы күңелен җәлеп итәрлек әсәрләр. Минем үземә, мәсәлән, иң ошаганнары "Мәхәббәт мәңгелек" дигән хикәясе һәм "Нишләвегез бу, егетләр" дигән публицистик язмасы булды. Мин аларны инде берничә тапкыр укып чыктым, әмма ике язманы да вакытым булган саен кабат укыйм, укыган саен алар миндә өр-яңа фикерләр уяталар, тирән хатирәләремне яңарталар...

Язилә АБДУЛКАДЫЙРОВА,
нәшрият мөхәррире.

(Ахыры. Башы 11 нче биттә).

халкын куалап киткәннәр. Шулай хезмәт иттереп, крәстиәннәрнең канын түбәнге вак-төяк чиновниклар эчкәннәр. Хөкүмәт, удель һәм баяр крәстиәннәренең сабырлары актык чиккә җиткәнен сизгәч, яхшылык берлә йибәрмәсәк, көч берлә китәрләр дип, куркып, 1861 елда, ике төрле крәстиәнне берьюлы азат кылып, барысын бергә – падиһашлык крәстиәннәре дип атаганнар. Димәк, бер хуҗадан азат иттереп, икенче, куәтлерәк хуҗага кол иткәннәр. Шуның эчендә, крәстиәннең бар малын, налог дип, падишаһ файдасына ала башлаганнар. Кол кәсеб кыйлган нәрсә хуҗаныкы булганга, падишаһлык расходының иң күп өлешен, туры, кәкре налоглар аркылы, крәстиәннәр җилкәсенә йөкләгәннәр. Бу удель бәласе ясашныйларга гына хас булмаса да, ягага барып хезмәт итү – лашманга юк, – алар, бары удель җирләрен эшләп кенә котыла иде. Крәстиәннәрне үзләре дигәнчә азат кылу берлә бергә, Русиядә бик күп яңалыклар ясалды. Ясашныйлар, лашман дип, халыкны икегә бүлү беткән. Һәр ике таифә тигез солдат бирә башлаган. Лашманлык исеме беткән. Солдат бирүдә аталар ихтыяры алынып, наемщиклар да кабул ителмәгән. Һәркем үзе өчен үзе солдатка барырга мәҗбүр булган. Акча түләп солдаттан калу булса да, гомере озакка бармаган. Һәм, шул елларда, җир тигезләү – "равноправие" булган. Ләкин бу җир тигезләү җире аз крәстиәннәргә җир бирер өчен булмый, билгакыс, җире күпләрдән җир тартып алыр өчен ясалган. Удель крәстиәннәренең урманнары һәм әллә никадәр җирләре тартып алынып, удель җирләренең хисабы бик күп арттырылган. Удель чыккач, 5-6 елдан соң, удель җирләрен крәстиәннәргә бик арзан бәһагә сатмакчы булганнар икән. Ләкин, удель җәфасы крәстиәннәрнең йөрәгенә бик үткәнгә, яңадан удельга кайтарыр куркусы илә, сатып алмаганнар. Хәзергә чаклы шул җирләрне арендага алып чәчәләр иде. Соң вакытларда, сатып алырга сорасалар да, удельный контор сатмады. Хәзер исә шул удель җирләрне Крестьянский поземельный банк аркылы әүвәлге хуҗаларына түгел, җирсез йә җире бик аз крәстиәннәргә саталар. Әүвәлге хуҗа(лар) разый булырлар микән, аны сорау да юк. Димәк, крәстиәннәрне, өченче мәртәбә уларак, Поземельный банкка кол ясыйлар. Крәстиәннәр кайчан гына, башка сыйныфлар берлә тигез булып, бер Аллаһка гына кол булырлар икән?

Ч.

Кечкенә мөтәфәрыйка

Гыйззәтле хөрмәтле Бикмулла кода!

Сезгә хат яза алмавыма әллә ни кадәр вакыт үтте, кодакаем. Сез бәлки: "Мине онытты", – дип, мине гаепли дә торгансыз. Гаеп миндә түгел, кодакаем. "Гаеп – язмышта!" Сезгә актык хатымны язганнан бирле бик күп гомер үтте, бик күп сулар акты. Минем башыма әллә ни кадәр бәлаләр килеп кичте. Беләмсең, кодакаем? Мин сезгә хат язганнан соң күп тә үтмәенчә, мине зинданга яптылар. Сез кодакаема язган хатларым өчен, мине законның 109011129 статьясы берлә гаепләп, гөнаһымны киметер өчен, дүрт городовой каккаладылар-суккаладылар! Без кечкенә вакытта әбиләр: "ата-ана (йә хәлфә) суккан йир тәмугта янмый", -диләр иде. Ул сүз дөрес икән, кодакаем. Хәзерге замандагы городовойлар бөтен Русия халкының хәлфәләре булганга, гөнаһны киметер өчен шулай итсәләр, гаҗәп түгел икән! Аларның кыйнавы-сугулары, һәммәсе дә – безне якын күрүләреннән, безгә яхшылык теләүдән генә икән! Әй, тәбәррекләр, нинди яхшы кешеләр! Безне нинди кызганалар. Безне дөнья утыннан түгел, ахирәт утыннан да коткармакчы булалар! Боларны "Русияне коткаручылар" димичә, кемнәрне әйтерсең? Боларны мактамаенча, кемнәрне мактарсың? Боларның һәммәсе бик яхшы кешеләрдер. Боларның һәммәсе "Русияне чын сөюче"ләрдер. Боларның һәммәсе Русиянең безнең кебек гөнаһлы бәндәләрене камчылары берлән, гөнаһлары кичерелүе өчен хезмәт итүчеләрдер. Мин, элгәре, "Таң"да язганда, кодакаем, боларны – "шалтыравыклы чиновниклар-фәләннәр" дип мыскыл итә идем. Боларның зурларын "карт бюрократ", "карт күсе" дип, көлә идем. Болар һәммәсе дә хата икән, кодакаем! Болар, һәммәсе, Русиянең иң зур кешеләре, Русиягә әллә ни кадәр хезмәт итүчеләр икән. Боларның сайлау вакытларында тырышуларын күрсәң, исең китәр. Бу тәбәррекләрнең, үзләрен-үзләре ваксындырып, олуг башларын кече итеп, сайлаучыларына барып: "Фәләнне, төгәнне сайла", – дип йөрүләре, бездән башка , нинди мәмләкәт чиновникларында күренгәне бар? Шуның өчен, кодакаем, мин моннан соң, "Таң"нар-"Маң"нар берлән чуалмыйм. Андый гәзитләргә син кодакаема язган хатларымны да күрсәтмим. Дурнава кебек затларны – солы ашаган дип, Гурко кебек тәбәррекләрне – "ашка күпкән" дип язмыйм. Боларны дус күргәннәрне дус күрәм. Столыпинның либераллыгына ышанам, иман китерәм. Гурконың гөнаһсызлыгына, Лидвальның барлыгына, 25 мең франкны барон Фридиксның йоклаганда гына алуына игътикад кыйлдым, күңелемне беркеттем. Моннан соң да, Столыпиннарның булуына, моннан соң да полевой судлар булуына ышандым. Моннан соң да Гурко, Лидвальларның ач халыкларны ашатуларына һәм, моннан соң да, бароннар, графларның йоклаган вакытларында, 25 мең франклар, йөзләр мең сумнарны белмәенчә алуларына инандым!

Гаяз Исхакый – милләттәшләребез арасында. Мукден шәһәре (Маньчжурия). 1935 ел.

Русиянең акчасының күплегенә, ренталарның төшмәүләренә, Столыпинның циркулярының халыкны тынычландырып, сулларны Думага сайлатмавына, телем берлән икърар кыйлып, күңелем берлән иман китердем. Хәзерге түрәләргә каршы сөйләгән сүзләремнән тәүбә кыйлдым-кайттым, тәүбә кыйлдым-кайттым, тәүбә кыйлдым-кайттым! Думаның уң булуы өчен, Думаның мискин тәбәррек түрәләрне сүкмәенчә, алар ни кушса, шуны эшләп торуы өчен, җиде шәехкә җиде нәзер әйттем. Элгәреге Аладиннар, Анипкиннарның иптәшләре эләкмәсен өчен, үзем төрмәгә кереп яттым! Сез дә, кодакаем, андый-мондый кызыл-мызыллар сайламаңыз! Чын татарларны сайлаңыз! Зәңгәр Салахны – Думага җибәреңез! Мирсәед учительне бөтен мөселманнар арасында кызыл фикерне бетерергә баш итеп куеңыз! Газларны, Фуадларны, Харисларны җибәрмәңез!

Менә шул әйткәннәремне тотсаңыз, чын кодакаем булырсыз дип язучы

кодаңыз БИКТИМЕР.
26 гыйнвар, 1907 ел. Чистай төрмәсе.

Минзәлә театрында премьера

16 гыйнвар көнне Минзәлә Татар дәүләт драма театры драматург Хәбир Ибраһимның "Газиз ярым" исемле әсәре буенча эшләнгән спектакль премьерасын күрсәтте. Психологик кичерешләргә бай һәм шул кичерешләрне бөтен нечкәлеге

Газиз ярым – үз ярым...

белән тулы итеп бирә алган артистларның оста уенынннан торган бу спектакльне Минзәлә тамашачысы бик яратып һәм җылы итеп кабул итте. Әсәрне сәхнәгә яшь режиссер, Булат Бәдриев куйган, спектакльгә көйләрне Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, танылган композитор Мәсгут Имашев язган, сәхнәне театрның рәссамы Салих Миңнегәрәев бизәгән. Классик драматургыбыз Ф.Әмирханның "Тигезсезләр" әсәрен куеп инде сәләтле режиссер булып танылган Булат Бәдриев "Газиз ярым" әсәрен дә сәхнәгә үзенчәлекле итеп, төрле театраль эффектлар кулланып, кайбер эпизодларны көчәйтеп, аны бер кульминацион ноктага җиткезеп куя алган. Спектакльдә тетрәндергеч, сокландыргыч урыннар шактый. Спектакльне караганда тамашачының күзеннән яшьләре китми. Әйе, газиз ире үлеп, ике баласы белән калган ханымның язмышы кызганычлы да, монсу да. Спектакльдә күрсәтелгән вакыйгалар тормышта да адым саен бит. Әле күптән түгел генә шушы спектакль Мөслим районында күрсәтелгәч, автор безнең тормышны тасвирлаган бит, монда үз язмышыбызны да ачык күрдек, дип килеп әйтүче хатын-кызлар да табылган. Әйе, кеше язмышы, кеше тормышы укучы өчен дә, тамашачы да өчен һәрчак кызыксыну тудыра. Әсәрнең төп героинясы Фәүзияне уйнаучы артистка Гөлшәһидә Сәлахова образны бөтен тулылыгы белән ачып бирә алган. Бу аның бик зур уңышы. Тискәре образ Галимханны Татарстанның атказанган артисты Хафиз Хамматуллин нәкъ тормыштагыча итеп иҗат итә алган. Галимханның хатыны Мөршидәне уйнаучы Венера Нигъмәтуллинаның: "Мин дә бит кеше, минем яратырга, сөяргә-сөелергә хакым бардыр бит!" дип өзгәләнеп кычкыруы үзәкләрне өзә. Һәм шулай ук әле яңа гына театрга килгән яшьләр Илназ Гайфин, Наил Әзгәмов, Эльвира Хәйретдинова, шулай ук күрше хатыны Саимәне уйнаучы, инде егермеләп елын театрга багышлаган Сәгъдәнур Шәймәрдановаларның уены зур тәэсир калдырды.

Шушы көннәрдә генә театр тагын бер куаныч кичерде: Мәдәният йортыннан яңа бинага күчende. Әлегә театрның фойесы, тамаша залы төзелеп бетмәсә дә, монда инде артистлар, хезмәткәрләр өчен бөтен шартлары да тудырылган, Евроремонт стилендә бизәлгән эш, грим бүлмәләре бар. Театр бинасын төзүдә бөтен көчен биреп эшләгән директор Роберт Шәймәрдәнов киләчәккә зур өмет белән карый. "Тамаша залын төзеп бетерергә дә инде күп калмады, дәүләт үзенең ярдәменнән ташламас, җәйгә кадәр театр бинасы ачу тантанасы булыр, Алла боерса! Театр бинасы ачылган очракта да без күчмә театр булып калабыз, бөтен республика халкына мәдәният хезмәте күрсәтәчәкбез" – диде ул театрның перспективасын әнә шулай билгеләп. Әйе, Минзәлә театры элеккеге традицияләреннән кире кайтмый, авырлыкларга да карамыйча, ул һаман "тәгәрмәчләр" өстендә. Инде менә бу якын көннәрдә Минзәлә театры "Газиз ярым" спектаклен Зәй районына алып чыгып китте...

Мәсгудә НИЯЗОВА.
Минзәлә.

Затулла баганасы

Күңел күзе

XIX гасырда яшәгән татар шагыйре Шәмсетдин Зәки, сукыр булуына карамастан, искиткеч хәтерле, гаҗәеп дәрәҗәдә зиһенле, кайбер күзле кешеләрдән дә тизрәк һәм күбрәк йөри торган кеше булган. Шуңа күрә кайберәүләр аның сукырлыгына шикләнеп караган.

Ашказар Балыклы мәдрәсәсендә укыганда ул егерме чакрым ераклыктагы Кара Киртә авылына берүзе кайтып йөри торган була. Анда шагыйрьнең туганнары яши икән. Шулай бер көнне Ашказар Балыклы авылының бер кешесе Шәмсетдин Зәкине, сынау нияте белән, ул узачак юл кырыена барып ята. Шагыйрь бу кеше турысына килеп җиткәч:

– Әссәламегаләйкем, Шаһимөхәммәт абзый, монда нишләп ятасың? – дигән.

Шаһимөхәммәт үз нәүбәтендә:

– Сине күрми дип әйтәләр иде, күрәсең икән! – дигән.

Аңа каршы шагыйрь:

– Күңел күзе күргәч, заһир күзнең күрмәве зарар түгел, – дип әйткән дә юлын дәвам иткән.

Һаман татар гаепле

1835 ел.

Александр Герцен Пермьгә сөргенгә җибәрелә, юлда барганда Казан аша уза. Алар жандарм белән Югары Осланнан Казан ягына чыгарга тиеш булалар. Жандарм смотрительдән тигез идәнле көймә сорап ала да, бер татарны яллап, көймәгә дүрт кеше – Герцен, жандарм, Герценның хезмәтчесе, көймәче татар төялеп Казанга таба йөзеп китәләр. Су уртасына җиткәч, көймә тишегендәге бөке төшә дә, ургылып су керә, көймә бата башлый.

Герцен көндәлегенә болай дип яза:

"Татар кешесе чыннан да бик куркынган, каушаган иде. Беренчедән, су исереп йоклаган жандармны чылатып бетерде, тегесе сикереп торып, татарны тукмый башлады. Икенчедән, көймә татарның үзенеке түгел, кәҗүнни көймә һәм татар агае бертуктаусыз кабатлый:

– Көймә батса, мине үтерәчәкләр! Үтерәчәкләр бит! – ди.

Көймә батса, көймә белән үзең дә батарсың! – дип шаярта Герцен.

– Үзем дә батсам, әйбәт булыр ие дә, ә батмый калсам, эш харап! – дип кайгыра татар.

Көймә белән узып баручы бер мужик ярдәмендә көчкә-көчкә тишекне томалап, болар тагын кузгала. Бераз баргач, тишек тагын ачыла. Көймә тагын бата башлый. Татар Аллага иман китерә. Герценның хезмәтчесе:

– Хуш, анакаем, кабат синең белән күрешеп булмас! – дип акырып җыларга тотына.

Жандарм исә, ярга чыккач, бөтенесен дә тукмау белән яный".

Зур җәберләр белән генә алар Казан ягына чыгып җитәләр.

Илһам Фәйзрахманов кыйтыклары

Сала саен мең дә бер мәзәк

Кем нәрсә күрә?

Мәктәпнең яхшы укучыларын җыеп, Казанга экскурсиягә алып баралар. Гадәт буенча, зоопарк, музейлар, кибетләр буйлап йөртәләр авыл балаларын. Әти-әнисе Казаннән әйләнеп кайткан Миңзифадан сорый:

– Күрдеңме, кызым, Казанны? Ошадымы? Кайларда булдыгыз?

– И, әни! Андагы кеше! Андагы машина! Андагы морожный! – дип җавап бирә уку алдынгысы.

Сүнгән йолдызлар

Авыл яшьләре клубта концерт куялар. Сәхнәдә каушамас өчен, бераз "төшереп" тә ала болар. Араларында җырга хирыс Габделхак та бар. Концерт бетеп, "танцы"дан соң яшьләр парлашып таралышалар. Габделхак та күптәннән күз атып йөргән Фәридәне озата бара. Капка төбендә Фәридә егеткә:

– Ай матур да җырладың инде... Габделхак! – ди.

Егеткә канатлар чыккандай була.

– Ә беләсеңме, Фәридә? Мин бит аны сиңа багышлап җырлаган идем, – дип мактана да башлый.

Фәридә, егеттән туеп, ничек өйгә кереп китү юлын эзли һәм таба:

– Юк, ышанмыйм мин сиңа, – ди. – Әгәр сүзләрең дөрес икән, менә хәзер монда җырла.

"Каушамас өчен" дип эчкән шайтан суы үзенекен итә бит – каушамый Габделхак, җырлап җибәрә:

Ул Балтачта туган. Балык Бистәсендә үскән. Дөресрәге Балык Бистәсе районының Балтач авылында. Шуның белән мактана. Җыйган мәзәкләре дә, күрәсең, шул яктан. Илһам белгечлеге буенча агроном, шәһәрдә яши. Күренгәнчә, чәчәура, суга-җилгәрә.

Күрче, иркәм,
нинди матур бу төн,
Йолдызлар яна безнең өчен...

Ачык тәрәзәдән җыр тавышы өйгә ишетелә. Фәриднең әтисе йокысыннан уянып хатынына:

– Сара, әйт әле шул кызларыңа, сүндерсеннәр магнитофоннарын, – ди. Ә егет белән кызның сөйләшкәнен тыңлап яткан әни кеше тәрәзәдән кызга эндәшә:

– Фәридә, сүндерегез йолдызларыгызны, булды, җитте. Кер өйгә!

Фәридәгә исә шул гына кирәк тә.

Былтыргы кепка – быелгы билге

Урманга утынга барган җиреннән Габдрахман абый кепкасыз кайта. Ул моны хатынына ничек аңлаткандыр, ләкин карчыгы кепка югалуын сизсә дә, сүз әйтми.

Шулай бу хәл онытыла, бер ел вакыт үтеп китә. Габдрахман абыйның карчыгы, урманда чикләвек җыйганда, куакта эленеп торган кепка таба.

Урманнан кайткач, ире нәрсә әйтер икән дип, үзенең былтыргы шөбһәсе рас килүенә сөенеп-горурланып:

– Карале, Гаптерахман, урманда бер кипке таптым. Синекенә охшаган бигрәк, әллә синең үзеңнекеме соң бу? – ди.

Габдрахман абый югалып калмый, сиздермәскә тырышып:

– Ә! Әйе, минеке, – ди. – Бик матур корыган туйра бар иде ул төштә, шуны онытмас өчен билге-тамга итеп калдырган идем, списсияльни. Аннары чикләвек тә бик шәп иде ул урында...

– Бу кипкәң былтыр элеп калдырганга ошый түлке, – ди хатыны, ирен сүз белән тота алмагач. – Эче тулы кипкән яфраклар, үрмәкүч пәрәвезләре...

– Мин дә шулай дим бит инде. Әнә, кара әле, үзең күпме чикләвек җыйгансың шул урыннан минем билге аркасында!

– Шулайдыр инде, былтыргы кипке, быелгы билге булган ди! – дип үз-үзенә сөйләнә карчыгы, җиңелүенә ачуы килеп.

Авыл сөтенә ни җитә

Күп балалы гаилә башлыгы Габдрахман абый мал-туар карап йөри. Күңеле күтәренке. Балалары кунакка кайтты, бөтен өй умарта күчедәй гөжләп тора. Әнә кайсы-кая чабыша. Китәргә җыеналар, әниләре күчтәнәч әзерли. Күчтәнәч дигәннән, һәркем белә, авылдан күчтәнәч шул: ит, сөт, май, каймак, бәрәңге ише әйберләр.

Әти-әни шулай инде: хәзинәдә булганның барысын да балаларга бирәсе килә. Үзенә булмаса да, балаларга булсын...

Шундый уйлар белән хисләнеп, Габдрахман абыйның игътибары бер нәрсәгә төшә: әллә белеп, әллә белмичә, бербер артлы өч кызы абзарга керә дә сыер сава, керә дә сыер сава... Гаҗәпләнә Габдрахман абый, сыерны кереп карый: "Әллә чыннан да яхшы "пароДа"га әйләнгәнме бу, шулкадәр сөт саугач?" – янәсе.

Ул арада, балалар да җыелышып, капка төбенә чыкканнар:

– Әти, сау булып тор, авырма, – дип тәкрарлыйлар барысы да.

– Ярый, сау булыгыз, исәнлектә-саулыкта. Бүген сыер беренчелекне алды инде, маладис! Икенче кайтуыгызга мөгаен тавыклар да көненә өчәр йомырка сала башлар. Озак көттермәгез, кайтыгыз, – дип елмаеп озатып кала Габдрахман абый.

Кунак кызы

Шәһәрдән кунакка кайткан бәләкәй кызчык Регинадан дәү әнисе сорый:

– Кызым, татарча беләсеңме соң?

– Да, знаю, – ди бәләкәй Регина.

– Яле, йә, сөйләшеп күрсәт әле, кызым, – ди дәү әнисе.

– Маймыл, ишәк, эт, дуңгыз, сарык, кәҗә, – дип тезеп китә кызчык.

– Әй, кызым, – ди дәү әнисе, – сиңа моны кем өйрәтте соң?

– Папа белән мама өйрәтте, – ди кыз.

– Дуңгыз тәреләр, – дип сөмсерен коя дәү әнисе.

Шулай итеп, Регинаның күңел дәфтәренә "тәре" сүзе дә өстәлә.

Бәйләнмә!

Ялгыш каенны кочканмын,
Мин аны син дип торам...
Роберт МИҢНУЛЛИН.

Урам буйлап берәү бара,
"Тукта!" – диеп кычкырам.
Туктарга уенда да юк –
Мин аны син дип торам.

"Тукта – минәйтәм. – Югыйсә!
Тотып колагың борам!"
Туктады да көтеп тора,
Мин аны син дип торам.

"Не залезай!" дип язылган -
(Ах, күзеңнең карасын!) -
Ялгыш барып кочканмын бит
Электр баганасын.

Погон таккан берәү шунда
Миңа килеп бәйләнә.
Нигә миңа бәйләнә ул,
Болай да баш әйләнә.

Әйт әле, әйт син шуңарга
Әйт әле, каенкаем.
Кешегә бәйләнәләрме
Багана кочкан саен?!

Нигә миңа бәйләнә ул -
Аягымда нык торам.
Ул да, каен да бер төсле -
Аералмый тик торам.



Башкодасыз килгән мәхәббәт

Шагыйрь Нәҗар Нәҗми дөньясының бер читенә генә кереп, күкрәк тутырып андагы һаваны бер генә суласаң да, рухың сафланган, дәртең көрәйгән кебек буласың, яшәү мәгънәсен тирәнрәк аңлый башлыйсың шикелле. Миңа шундый бәхетле мизгелләр тигәләде.

1960 – 70нче елларда, мин "Азат хатын" журналы редакциясендә эшләгәндә, Нәҗар абый монда, кайбер татар шагыйрьләренә караганда да ешрак була иде кебек. Үзеннән алда бүлмәгә елмаюы килеп керә. Куе, озын чәчләрен сыйпый-сыйпый ул безнең эшкә бәя бирергә тотына: журналның соңгы саннарындагы уңышлы мәкаләләрне, шигырьләрне телгә ала, басмый калсаң да ярарлык, йомшак әсәрләрне дә санап чыга. Кайчак бәхәсләшеп китәбез, әмма бу әңгәмә бәрәүне дә кимсетми, рәнҗетми, чөнки барыбыз да сүзнең журналны тагын да яхшыртa төшү турында баруын аңлый. Нәҗар абый редакциягә буш кул белән керми, яңа шигырьләрен, яңа җырларын да алып килгән була ул. Без ул елларда аның гаҗәеп киң таралыш алган җырларын еш баса идек. Кайдан да булса ишетеп алуыбыз була – композитор Рим Хәсәновка шалтыратабыз. Бер ара бу ике кызыклы шәхес бик ныклы иҗат берлеге оештырганнар иде. Алар дуслыгы нәтиҗәсендә дистәләгән шәп җырлар барлыкка килде. Рим Хәсәнов редакция үтенечен көне-сәгате белән үти: җырның сүзләрен дә, ноталарын да җибәрә. "Азат хатын" бу ике талант иясенең җырларын кайчак хәтта Уфа матбугаты баскалаганчы ук дөньяга тарата иде. Җыр чыкканнан соң, Нәҗар абый килүен көтәбез, аның бүлмәгә керүен җыр белән каршылыйбыз:

...Акты ташып, акты ярсып
кар сулары,
Шулдыр инде язның ташып
ярсулары.
Акты безнең кар өстендә
калган эзләр,
Акты, елап, икәү бергә
салган эзләр...

"Син – гомер агышларым", "Өфе юкәләре" кебек җырлар тора-бара тәмам халык җырына әйләнеп киткән кебек булды. Аларны татар яши торган теләсә кайсы тарафта җырлый башладылар.

Моннан тыш, Нәҗар абый миңа Мәскәүдә дә очрады. РСФСР язучылары съездына делегат итеп сайланган иде ул. Мәскәүнең Союзлар йорты дип йөртелә торган мәшһүр сараенда күрештек. Бу яктылык белән җылылык кайдан икән, дип борылып карасам, нәкъ Казандагыча ук елмаеп, Нәҗар абый басып тора. Тирә-юнендә әллә нинди зур-зур әдипләр, дуслары, танышлары, тик ул шулай да мине күргәч кайберәүләр кебек читкә тайпылмады: "У-у, Кояш ханым!" – дип, үзебезчә, сәламли-сәламли исәнләшергә, хәл-әхвәл сорашырга тотынды. Аннары урыс дуслары белән дә таныштырып чыкты. Ул һич тә үзгәрмәгән иде: гел шул җорлык, шаярту, көлү. Гадәттә, кеше, тирәсендә кемнәр булуга карап үзгәреп тә куйгалый бит, өендә ул бер төрле була, рәсми урыннарда кырыслана төшә, четереклерәк җирдә сине бөтенләй күрмәмешкә салышып, сәламеңне алмыйча узып китәргә дә күп сорамый. Нәҗар абый исә андый катлы-катлы кабыкларга төренеп үзен түбәнәйтми, үз йөзен һич яшерми.

Мәскәү димәктән, ул – Мәскәүдә дә үз кеше. Аның шигырьләре урыс гәзит-журналларында ("Литературная газета", "Литературная Россия", "Новый мир", "Звезда" һ.б.) зур-зур күләмнәрдә басылып торды. Аерым китаплары да чыкты. Мәгълүм ки, урыс нәшриятларында китап чыгару, аның гәзит-журналларында басылу урыс язучысы өчен дә авыр чакта мондый шөһрәткә ирешү өчен, татар-башкорт язучыларына, урысларга караганда ун-йөз мәртәбә артыграк тырышырга кирәк иде. Нәҗар абый – әнә шул мең катлы киртәләрне атлап үткән шагыйрь. Аны күп басмалар бик теләп басалар, чөнки шигырьләре кайбер урыс шагыйрьләренекенә караганда бик күпкә көчлерәк, тирәнрәк, аларны укыгач, каршы сүз әйтер урын юк.

Дөрес, съездлардагы төп докладларда аның исемен әлләни еш телгә алмыйлар иде. Докладларда макталучылар тыгыз бер бөҗрада иделәр: Бондарев, Распутин, Евтушенко кебек урыс әдипләре янына, "халыклар дуслыгын" расларга, берничә милли язучыны да кыстыралар – Айтматов, Күгелтдинов, Кулиев, Гамзатов... Башкортстан язучыларыннан бу бөҗрага Мостай Кәримне кертәләр иде. Соңрак бу "мисал өчен саналып йөртелүчеләрнең" һәммәсенә Социалистик Хезмәт Герое дигән исемнәр дә биреп чыктылар. Нәҗар абый бу ясалма төркемдә йөртелмәде һәм, уйлавымча, ул моның белән горурлана да иде әле.

Ә исемнәргә һәм бүләкләргә килгәндә, Нәҗар абыйның андый шөһрәтләре җитәрлек. Ул үзенең орден-медальләре, исемнәре белән теләсә кайда, теләсә кем алдында мактанырга да хаклы. Иң кадерлеләре – сугышчан бүләкләредер, мөгаен. Ул бит – Бөек Ватан сугышы батыры. Орденнарның бер ишесен шагыйрь кан коюлы бәрелешләрдә кыюлык күрсәтеп алган. Австрияне фашистлардан азат итүен ул аеруча дулкынланып сөйли. Җиңүле һөҗүмнәрдән соң аны Вена шәһәренең иминлеге өчен җаваплы җитәкче итеп тә куеп торалар. Иҗатына бәя бирү йөзеннән, аңа лаек исем вә бүләкләрне Башкортстан хөкүмәте дә мулдан өләшә. Ул безнең Татарстан тарафыннан да читкә кагылмый, әле күптән түгел аңа мәшһүр Гаяз Исхакыебыз исемендәге бүләк бирелде. Ни өчен дигәндә – бер генә шигыре: "Татар теле" шигыре өчен. Нәҗар абый тормышта гына түгел, шигырьләрендә дә үзе булып кала ул. Күңеленә шатлык индергән вакыйга турында язса, шигырьләре дә дөньяны шатлыкка күмә: моңаеп калса, әсәрләрендәге моңнан елап үләрлек була, инде явызлыкка яки гаделсезлеккә тап булып, шул хакта язарга тотынса – дошман сакланып кына өлгерсен!

"Татар теле" шигыре исә татарның дистәләгән галимнәр язып азапланган тарих томнарына тиң. Монда телгә мәдхия уку яки аның әһәмиятен олылау гына түгел, бу телгә ия татар халкының ачы язмышы тасвирлана кебек. Бөтендөнья татар конгрессына килгәч, Нәҗар абый Г.Камал исемендәге театр сәхнәсеннән шул шигырен укып җибәрде. Кай төшендәдер тәрәлебрәк калган иде, аңа ярдәмгә бөтен зал кушылды, аягүрә басып ул строфаны бергәләп яңгыраттык:

...Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, батыр татар теле!

Ихласлык – аның шигърияттенә дә, чәчмәләренә дә, драматургиясенә дә хас сыйфат. Укучыга күңелен тәмам ачып бирү теләге Нәҗар абый иҗатында шул кадәр көчле ки, бу юнәлештә безнең әдәбиятка хәтта яңа жанр да кертеп җибәрде. Монысы – хатлар. Кай ягы белән булса да аның игътибарын җәлеп иткән кайбер шәхесләргә Нәҗар абый хат яза. Хатны исә әлеге шәхескә түгел, матбугат органына җибәрә. Чөнки аның бу хаты безнең әдәби хәрәкәтебез өчен мөһим мәсьәләне күтәргән була. Укучы күңеленә үтеп керер өчен моннан да кулайрак нинди ысул табар идең?! Аның хатлары да кемгә языла бит әле?! Инде вафатына да шактый вакыт узган Саҗидә Сөләймановага, татар шигърияттенә бил бөккән шагыйрь Рәдиф Гатауллинга, Мөдәррис Әгъләмовка, аксакалыбыз Гомәр ага Бәшировка... Адресатларын күрүгә үк, хатларны укыйсы килә, әдип исә, укучының шул табигый кызыксынуыннан оста файдаланып, үзенә кирәкле фикерне үткәреп кала.

Саҗидә Сөләйманова белән Әдип абый Маликовны Нәҗар ага якташлары итеп тә бик якын күрә. Бер очрашуыбыз Әлмәттә, Саҗидә Сөләймановaның тууына 60 ел тулу уңаеннан оештырылган "Кызыл каурыйлар" кичәсендә булды. Кичәгә килгән халык Нәҗар аганың бәгыреннән чыккан сүзләрен тын алмый тыңлады. Бу чыгышта, безнең талантлы шагыйрәгә зур бәя бирелү белән бергә, Нәҗар Нәҗминең үзенең олы җанлылыгы да, якты нур булып, бөтен залга таралды.

Тагын бер очрашуыбыз аеруча көтелмәгәнчә һәм кадерле истәлекләргә бай булып тора. 1993 нче елның феврале иде. Татарстан Язучылар берлегенә Нәҗар Нәҗминең 75 яшьлеге тантанасын үткәрергә чакырып хәбәр килгән. Татарның кайсы олуг әдибен чакырган дип уйлыйсыз? Сердәш дуслары Мөхмүт Хөсәенне, Рәдиф Гатауллинны, Роберт Миңнуллинныңмы, әллә олугтан-олуг Гомәр Бәшировны яки Гариф Ахуновнымы? Берсен дә түгел – ике кызны җибәрүне сораган ул: Гөлшат Зәйнашеваны һәм мине.

Киттек. Безнең белән, бу вакыйга турында газета-журналларга хәбәрләр язарга дип, журналистка Фәния Хуҗахмәт тә барды. Кар-буранлы төн уртасында Нәҗар абый үзе каршы алды безне. Шул минуттан башлап без аның зур кунакларына әйләндек. Шагыйрьнең туган авылына да бардык, тантаналы кичәдә безгә дә сүз бирделәр. Фәниябез үзенең чыгышында, уенын-чынын бергә кушып, серле бер җөмлә-тәкъдим кертеп җибәрде: "Алыгыз безнең Тукайны, бирегез безгә Нәҗар абыйны!" – диде. Ә-әй китте шаушу, гөрләү... Бу тавыш хәтта Башкортстанның кайбер гәзит битләренә дә төште. Аптырадылар: ничек шундый көфер сүз әйтергә мөмкин, янәсе? Миңа шагыйрь Шәриф Бикколның хатыны Рәисә апа хат язып салган: "И Кояш, миңа читен, Фәнияне бер дә яман телләргә бирәсем килми..." – дигән. Үзем дә өзеп кенә аңлата алмас хәлдә идем, Фәниядән сорадым: "Ник алай әйттең соң?" – дим. Фәния көлә:

– Инде син дә аңламыйсыңмы? – ди. – "Тукай"ны бирдек бит без аларга – үзең тапшырдың. Бакый ага койган бюстны, ә Нәҗар абый барыбер безнеке инде ул...

Кеше булган кешедә мең кешенең эше бар, дигәндәй, чыннан да нигә әле без адәм баласын башкортныкы, татарныкы яки урысныкы дип тарткаларга калдык. Дөнья тармыни, кулларыннан килгәнчә барлык кешеләргә хезмәт итсеннәр. Хәер, Фәниянең үтенече тормышка ашты да бугай: Нәҗар абыебыз Бөтендөнья татар конгрессына да катнашты, безнең "Казан утлары" журналының редколлегия әгъзасы булып та тора. Шигырьләре безнең гәзит-журналлардан төшкәне юк. Начармыни?! Киң ябалдашлы агачларны, ботак-тармаклары никадәр еракка сузылсалар да, тамырларыннан аерып булмаган кебек, шагыйрьне дә туган туфрагыннан читләштерү мөмкин түгел. Иҗатының халыкара киңлеккә ирешүен тойган хәлдә Нәҗар абый туган ягын, Өфе юкәләрен, Дүртөйле районындагы Миңеште авылын тагын да тирәннәнрәк ярата, минемчә.

Русиянең һәр төбәгендә дә, төрки халыклар дөньясының һәр тарафында да Нәҗар Нәҗми иҗатын хуплап яшиләр икән, бу шагыйребез халыкара мәйданда яңгырый икән – үзара тарткалашмаска, моның өчен шатланырга кирәк. Бу – халыклар мәхәббәте, түбәннән килгән ихлас тойгы бу. Нәҗар Нәҗминең үз шигырендәгечә, әллә кайдан сизелеп торучы кадерле хис бу:

....Мәхәббәтнең килгәнен
мин тоям -
Үзе килә, килә тирәннән.
Башкодасыз,
димләүләрсез килә,
Өстән түгел, килә түбәннән.

Шатланыйк, горурланыйк; безнең шул кадерле кешебезгә, талантлы шәхесебезгә, халыкларның барын да тиң күрүче гуманистыбызга 80 яшь тула. Котлы мөбарәк булсын, иҗаты дәрләп торсын!

Кояш ТИМБИКОВА.

● *Нәҗар Нәҗми.*

Сәхнә биеклегендә калу

Соңгы елларда сәхнәгә күтәрелгән һәм тиз арада үз тамашачыларын тапкан, хөрмәт, ихтирам казанган эстрада җырчыларыбыз арасында Сәнифә Рангулова да бар. Иҗатына битараф булмаган тыңлаучы-тамашачы буларак кына түгел, каләм тибрәтүче кеше буларак та Сәнифәбез белән якыннанрак танышасы, аның чыгыш-концертлары турында үз укучыларым белән уй-фикерләремне уртаклашасым күптәннән җанны бимазалап тора иде инде. Менә, ниһаять, форсаты чыкты – Сәнифә Рангулова, редакциябез кунагы буларак, каршымда елмаеп, балкып утыра.

Елмаю, балку дигәннән Сәнифә үзенең матур-моңлы тавышы белән генә түгел, ә иң әүвәл сәхнә түрендә күпләрне әнә шул сыйфатлары белән әсир итте дә бугай әле. Төз, матур гәүдәле, нечкә билле кызыкай кыска итәктән бии-бии сәхнәгә репертуары байый, тулылана бара. Рәшит Кәлимуллин, Оскар һәм Вадим Усмановлар, Мәсгудә Шәмсетдинова, Резидә Әхиярова, Риф Гатауллин кебек халкыбыз арасында абруй казанган композиторларыбызның Гөлшат Зәйнашева, Резидә Вәлиева, Фәнис Яруллин, Роберт Миңнулин шигырьләренә язылган җырларын башкарып, Сәнифә Рангулова үзен эзләнүчән, киләчәге өметле булган җырчы итеп танытты. "Кызлар перчатка түгел", "Бар ул син эзләгән кеше", "Аерылу авыр икән", "Ал тасма", "Исеңә төшәрмен", "Йөрәк

• Яшь җырчы Сәнифә Рангулова.

Кояшлы җырчы

чыгуга һәм шаян-шук "Кызлар перчатка түгел" дигән җырны башлауга татар сәхнәсенә, татар тамашачылары каршына чыккан, моңа кадәр билгеле булмаган артистның бу кыланышларын күреп зал бермәлгә тын калган иде. Тик бу озакка бармады. Сәнифә сәхнәгә үзенең зифа аякларын күрсәтер өчен генә чыкмавын, ә җырның эчтәлегенә туры килердәй образ – чая, әмма мәхәббәт, сөю-яратуга үзенең мөнәсәбәте булган яшүсмер кызның уй-фикерләрен җыр телендә сөйләп биргәч, тамашачылар дәррәү килеп аны алкышларга күмде.

– Бу минем зур сәхнәгә беренче мәртәбә аяк басуым иде, – ди Сәнифә Рангулова бу хакта сүз чыккач. – 1993 ел иде ул.

Эстрадада үз урынын яуларга атлыгып торучы дистәләрчә яшь артистлар кебек үк Сәнифә дә эчке дулкынлану, ярсу белән атлаган иде ул чакта сәхнәгә. Беренче чыгышларыннан соң ук тамашачы күңеленә юл таба алу бәхетенә ирешкән җырчы тагын да канатланып эзләнүен дәвам итте. Сәхнә йолдызлары Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова һәм башкалар белән аралашып яшәү, алар белән бергә концерт-тамашаларда катнашулардан ул бернәрсәгә төшенде: сәхнә тамаша урыны гына түгел, ә бәлки безнең тормыш – чынбарлыкның көзгедәге бер чагылышы да икән. Анда ясалмалылыкка, арзанлы алдау-ялганлауга урын юк. Әгәр шулай икән тамашачы сине шунда ук сизеп алачак һәм киләчәктә концертларыңа йөрмәячәк, кабул итмәячәк. Ә үзеңне көчләп яраттыру, сәхнә бәхетен тою мөмкин булмаган нәрсә.

Моны бөтен җаны-тәне белән аңлаган, тойган Сәнифә җиң сызганып иҗади эзләнүләргә кереп чумды. Артист-җырчы өчен иң әүвәл үз репертуарыңны булдыру мөһим. Моның өчен исә синең тавышыңа, холык-фигылеңә туры килердәй җырлар эзләп табу, ягъни шагыйрь, композиторлар белән аралашып, иҗади дуслыкта яшәү сорала. Тиз аралашып китүчән, кызыклы әңгәмәдәш, күп нәрсәләрдән хәбәрдар булган Сәнифә Рангулова бу яктан да бәхетле иҗат кешесе. Көннән-көн, елдан-ел аның җырлары", "Елмай" аша таләпчән тамашачы Сәнифә Рангулованы таный, аны хөрмәт итә, алкышларга күмә. Җырчының әлеге иҗат җимешләре ике аудиоальбомына тупланган. Аларның берсе – "Мәхәббәт җырлары", икенчесе "Бәхет телә" дип исемләнгән.

... Безнең халык талантларга беркайчан да кытлык кичермәгән. Җир шарының барлык кыйтгаларына сибелгән татарлар кайда гына яшәүләренә карамастан, туган телебезне, җыр-моңнарыбызны саклап калганнар. Сәхнәбездә үзенчәлекле бер йолдыз булып кабынган Сәнифә Рангулова да Татарстаннан читтә туып үскән талантлы яшьләрнең берсе. Пермь өлкәсенең Барда районы, Күчтәнти авылы кызы белән бу як халкы хаклы рәвештә горурлана ала. Моңа кадәр үк инде Барда ягы татар мәдәниятенә, сәнгатенә, фәненә сизелерлек өлеш керткән җырчы-композитор Мәсгут Имашев, әдәбият белгече, фольклорчы, милли хәрәкәтебез җитәкчеләренең берсе Рәшит Ягъфаровларны биргән игелекле төбәк буларак кадерле иде.

Киләчәктә дә бу туфрактан халкыбызны сөендерерлек талантлар чыгачагына шик юк. Сүз уңаеннан шунысын әйтү дә урынлы булыр. Заманнар болгавыр, иҗат кешесенә яшәү, көн итүләр авыр. Пермь ягыннан чыккан эшкуарлар, җитәкчеләр үз талантларын һәрдаим барлап торсыннар, югалтмасыннар, кирәк чакта рухи, матди ярдәмнәреннән дә ташламасыннар иде.

Сәнифәбезнең Барда районында балкып кабынган якты йолдыз булуын әйткән идек инде. Биредә ул урта мәктәп тәмамлаган, Оса шәһәрендәге педагогия училищесында укып мөгаллимәлек белгечлеге алган, туган авылы Күчтәнтидә балалар укытырга да өлгергән. Дүрт балалы гаиләдә хезмәткә мәхәббәт тәрбиясе алган Сәнифә моның белән генә чикләнеп калырга теләми, бала чакта ук мәктәп, авыл сәхнәләрендә җырлап-биеп үскән кызның күңеле гел Казанга ашкына. Үзе дә мәҗлесләр күрке булган, матур итеп җырлаучы әтисе Шәрифҗан да кызының ниятенә каршы килми, хәер-фатихасын бирә. Казан музыка училищесына килә Сәнифә, имтиханын уңышлы тапшырып, вокаль бүлегенә укырга керә. Профессиональ сәхнәгә юл аның өчен нәкъ менә шушында укыган чагында башлана да инде. Бу уңайдан ул үзенең укытучысы-остазы Нина Петровна Зайцевага аеруча рәхмәтле. Ник дигәндә, сәхнәдә үз-үзеңне тоту, репертуар булдыру, кабатланмас образыңны тудыру кебек сыйфатларны аңарда нәкъ әнә ул тәрбияли дә инде.

Гомумән, Сәнифә Рангуловага үзе ирешкәннәр белән канәгатьләнеп яшәү хас нәрсә түгел. Гел эзләнүдә, укуда ул. Аны әледән-әле радио-телевидение тапшыруларына чакыралар, концертларга дәшәләр. Ул ялындырып тормый. Әле генә үзе туган төбәкнең тамашачыларын сөендереп кайткан Сәнифә җөмһүриятебез авыл-районнарына чыгып китә. Шул ук вакытта белемен күтәрергә дә җай таба. Бүгенге көндә Сәнифә Рангулова – Казан мәдәният һәм сәнгать академиясенең режиссерлар әзерләүче бүлегендә укый.

Сәхнәгә чыккан һәр артист үзенең тышкы кыяфәтенә, киеменә игътибар итәргә, зәвык белән киенә белергә тиеш.

Беренче тапкыр сәхнәгә кыска итәктән чыккан Сәнифә Рангулова да вакытлар үтү белән үзгәрә, камилләшә, җитдиләнә бара. Репертуарында халкыбыз җырларына зуррак урын бирелгән саен аның да сәхнә киемнәре үзгәрә – татар хатын-кызларына гына хас милли төсмерләр белән тулылана. Бу уңайдан аңа модельерлар Ольга Жукова, Галина Мартынова булышлык итә. Яңа өлгеләр алар ярдәмендә барлыкка килә.

Татар сәхнәсендә үз урынын тапкан җырчы Сәнифә Рангулова киләчәктә дә балкып янар өчен көч-сәләтен кызганмыйча эзләнүләрен дәвам итә, яңа концертларына әзерләнә, яңа альбомнарын әзерли. Ә тамашачылар аның белән яңадан очрашу шатлыкларын көтә. Шик юк: ул очрашулар вакытында да Сәнифә Рангулова үзенең күтелмәгән яңа яклары белән ачылыр, үзенчәлекле җырчы буларак күңелләрдә калыр. Чөнки ул үзе дә әнә: "Җырларым – канатларым минем..." – ди бит.

Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.

Үз-үзеңне ничек тотарга?

Хатынга булмый ярап

Биредә сүз үз-үзеңне гаиләдә ничек тоту турында бара. Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрнең яхшы булуына ирешү өчен унике кагыйдәне үтәү мөһим.

1. Ир белән хатын берберсенә ышанырга тиеш.

2. Ир хатынын, хатын ирен һичкайчан үзе теләгәнчә үзгәртергә маташмасын.

3. Үзегезнең якын кешегезне беркайчан да тәнкыйтьләмәгез.

4. Ир хатынына, хатын иренә ирек бирә икән, алар үзләре дә ирек алалар.

5. Хатынызгыга аның күркәм, өстен яклары турында сөйләргә онытмагыз.

6. Ирләр белән сөйләшкәндә аларның үзләре хакында сөйләгез.

7. Үзегезнең никахны үзегез генә саклап кала аласыз.

8. Хатынызга чәчәкләр бүләк итегез.

9. Зур булмаган гаилә бәйрәмнәрен ешрак үткәрегез.

10. Никахлашуыгызның беренче көннәреннән үк берберегезгә нәзакәтле булыгыз.

11. Гаилә тормышыгызны, туа торган төрле хәлләр иркенә тапшырмыйча, аңлы рәвештә оештырыгыз.

12. Ике җенес арасындагы мөнәсәбәтләр теориясе белән һичшиксез танышыгыз.

1-2 кагыйдәгә мисалларны гәзитебезнең узган санында басылган Наполеон, Лев Толстой, Линкольн гаиләләре үрнәгендә күрсәткән идек инде. Хәзер ир белән хатынның берберсен битәрләвенә тукталыйк. Гадәттә ир белән хатын бер-берсенең кечкенә генә кимчелекләрен дә күрүчән. Менә ир белән хатын яратышып яшиләр. Ләкин хатын иренең аз хезмәт хакы алуыннан зарлана. Бигрәк тә чит кешеләр алдында. Ире аңлый. Өстәмә эшләр ала. Эш хакы бер ярымга арта. Ләкин хатын ирен: "Өйдә ярдәм итмисең", – дип битәрли башлый. Ул ничәгә ярылырга тиеш соң? Хәлдән таеп эштән кайткач та аңа булыштың да ди. Хатын тагын гаеп табачак. Хатынга булмый гына бит ярап. Аның беренче таләпләрен үтәгәндә, ирлек дәрәҗәңне югалтып, аның төсле үк икенче хатын-кызга әверелергә кирәкме? Ә бит минем ирлек хокукларым да булырга тиеш. Әйтик, мин берәр көнне дусларым гаиләсендә булырга хокук алсам, икенче ял көнне хатын үзе дә шулай иптәшләре компаниясендә булырга хокуклы булып кала түгелме? Хатынны дусларына, кием тегүчегә, чәчтарашка яки театрга үзен генә җибәр – ялгыш булмастыр.

Хатын-кыз җылы сүзгә аеруча мохтаҗ. Уңай яклары турында үзенә әйтсәң, эреп китә инде ул.

Тормыш-көнкүрештә кешеләр гаҗәп күп кыенлыкларны җиңеп, төрле мәсьәләләрне хәл итеп яшиләр. Ләкин ир белән хатын тормышында сексуаль мәсьәләләр дә зур роль уйнавын онытырга ярамый. Кайчак әйбәт кенә кешеләр сексуаль мәсьәләдә берберсен канәгатьләндерә алмаган өчен аерылышалар. Димәк, сексуаль культураны үзләштерү дә мөһим.

("Как вести себя в любой компании" дигән китаптан).

НУРЗИЛӘ

Нурзилә – Кукмара якларыннан. Шигырьләрен, үзе әйтүенчә, сабый чактан яза. Аның иң яратканы – көз ае. Ләкин ул язлардан, җәйләрдән һәм кышлардан да ямь табып яши белә. Шигырьләре шул хакта сөйли.

Һәр күңелдә шигырь уты бар

Көз һәм без

Нигә инде көзне яратмыйсыз,
Табынасыз язлар,җәйләргә?!
Шуңа рәнҗеп,көзнең керфегендә
Ак энҗедәй яшьләр тирбәлә.

Гел мөлдерәп түгелергә тора
Нәүмизләнеп калган күңеле,–
Үгиедер, ахры, табигатьнең,
Сөйкемсезе, якын түгеле...

Үзәк өзгеч ачы, салкын җилләр
Бары көзгә генә исәдер;
Кешеләрнең салкын карашлары
Моңлы күңелен уттай кисәдер.

Шуңа әрнеп түккән яшь-яңгыры
Чеметтереп җанга коела.
Җанны гына түгел, тән өшеткән
Авыр сүзләр ишетү кыен ла...

Җитәкләшеп икәү китик, әйдә,
Бергә булсак, башны имәбез.
Бозлы сүзләр өтеп ала җанны...
Рәнҗетмәгез көзне, тимәгез!

***

Яңгыратып суктың
Җанның яңагына!
Юкса туган иде
Хисләр яңа гына.

Сөю яңа гына
Бөреләнгән иде...
Авыр сүзең җанга
Авырттырып тиде.

Очкыннармы очты
Җаным күзләреннән?!
Инде яшьләр тама
Сөю эзләреннән...

Алсу тышлы дәфтәр

Алсу дәфтәремне утка яктым
Дөрли-дөрли янды учакта.
Канатларын сары ялкын коча
Дөньялары сыймый кочакка.

Ак кәгазьгә тамган
шатлыкларым,
Сагышларым дөрли учакта.
Кичерегез,зинһар,кичерегез,
Хушлашу да кирәк кайчакта.

Елый-елый яна шигырьләрем –
Җылысы юк, салкын бөркелә.
Ут каршында бармакларым өши,
Йөрәгемә бозлы җил өрә.

Күңел күге тулы йолдызларны
Сызып ташлап кара бәгырьдән!
Беркем укымаган сүзләремне
Ялкын ятлый, ахры, хәтердән.

Мактанса да ялкын,
шәп булды,дип,
Ялмады тик каләм эзләрен, –
Йөрәгемә көчте әйтелгән һәм
Әйтелмичә калган сүзләрем.

Битем буйлап күз яшьләрем ага,
Ал күмердәй иренем пешереп.
Ут-ялкынның хәтта көче житми,
Хисләремне ничек яшерим?!

КИНДЕРГӘ КҮЧКӘН

Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов иҗатына багышланган мәкалә-очерклар күп язылды. Каләмдәшләре, тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият сөючеләр язучының әсәрләренә зур бәя бирәләр. Күренекле сүз остасы тынгысыз хезмәте һәм җәмәгать эше белән, татар халкының гына түгел, башка милләт укучыларының да ихтирамын казанды. Аның унбиш телдә 57 китабы дөнья күрде. Шуның унҗидесе урыс телендә басылып чыкты.

Әдипнең җәмәгать эшчәнлеге дә киң колачлы. Ул ике мәртәбә СССР Верховный Советына депутат булып сайланды. Элекке Союз вакытында унҗиде төрле җәмәгать эше алып барды. Аларның күбесе ил күләмендәге бик мәртәбәле, җаваплы эшләр иде. СССР һәм РСФСР Язучылары союзы секретаре, Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе булды. Өлкән яшенә карамастан, ул хәзер дә җәмәгать эшләрендә актив катнаша.

Еракларга танылган язучы, тормыш университетының түбән баскычыннан күтәрелеп, остаз дәрәҗәсенә ирешкән икән, бу – аның дистәләрчә еллар буегендә йөрткән татлы хыялы бит.

Яшүсмер Гариф Бөек Ватан сугышы елларында Красноярск краеның Березовка бистәсенә балигъ булмаган балалар колониясенә җибәреләә. Анда ул буяучылар бригадасын җитәкли.

– Колониягә ничек килеп эләктең? – дип сорыйм язучыдан, гаҗәпләнеп.

– Туган авылым Өчиледә яшәгәндә, рөхсәт-мазар сорап тормыйча, бер пот чамасы колхоз бөрәңгесен алып кайткан идем. Шуның өчен, суд ясап, мине Себергә озаттылар. Авыр вакыт – ашарга, ничек тә булса яшәргә кирәк. Кемнең ачтан үләсе килсен...

– Бригадир вазифасы авыр булгандыр? Ни дисәң дә, буяучылар – үзенчәлекле халык. Алар белән җитәкчелек итәргә, бирелгән эшне җиренә җиткереп башкарырга кирәк бит.

– Буяучылар әйбәт иде. Бригадабызда рәссам да бар иде. Александр Краснов. Мин аңардан рәсем ясауның серләренә өйрәндем. Ятим үсkәнлектән, буяу сатып алырга акчам юк, ә колониядә буяу мичкә-мичкә иде. Дөресен әйтим, шул заманнардан бирле мәшһүр рәссамнарның хезмәтләре белән кызыксынып яратуы, аның тылсымлы мизгелләрен җаны аша кичерүе, үзен табигать баласы итеп тоюы картиналарыннан да күренә. Диварга ябыштырылган бик зур, төсле фотообой да шул хакта сөйли. Анда куе урман, урман алдында күл гәүдәләнә. Бу фотообойның хикмәтле бер үзенчәлеге бар: Гариф дус урман күренешенә яңа төсмер биргән, детальләр "картина"га милли үзенчәлек керткәннәр, урман да киңәйгән. Күл янәшәсендә үсеп утырган каен төбендә аягына ак читек, өстенә бизәкле күлмәк һәм камзул кигән, башына өрфиядәй яшькелт яулык бәйләгән кыз, кулына гармун тоткан егет күренә. Еракта, урман артында – сыек томанга төренгән мәчет сурәте. Бу инде тулы бер фәлсәфә – табигатьтән, рухилыктан, мәхәббәттән башка тормыш юк, дигән сүз.

Язучының туган җиргә мәхәббәте аның әдәби әсәрләрендә дә мул чагыла. Мәсәлән, "Хәзинә", "Хуҗалар", "Идел кызы" романнарын мина уй-фикерләрен, теләк-омтылышларын даими рәвештә гамәлгә ашыра баруы дигән сүз. Басым ясап әйтик, аның иҗат чишмәсе кайнап тибә. Ә моңа бары тынгысыз һәм эзләнүчән каләм генә ирешә ала.

Мәкалә-очерк авторлары да Гариф Ахуновның хезмәт яратуын, ярдәмчеллеген аерым алып күрсәтергә тырышалар, әдипнең иҗатында, тормыш дөреслегенә тугры калуга аеруча игътибар итәләр. Чыннан да, язучы үз әсәрләрендә яңа темаларны кыю күтәрә, аларга бәйле мөһим проблемаларны мавыктыргыч итеп чишә.

Әйе, Гариф Ахуновның иҗаты хакында күп язылды. Бәс, шулай икән, мин аның роман-повестьларына кагылышлы яңа фикер әйтә алмам. Әдип турында башкалар әйткән: "Язудан арыса, кулына пумала алып, табигатьнең матур күренешләрен киндергә төшерә", – дигән җөмләдән гайре берни язылмаганын истә тотып, Г.Ахуновның икенче яраткан шөгыле – сынлы сәнгатьтәге иҗаты турында күптән әйтәсе килеп йөргән уй-фикерләремне укучыларга җиткерергә булдым.

Әйе, ул, язудан арыса, кулына пумала ала. Сынлы сәнгать серләрен шактый үзләштергән һәвәскәр рәссам киндердә пумаласын ышанычлы йөртә – озакламый киндердә күңелне җәлеп иткән табигать күренеше пәйда була.

Үз хезмәтендә балачактан ук таныш, җанга газиз булган елга-тугайларның, урман-әрәмәләрнең хозурлыгын тасвирлауга ирешкән икән, димәк, Гариф Ахунов вакытын бушка уздырмый. Аннары тагын шуны да әйтергә кирәк, булачак әдип беренче сыйныфтан ук рәсем ясый, авылда таң ату, кояш баюларны күзәтеп яши. Табигатьнең әнә шундый гүзәл мизгелләре, гомерлеккә онытылмас булып, балачактан ук күңел түренә кереп урнашалар.

Гариф Ахунов, әдәби әсәрләрен язгандагы кебек, рәсем сәнгатендә дә иҗат газаплары кичерә торгандыр. Бу шөгыле дә – дистә еллар буена аның күңеленә тынгы бирмәгән, йөрәяшим, картиналарына карап сокланам.

Язучының эш бүлмәсендәге диварда "Туган авылым Өчиле" дигән картина эленеп тора. Автор анда Казансу елгасының текә ярыннан арырак урнашкан авылны сурәтли. Гарифнең әтисе Ахунҗан агай җиткергән каралты-кура башка өйләрдән зуррак булуы белән аерылып тора. Лапаслар артындагы зур агачлар күккә терәлгәндәй утыралар. Картинаның алгы планында Казансу елгасы гәүдәләнә. Яр астында, су буйлап биек булмаган агачлар тезелешеп утыра. Зифа буйлы камышлар да елгага ямь өстиләр. Тирә-юнь җәйге хозурлыкка төренгән.

Гариф бу картинасын балачак, яшүсмер хатирәләреннән чыгып язган. Әтисе заманында әнә шундый йорт җиткергән булган. Ул күмәк хуҗалык оештыруда актив катнаша, колхоз рәисе була. Ләкин кулаклар моны кичермиләр – Ахунҗан агайны, бандитлар яллап, үтертәләр. 1931 елда гаилә, шул исәптән алты яшьлек Гариф әтисез кала.

– Ул заманда гаиләбез шундый югалтуны һәм ятимлекне нык татыган иде, – ди әдип. – Мин бу картинаны әтием истәлеге булсын дип яздым. Хәзер Өчиле авылы үзе дә юк инде. Аның җир йөзеннән юкка



"Туган авылым Өчиле". Г.Ахунов рәсеме.

чыгуына колхозларны эреләндерү кәсәфәте сәбәпче булды. Минем әсәрем туган авылымны да искә төшереп тора. "Йолдызлар калка" повестемда да яшьлек елларымның онытылмас хатирәсе саклана.

Каләм остасының табигатьне салга алып була.

– Табигать күренешләрен киндергә төшерү өчен теләк-омтылыш кына җитми. Аның өчен рәсем ясау алымнарын, буяуларны табигать халәтеннән чыгып куллана белү дә кирәк бит әле. Син, Гариф, бу хакта ничегрәк диярсең, кемнәрдән өйрәндең?

– Баштан ук шунысын әйтим: Көнбатыш илләренең берничәсендә булдым, алардагы шәһәр музейларында урта гасыр, соңгы йөзләрдә иҗат ителгән, бөтен дөньяга билгеле, мәшһүр рәссамнарның картиналары белән таныштым. Мин, теге яки бу илнең мәркәзенә килү белән беренче булып, сынлы сәнгать җәүһәрләрен карарга юнәлә идем. Соңгы өч гасырда иҗат иткән урыс рәссамнарының хезмәтләре белән дә танышмын. Татарстан рәссамнары Б.Урманче, Х.Якупов, В.Кудельkин, Л.Фәттахов (ул минем "Хәзинә" романына иллюстрацияләр ясаган иде), М.Усманов, Г.Рахманкулова, А.Абзгильдин, И.Зарипов һәм башкаларның хезмәтләре миндә бик җылы тәэсир калдыра. Алар иҗат иткән картиналарның күбесе күз алдымнан китми.

– Сиңа аларның этюдлар яки картиналарын ничек язганнарын карап торырга туры килмәдеме?

– Нигә туры килмәсен! Андый халәтне кичергән чакларым аз булмады. Әйтик, Гайшә Рахманкулованың, Виктор Кудельkин, Харис Якупов, Илдар Зарипов, Мәхмүт Усманов, Рәшит Имашев һәм башкаларның иҗади эш процесcларын күзәткәнем, үзем өчен кирәкле алымнарны, кем әйтмешли, мыегыма чорнаган чаклар аз булмады.

– Урыс рәссамнарыннан кемнәрнең хезмәте сиңа ошый һәм ни өчен?

– Якташыбыз Иван Шишкин – туган якның, дөресрәге Алабуга табигатенең гүзәллеген җырлаучы рәссам. Ул миңа киндерләрендә табигатьнең бөеклеген, илаһи көчен нечкә чагылдыруы белән бик якын. Константин Коровин картиналары милли күренешләргә бай. Чөнки аның әсәрләре

ГҮЗӘЛЛЕК



● Гариф Ахунов яраткан шөгылен дәвам иттерә.

Русия чынбарлыгы белән тыгыз бәйләнгән, алардан күңелгә рәхәтлек бирә торган, йөрәктә җылы хисләр уятырлык мотивлар күп.

– Ә Исаак Левитан картиналары нинди тойгылар уята?

– Мин аңа Русия табигатенең лирик ташкынын үз тойгылары аша башкаларга ирештерүче оста дип карыйм. Ул – "көеф пейзажы" рәссамы. Аның киндерләре сагыш һәм моң белән тулы. Тормышта да Левитан бик үзенчәлекле була: барлык хатларын утка яга, миннән соң архивымда казынучы булмасын, ди. Әмма аның шатлык тудыручы әсәрләре дә бар. И.Левитанның "Март" исемле хезмәтен алып карыйк. Бу әсәрдә яз башында табигатьнең кышкы йокыдан уянуы, зәңгәр күктән ак кар өстенә якты нурлар иңүе, карасу-кызгылт төстәге ботаклардан беренче тамчылар тамасын һәм рамга тарттырып грунтлаган буш киндер бүләк итте. Ул: "Моңа син, Гариф ага, үзең телəгән пейзажыңны яз, иҗат газаплары кичер!" – диде.

Мин язучының фатирында бүлмәдән бүлмәгә картиналар, этюдлар, натюрмортлар карап йөрим. Кайчагында Гариф миңа ярдәмгә килә – аңлатмалар бирә. Билгеле, фатир диварларында әзер киндерләр эләр өчен урын

телгә алдың. Мин дә шулай уйлыйм. Язучымы син, рәссаммы – әсәрләрең аша фәлсәфә бирү лазем. Шулай дигәннән, Литва халкының күренекле композиторы һәм рәссамы Чюрленис искә төште. Ул шундый булган. Ул безгә киндергә төшерелгән хезмәтләре белән гүзәллекне җырлаучы шагыйрь һәм философ буларак кадерле...

– Чынында, күптән мәрхүм булган Микалоюс Чюрленис минем өчен дә кадерле, – дип сүзен дәвам иттерде Гариф Ахунов. – Ул, композиторлык эшчәнлеген ташлап, сынлы сәнгать мәктәбен, аннары академияне тәмамлый. Рәссам булып дөньяга таныла. Аның "Яз сонатасы", "Җәй сонатасы" кебек киндерләрендәге төсләрнең өрфия дулкыннарында музыканың моңлы һәм акрын агышын тоясың. Икенче төрле әйтсәк, рәссам үз әсәрләрендә сүз белән белдереп булмый торган кичереш-хисләрне чагылдыра. Шунлыктан Чюрленисның моңнары белән өретелгән пейзажларын дулкынланмый карау мөмкин түгел.

Язучы белән сынлы сәнгать турында, аның күренекле вәкилләре – рәссамнар хакында әңгәмә корганда, мин шунысына да инандым: Гариф Ахунов сынлы сәнгатьтә төшеп калган кеше түгел. Ул әлеге сәнгатьтә тирән эз калдырган һәм хәзер дә иҗат итүчеләрне яхшы белә, аларның хезмәтләре белән даими танышып тора. Аның шкафында дөнья рәссамнарының 250 альбомы бар...

Әдипнең матур сыйфатлары балалары һәм оныкларына да күчкән. Гариф һәм тормыш иптәше Шәһидә (ул да язучы) үзләренә лаеклы алмаш үстергәннәр. Уллары Рәшит тә, кызлары Наилә дә – язучылар. Кияүләре Борис Сулимов та алардан калышмаган. Наилә – шагыйрә. Ул рәсем мәктәбен тәмамлаган, әле һаман осталыгын чарлый. Аның кызы Һидая – яшь рәссам. Ана белән кыз шәхси күргәзмәләрен дә оештырырга өлгергәннәр инде. Алар рәсем-иллюстрацияләре белән "Салават күпере" журналында катнашалар. Һидая Русия һәм Англиядә үсмерләр өчен ике телдә чыга торган "Вместе" журналы редколлегиясе әгъзасы да икән. Кыскасы, Ахуновлар гаиләсе иҗатчылар берлеген тәшкил итә. Димәк, өлкәннәрнең балаларын олы тормыш юлына чыгарудагы тырышлыклары бушка китмәгән.

Мин Гариф Ахуновның повесть-романнарында табигать нигә шулкадәр җанлы икән, сулыш алып тора икән? – дип аптырый идем. Аның рәсем сәнгате белән дә шөгыльләнгәнен белгәч, аңладым. Димәк, табигатькә ул рәссам күзе белән карый. Мирсәй Әмир роман-повестьлары белән дан алды. Нури Арсланның шигырьләре җырлап тора. Аларның икесе дә Казанның сынлы сәнгать техникумын тәмамлаганнар. Нури ага "Пионер" (хәзерге "Ялкын") журналында, "Яшь ленинчы" (хәзерге "Сабантуй"), аннары "Совет Татарстаны" (хәзерге "Ватаным Татарстан") гәзитләрендә рәссам булып та эшләде.

– Гариф, күп һөнәрле булуга ничек карыйсың? – дип сорау бирдем.

– Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, – диде халык язучысы.

муы – табигатьтә тантаналы рәвештә бөек яңарыш башлануы тасвирлана.

Мин Г.Ахуновның "Идел тугаенда көз" дигән киндерен "көеф пейзажы" сериясенә кертер идем. Чөнки аңа күз төшерү белән, үзеңне култыкланып кергән су янында, алтын яфраклары белән көязләнеп утырган каеннар каршында басып торгандай хис итәсең. Шунда ук ямь-яшел нарат-чыршылар җәелеп утыра. Алар синдә күтәренке көеф тудыра. Автор көзнең үзенә генә хас матурлыгын әйбәт тотып алган, төсбуяуларны әнә шул гүзәллекне гәүдәләндерү өчен кулланган. Мин әйтер идем, авторның бу әсәре һичшиксез уңышлы.

Язучы "Идел тугаенда көз"ен каләмдәшләре Ринат Мөхәммәдиевкә, Аяз Гыйләҗевкә, "Пушкин табигать кочагында" исемле хезмәтен – Марс Шабаевка, "Инеш ярындагы имән"не – Лирон Хәмидуллинга, "Шарлавык" (Кавказ күренеше) исемле картинасын Әхмәт Гаделгә һәм тагын унбишләп киндерен дусларына, туганнарына бүләк итә. Бүләк иткән әсәрләре арасында акварель белән язган "Истанбул мәчете" дә бар. Алары А.Гыйләҗевтә, Фәрваз Миңнуллин фатирларында һәм зуррак вариантлары авторның үзендә саклана. Гариф Ахуновның үзенә бүләк ителгән картиналар да байтак. Әнәс Тумашев, Эрот Зарипов, Мәснәви Хәйретдинов, Рәшит Имашев, Виктор Кудельин, Сергей Лукашев, Степан Неустроев, Гаишә Рахманкулова, Мәхмүт Усманов, Фәйзерахман Әминов, Җәүдәт Булат, Хаҗиәхмәт Казаков, украин Микола Неклюенко кебек танылган рәссамнар, әдипкә истәлек итеп, ихтирам белән үз хезмәтләрен бүләк итәләр. Гомумән, язучының фатирында чит ил рәссамнары, сынлы сәнгать осталары бүләк иткән киндерләр һәм скульптуралар да бар. Ул аларны кадерләп саклый.

Ә менә әдипкә 70 яшь тулу уңаеннан, Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе Абрек Абзгильдин аңа Татарстан сынлы сәнгать осталарының өч карти-

аз. Ни дисәң дә, фатир музей залы түгел бит.

Дүрт дистәләп картина язган әдип. Төп көчен әдәбиятка багышлаган, зур-зур романнар, повестьлар, әдәби портретлар, пьесалар иҗат итеп, укучыларны шатландырган язучы өчен дүрт дистә картина аз түгел. Мин аларның кайберләрен генә телгә алам. "Казансу буендагы урманнар" әсәрендә Казан елгасы тулып ага.

– Сугышка кадәр, мин белгәндә, Казансу тирән иде. Балыкчылар аңардан, язгы ташулар кузгалган чакта, җәтмә белән чиләк-чиләк балык тоталар иде. Мин әлеге картинаны хәтердән, сугышка



● "Елга буенда йортлар".

кадәрге елганы истә тотып яздым.

– Шулайдыр шул, – дим мин һәм "Кышкы урман юлыннан" дигән әсәре янына тукталам.

Кышкы урман үзенчә матур. Ул тирән тынлык кичерә. Агач ботакларында мендәр-мендәр кар. Һәр тараф сөттәй ап-ак булып күренә. Әнә Әйе, тынлык биредә, тынлык. Әнә шул тынлыкны бозып, урман юлыннан кашавай чанага җигелгән ат җилдерә. Чанага ир-ат һәм хатын-кыз утырган. Күрәсең, бу пар күрше авылга кунакка бара. Сугышка хәтле кашавай чаналарда авылдан-авылга кунакка йөрү гадәти хәл иде. Хәзер замана башка, транспорты да икенче. Ә шулай да еракта калган онытылмас елларны сагынып искә аласы килә...

– Минем дулкынландыргыч картиналарым язылмаган әле, – ди Гариф. – Аларда, маңгайга чиртеп әйтелмәгән фәлсәфә булырга тиеш.

– Син, Гариф, "фәлсәфә" сүзен

Касыйм ТӘХАУ.

Мидхәт ШАКИРҖАНОВ фоторәсемнәре.

Беломырдины кем тагын?

Петрозаводскида яшәүче берәү дус-ишләреннән мәче баласына берәр ят исем табарга булышуларын сорый. Никтер, тәкъдим ителгән исемнәрнең барысы да Русия сәясәтчеләренең исем-фамилияләре булып чыга. Мәче хуҗасы мин сәясәт белән кызыксынмыйм, ди. Һәм... мәче баласына Беломырдин дип исем куша. Чөнки кара мәче баласының бите генә ап-ак икән.

Борис патша туганы

Бурятия башкаласында Б.Ельцинның туганы Савелий Ельцин яши икән. Ул республиканың фәнни-техник мәгълүмат үзәге җитәкчесе, Б.Ельцинның бабасы аның бабасының бертуганы икән. Ләкин шул чыбык очы туганлыктан башка бу Ельциннарның уртаклыгы юк, икесе бер яшьтә дисәк кенә инде. Байкал артында яшәүче Ельцин – коммунистлар партиясе активисты, бүген дә актив эш алып бара.

Залны өркеткән Шифрин

Сатира жанрында эшләүче артист Ефим Шифрин Роман Виктюк театрында "Путана" ("Урам хатыны") спектаклендә уйнаганда, сәхнә буйлап кулына пычак күтәреп чабып йөри. Бер артык хисчән тамашачы, куркып, тамаша залыннан чыгып ук китә.

Калганнар, артист сценарий буенча уйный бит, дип утыралар. Шифрин спектакль ахырында залга тамашачылар өстенә папье-машедан ясалган алагаем зур йомырка ташлагач, сикерешеп торалар. Йомырка партерда утырган берәүнең башына килеп төшә.

Спектакльдән соң артист янына сәхнәгә автограф алырга менгән тамашачының йодрыгы йомарланган була, артистка әйткән сүзләре генә залга ишетелми кала.

"Яблоко"ның туган көне

Татарстан делегациясе Мәскәүнең архитекторлар йортында "Яблоко"ның туган көне мәҗлесендә катнашты. Өстәлдәге ризыкларның күпчелеге алма кушып пешерелгән пироглар, алма кайнатмасы белән чәй, алма суы...

Гадәттә Г.Явлинский партиясе сюрприз эшләргә маһир. Бу юлы да шулай булды: бер зур лампа шартлап, авыр тәрәзә пәрдәләренә ут капты. Якында ут сүндерү җайланмасы булмагач, кем ничек – шулай янгын сүндерергә кереште: шторалны сөйрәп төшереп, таптадылар. Соңыннан "Яблоко" юлбашчыларының берсе – Лукин янган табанын да күрсәтеп йөрде. Кунак булып чакырылган Михаил Горбачев: – Русия яңадан төтенли! – дип трибунадан шаяртып алды.

("ВК").

Хакыйкать бәхәстә туа

Тел фетнәсе

СССР таркалуыннан файдаланып, Татарстан да мөстәкыйль дәүләт булуын белдерде, ә халык, үзен башка дәүләтләрдәге халыкларга тиңләп, дәүләтле һәм телле булуына өметләнде: дәүләт тамгалары булдыруны, татар мәктәпләре ачылуны, дәүләт теленең татарча булуын, хәтта алфавит үзгәртелүен дә таләп итә башлады. Халык һаман шаулады, даулады, ләкин эшнең кая барып терәлүен аңлагач, тынып һәм гамьсезләнеп калды. Озакка сузылган дәгъвалар берничә татар мәктәбе ачылуга, сүзсез (текстсыз) гимн кабул итүгә генә кайтып калгач, халык хыялый өметләре белән саубуллашып, Русия Федерациясе Конституциясе кушканча яши башлады шикелле.

Дөрес, дәүләт атрибутларын истән чыгармас өчен Татарстанның Конституциясе дә, Президенты да бар, ләкин Русиядәге халыкларны бүгенге мөшкел хәлгә төшерү өчен бер конституция дә җитәр иде.

Беренчедән, халык фәкыйрьләнде, чөнки аны хөкүмәт алдады. Аның гражданлыгын да билгеләү мөмкин түгел.

Икенчедән, халык үзен җилкәнсез көймәдә йөзүче итеп сизә башлады – кая юл тотасын белми, чөнки аның хокукларына беркайда да эш тапмау кебек "хокуклар" да өстәлде.

Өченчедән, аның теләкләрен дә, таләпләрен дә санга сугучы яки ишетүче калмады. Ил башында торучы затларның да вәгъдәсез булуын кат-кат күргәч, халык нишләсен?

Дөрес милли горурлык хисен сакларга, югалтмаска тырышучы галимнәр, шагыйрьләр, журналистлар, сәнгать осталары һәм дин әһелләре ара-тирә тел мәсьәләләренең яңадан, халык теләгәнчә хәл ителүен таләп итеп, талпынып карадылар. Ләкин аларны ишетмәделәр. "Закон кабул ителде бит, димәк, Дәүләт Советы халык сүзенә игътибарсыз калмаган", – диючеләргә җавапны болай бирергә булыр иде: ул закон кабул ителмәсә, без нәрсә оттыра идек? Автономияле чакта телгә игътибар зуррак иде. Гәзит-журнал алучылар саны мең тапкыр күбрәк иде, халык ике телдә дә күп укый, моның өчен закон кирәк түгел иде. Телне дәүләт теле итү өчен генә кирәк ул закон! Ә өйрәнү өчен теләк кенә кирәк.

Телләр турындагы законның кабул ителүе нинди үзгәреш китерде?

Сүз аның үтәлмәве турында түгел (үтәлә торган законнар, гомумән аз яки юк), ә бөтенләй мәҗбүри булмавында. Мәҗбүри булмаган законнарның берсе дә үтәлми һәм алар күп. Инде шушы ук мәсьәләгә башкача, бүтән яссылыктан күз салыйк: ни өчен телләр турындагы закон шатландырмый? Бу сорауга җавап мәкальдәгечә килеп чыкты: балта сораучыга шөшле бирделәр.

Реформалар турында сүз барганда аларның элек урнаштырылган тәртиптән камилрәк, файдалырак һәм төгәлрәк булуын көтәләр. Шулай булмаганда "реформа" төшенчәсе асылын югалта.

Табигый сораулар туа: халыкны бертуктаусыз алдау, фәкыйрьләндерү, түземлелеген сынау реформамы, юкмы? Моның бер очы бармы? Уңышсыз законнар "иҗат" итүнең сәбәбе нәрсәдә? Бәлки демократик юлдан тайпылуны гына булса да халыктан яшермәскә кирәктер? Чөнки беренче урынга икътисади таләпләр килеп басты һәм Русиядәге сәяси ыгы-зыгының дәвам итүе исән калу өчен көрәшне беренче урынга куя, тел – һаман соңыннан.

Тарихи агымны төгәл һәм дөрес сиземләүчеләр илдә бар, әлбәттә, алар үзләрен дә, дәүләтләрен дә таныттылар инде.

Һич югында бер генә закон – татар телен дәүләт теле итеп кабул иткәндә дә республиканың киләчәктәге халәтен төсмерләү ансатрак булыр иде. Ә моңа ирешеп була иде, ләкин тел белгечләренең һәм кайбер галимнәрнең "тыйнаклыгы" (гамьсезлеге дияргә тел әйләнми), зәгыйфь темпераментлы булуы барысын да хәл итте, кирәкле сүзне кирәкле вакытта алар әйтә алмады. Танылган академиклар сүзе дә ул көнне ишетелмәде.

"Алар фән белән мәшгуль, вакытлары булмагандыр, дәүләт эшен алар хәл итәргә тиешмени?" диючеләр хаклы түгел. Бу көнне микрофон алдында академиклар торырга тиеш иде, фәнни фикер депутатларга да тәэсир итми калмас иде! Ә инде телләр турындагы закон 1990 елда ук кабул ителгән булса, бәлки күп кенә әһәмиятсез законнарның кирәге дә булмас иде.

Татарлар урысча сөйләшәләр. Чөнки татарларны урысча сөйләшергә тормыш кына өйрәтмәде, аны "партия тирәсендә тагын да ныграк туплanyрга" чакырып торучы "өйрәтүчеләр" табылып торды. Читтән генә торып авыл хуҗалыгы институты "тәмамлаган" кайбер "беренчеләр"гә кадәр безне урысча сөйләштерде...

Чөнки ул заманда укымышсызлык та өстән, үзәктән җибәрелә иде.

Әнә, Горбачевтан әле һаман да көләләр, чөнки тел ул фикер йөртү дәрәҗәсен дә чагылдыра. Аның "процесс пошел", "договор", "ложу" диюләре мәзәккә әверелде.

Әйе, телнең корал икәнлеген дә истән чыгармаска кирәк, безнең бөтен өметебез, киләчәгебез телгә төбәлгән иде. Ләкин хак сүзнең олы кисәген публицистлар, язучылар гына түгел, дәүләт әһелләре дә, танылган галимнәр дә әйтергә тиеш иде. Хәзер телләр турындагы законда бер генә телнең, татар теленең дәүләт теле итеп белдерелүе дә аны тиз генә аякка бастыра алмаячак – моңа әзерлексез булу үзен озак сиздерәчәк, хәтта андый закон кабул ителсә дә, гамәлләштерү аз дигәндә дистәләрчә елга сузылыр иде.

Ләкин бу законның юклыгы татар халкын хыялдан да мәхрүм итә. Мәскәүдә тел галимнәре моннан берничә ел элек "Урыс телен саклау комитеты" төзү хакында, аның дәүләт структурасына кертелүен хупларга әзер торуларын белдерделәр. Әйтерсең, урыс теленә ни дә булса яный, әйтерсең, урысча сөйләшү мөмкинлеге югалу алдында тора. Мәскәү урамнары чит телдә язып эленгән һәртөрле такталардан да арына башлады, Моссовет бу хакта карар чыгарды, димәк, бу – мөһим эш.

Үрнәк алу сәләтебез әлегәчә яшәп килде, бәлки тарихи ситуациянең андый нечкәлекләрен дә тел сәясәтендә куллану ярыйдыр – ахыр чиктә, кытайлар әйтмешли, песи нинди төстә булса да тычкан тотарга тиеш.

Казан урамнарының исемнәре әле дә дөрес язылмый (1 май урамы, Лумумбы урамы, Хади Такташ урамы, Аяк киемнәре тукталышы, Парина урамы һ.б.). Бу хакта күпме сатирик чыгышлар ясалды, ә җирле хакимият моны күрми дә, ишетми дә, укымый да.

"Тел, тел..." дия-дия чаптылар инде татарлар – айлар, еллар буена гәзитләр бу темадан арына алмый. "Латинча язык" диючеләргә авыз ачарга да ирек бирмиләр: юк, ияләнгәнчә язык, болай да бик күп мәдәни мирастан колак кактык, монысын булса да саклап калыйк, диләр. Янәсе, бөтенләй телсез калуыбыз ихтимал, гасыр саен бер халык та телен "көчләми", болай газапламый, һаман үзгәртеп яки бозып торганга күрә иң укымышсыз халыкка әверелдек, инде дөрес язучылар гына түгел, дөрес итеп сөйләшүчеләр дә бик аз калды.

Татарстанда кабул ителгән яңа законның исеменә игътибар итик: закон телнең өйрәнелүен һәм үсүен (камилләшүен) дә таләп итә бит! Менә шул хакта сөйләшергә, шул хакта бәхәсләшергә вакыт!

Бу бәхәс әлифбабыз нинди рәвешкә керсә дә дәвам итәргә тиеш. Дәвамлы бәхәс зарурлыгын билгеләүче сәбәпләрнең берничәсе миңа да мәгълүм. Әйтик, чит тел сүзләрен үзгәрешсез кабул итү дәвам итәчәкме? Әллә алар "бераз" тәрҗемә ителергә тиешме? "Прожиточный минимум" төшенчәсен уйлап тапкан ахмакны шатландырып, татарлар бу ике сүзне фәнни терминга әверелдерергә, аңа өстәп, "куллану кәрзине" кебек шөкәтсез гыйбарәләрдән файдаланырга мәҗбүр ителделәр. "Малообеспеченные слои населения" кебек сүзтезмә татарларга кирәкме? Кирәк булса, фәкыйрь, ярлы, хәерче, ачялангач кебек сүзләребезнең урыны кайда соң?

"Сүзгә-сүз" дигән үҗәтлектән хасил булган тәрҗемә сүзләр телне көннән-көн ямьсезли, боза, пычрата. "Ассызыклап сөйләшү", "ассызыклап әйтү" гамәлгә кереп бара. Басым ясап әйтергә, аеруча искәртеп әйтергә булмыймыни? Авыздан чыккан сүзнең астына сызык сызучы-ассызыклаучы наданнарның кайберләре мәктәпләрдә, редакцияләрдә эшләве тел сагында торучыларны аеруча борчый.

Матбугат чаралары "ярдәмендә" (андагы мәгълүматларның радио һәм телевидение аша яңгыравы да күздә тотыла) дә татар телен бозу уңышлы дәвам итә.

Игътибар белән тыңласагыз (укысагыз), еш кына матур һәм гади сүзләрне бөтенләй кирәксез кушымчалар белән "бизәүче" авторлар белән таныша аласыз. Миңа, мәсәлән, "Тапшыруыбызның ахырында тамашачыларыбызны мәркәзебездәге һава торышы белән таныштырабыз" яки "телебезне, мәдәниятебезне, динебезне саклауда гәзитләребез, галимнәребез, дин әһелләребез өлеше...", "үзебезнең күзебез", "мәчетебездәге аебыз", "үзебезнең милләтебез, галимебез" кебек "быз-без"ләүне тыңлау (уку да) бернинди ләззәт китерми, киресенчә, мондый төчелек ачуны гына чыгара. Телне хөрмәтләүче "телебез" дип сөйләшми, чөнки телне сакларга, өйрәнергә, үстерергә омтылучы кеше татар телен бозучылар(ыбыз) белән бер сафта атларга теләми. Тел турында законнар кабул ителгәч, тел бозучыларны җинаятьче итеп күрү, аларны гаепләү дә гамәлгә керергә тиеш булып чыга бит. Эшләр алайга ук китмәс, әлбәттә, телен белмәүчеләрне дә җәзалый башласалар, надан милләтчеләр әйтмешли, "төрмәләребездә җинаятьчеләребезгә урыннарыбыз" җитмәячәк.

Йомгаклап, тел сөючеләргә шуны белдерәсе килә: телне өйрәнү һәм үстерү акылга, теләккә, омтылышка бәйле булса, татар халкы бу вазифаны җиренә җиткереп башкарачак, дәүләт югарылыгындагы игътибар (күпкырлы гына була күрсен!) бу эшне хәтта җиңеләйтер дә иде. Ә инде телне саклау, аны буыннан буынга әдәби һәм тарихи язмалар рәвешендә тапшыру өчен барлык ысуллар да файдалы. Ягъни теге яки бу әлифбага күчү төп мәсьәлә түгел, ул – иярчен эш, икенчел вазифа, аны ашыгып та, кичегеп тә гамәлләштерергә ярый. Ләкин кампитрлар чорында яшәүче дөньяда кампитрлар телендә дә сөйләшү һәм язышуга җайлашкан илләр исемлегендә Татарстан соңгы урында тормаска тиеш. Латин графикасына күчү – зарурлык ул, торабара аны кабул итмәүче телләр (илләр) калмаячак, чөнки фән һәм техника ачышлары шуны таләп итә.

Амур ШАКИРҖАНОВ.

Ышансаң — ышан, ышанмасаң - юк

ТЫЛСЫМ ИЯСЕ

Мәскәү университеты профессорының голографик күрү турындагы гипотезасын Вятка Аланы тикшеренүчесе гамәлдә раслый

Болгариядә яшәгән сукыр күрәзәче Ванганың бар нәрсәне күрүе хакында күп язылды. Картаеп хәлсезләнеп яткан чагында аңа урлаган оныгын табуда булышуын сорап бер нимес килә. Ләкин Ванга: "Сиңа Русиядән гомерендә бер тамчы спиртлы эчемлек эчмәгән, бер генә сигарет та тартып карамаган мөселман кешесе ярдәм итәр. Мин аңардан имтихан алган идем", дип киңәш кенә бирә алган.

Шул ук көнне Вебер әфәнде Мәскәүгә оча. Ләкин иксез-чи-

дә киңәш иткән. Тик бу мәгълүматларны нимес ягына Алманиянең Мәскәүдәге илчелеге аша тапшыру гына озак һәм бик мәшәкатьле булып чыга. Калганы полициянең осталыгына бәйләнгән. Тотучы төркемгә почтальон ярдәмгә килә. "Телеграммаkны алу өчен" караклар үзләре ишек ачканнар.

Әлегрәк Рамил үз илебездә дә югалган әйберне табуда әйбәт кенә булышкан, дөресрәге хәйләкәр клиент кассирдан оста итеп яшергән зур суммадагы акчаны Вятка-банкка кайтарырга ярдәм иткән. Күрәзәче киңәше белән

ксез Русиядә "аракы эчмәүче, тәмәке тартмаучы мөселман" дигән сыйфатлары буенча гына ул кешене ничек табасың!.. Шулай да Вятка Аланы шәһәреннән Рамил Гарифуллин дигән шундый кешене эзләп таба ул. Һәм шул ук көнне Вебер әфәнденең онытгы Алманиядә өенә кайтартыла. Баланы коткару операциясенә Русиядән торып күрәзә ысулы белән Рамил Гарифуллин җитәкчелек итә. Бу ысулны ул үзе урысча "ясновидение" дип атый икән.

Ул болай эшли. Күзләрен йомып, баш һәм имән бармагын борын төбеннән өскәрәк куеп, күңелен тиешле объектка юнәлдерә. Әкияттәге "маңгаенда йолдыз балкый" дигән сүзләр искә төшә. Фән әле төгәл нәтиҗәләр ясамаса да, МГУ профессоры Юрий Пытьев (ул физикада кампитр методлары кафедрасы мөдире) биш елдан артык инде голографик күрүчеләрне, ягъни күзләрен йомган хәлдә күрә белүчеләрне өйрәнеп, моңарчы фәнгә билгеле булмаган күрү кыры – күрәзә ысулы белән күрүчеләрнең маңгай үзәгендә булуын ачыклаган. Фәнни телдә әйткәндә, эчке күрү сәләте әлеге үзәктән җибәрелә торган нурларның ни дәрәҗәдә көчле булуына бәйле.

Ә бу сәләт Рамилдә гаять көчле, гүя ул эчтән балкып тора. Күзләренә карасаң, кампитр экранына карагандай буласың. Шулай да аңа күз йомып яки ерактан күрү җиңел генә бирелми. Маңгаендагы борын төбеннән башланып киткән ике параллель тирән сыр япь-яшь йөзендә юкка гына барлыкка килмәгән. Бу очракта да Киров өлкәсеннән Алманиядәге хәлне күрә алу җиңел эшмени! Кызчыкны бөтенләй башка шәһәргә яшергән булганнар бит. Әмма Рамил аны ничек урлаганнарын, аны кайда яшереп тотканнарын, ничә кеше саклаганын төгәл тасвирлаган һәм хәтта каракларны тоту төркеменә ничә кеше алырга кирәклеген

үз счетыннан акчаны алганда күз буяучы берни дә әйтә алмаган. Бер шофер күршедәге Удмуртия колхозыннан ЗИЛ двигателен урлаган була. Рамил ярдәме белән двигательне яшергән урыннан килеп тапкач, әлеге шофер берни әйтә алмас булып телсез кала. Кибән эченнән инә табарга алыныр идеме икән Рамил, әйтүе кыен, ә көнче ире тарафыннан эзәрлекләнгән хатынның никах балдагын кар көрте эченнән табып бирә ул. Чын могҗизачы. Могҗиза тудыручыларга хас рәвешчә, Рамил дә беркатлы. Ул үзенең тиңдәшсез гамәле өчен нимес Вебер әфәндедән дә акча алмаган. Аның Алманиядә үзенә шәхси лаборатория тәкъдим итүенә дә елмаю белән генә җавап биргән. Бәхетле нимес карты бу гаҗәеп кешегә үзенең рәхмәтләрен җирле гәзит аша белдергән һәм Рамилне кайчан да булса үзенә кунакка килергә чакырган.

Рамил үткәндәгеләр, бүгенге һәм киләчәк белән ничек хәбәрләшә соң? Үзе әйтүенә караганда, ул үз дөньясына чума да эчке бер тоемлау белән гадәти телевизор экранындагы кебек күренешләрне күрә. Ләкин бу сихри кинозалга керү өчен Рамилнең үз ачкычы бар. Фотография, почерк, кыяфәтен сурәтләп бирү кебек факторлар да роль уйный. Әгәр экранда кара тап эленеп торса, ул информация тоткарланганны аңлата.

Фән читтән торып күрү (ясновидение) сәләтенең серен ача алганы юк әле. Ләкин күп кенә тикшеренүчеләр җир тирәсендә информацион энергия кыры барлыгын раслаганнар. Ул кайчандыр яшәгән, яшәүче һәм киләчәктә яшәячәк рухларның берләшүе рәвешендә күзаллана. Җир ге ... бит Галәмнең кечкенә бер кисәкчеге генә. Җир тирәсендәге энергия кыры Галәмдәге мәгълүматлар хәзинәсе белән элемтәдә тора. Фәндә ... бик ...

Җир тирәсендәге мәгълүматлар ...

дан һәркем азмы-күпме файдалана. Еш кына аналар йөзләрчә чакрым ераклыктагы баласына бәхетсезлек килүен алдан сизүчән булалар. Кайчак ул төштә күрү рәвешендә була. Кайбер галимнәр төшләрендә зур ачышлар ясыйлар. Менделеевның химия өлкәсендәге мәгълүм таблицасы шундыйларның берсе. Язмышны алдан күрүчеләр бар. Өченчеләр без ишетмәгән тавышларны ишетәләр. Үзләре нинди дер сынау үткән кешеләрдә иң саф мәгълүматлар була. Ванга исемле кыз сукырайса да, күңел күзе күрә торган булып кала. 28 яшьлек Рамил Гарифуллинның эчмәү-тартмавы да юкка гына түгел. Им-томчы әбисенең васыятенә турылыклы ул. Әбисе оста дәвалаучы булу белән бергә, туачак баланың малаймы-кызмы булуын алдан әйтә алган, ул теләгәндә, яңгыр да килеп яуган. Бу төбәктә Рамил халык турында кайгыртучы, бәхетсезлек килгәндә ярдәмчел булуы белән дә танылган.

Рамил гаиләдә алтынчы бала булып туа. Аңа чаклы әнисе биш кыз бала тапкан була. Әбисе 18 яшьлек онытгына – Рамилгә үзендәге биокырны болай тапшыра. Әбисе бер чынаяк суны алдына куеп, тән уртасына чаклы догаларын укый һәм онытгына шушы суны тамчысын да калдырмыйча эчәргә куша. Алар бергә йокларга яталар. Әбекәй шуннан уянмый, ә онытгы мәрткә китә, үзе йоклый, тәнендә температура 41,9 градуска җитә.

Бу исә бирәдә хәлиткеч роль уйный. Күптән түгел расланганча, су – биологик тормышның информацион нигезе. Тик укымышлы булмаган карчык моны ничек белгән? Ничек ул аерым догалары белән суга тереклек программасын салган? Шушы су белән юындырып озаткан биш улы да, яралансалар да, сугыштан исән-сау кайтканнар. Ә менә мәрткә киткән онытгына берничә көн дәвамында югары температура бирдерә алган. Югыйсә тәнендә җылылык аз булса, аны үлгән дип санап, кабергә күмүләре дә ихтимал иде бит. Ә бәлки бу вакытта Рамилнең тәнендә һәм җанында изгелек белән явызлык көрәшкәндер? Изгелек җиңгән булса кирәк. Рамил изге юлда.

Хәер, Рамилгә сирәк очрый торган мондый сәләт тиктомалдан гына килмәгән. Ул Халыкара парапсихология үзәгендә берничә ел дәвамында әзерлек узган. Дөньяның сирәк очрый торган белгечләре сыйфатында ул әлеге үзәкнең әгъзасы да. Югалган әйберләрне табу белән генә чикләнми, дәвалау белән дә шөгыльләнә, өметсез авыруларны аякка бастыра.

Яхшы хәбәрләр бик тиз еракеракларга тарала. Вяткадагы бу тылсым иясе белән дөньяның 20гә якын медицина компаниясе килешү төзегән. Аны әллә кайларга чакыралар, әмма ул Русия мөселманы булып Вятка буенда калуны өстен күрә. Дөресрәге, әнисе – өлкән яшьтәге карчык – Вятка Аланыннан беркая да китәргә теләми. Рамил өлкәннәр сүзеннән чыкмый.

Рамил Гарифуллин менә бер ел инде яхшы җиһазланган "Өмет" парапсихология һәм медицина үзәгенә җитәкчелек итә. Аны оештыруга бирәдәге машина төзү заводы, Киров өлкәсе хакимияте, шәһәр мәриясе ярдәм итте ... бер кертелер. Рамил үзенең эшчәнлек даирәсен киңәйткәннән-киңәйтә. Инде икътисад белән дә шөгыльләнә. Хәзер ул Киров өлкәсендә нефть табуга өметләндерә.

Вера КРАСНОВА.

("Российская газета").

Йолдызнамә

(9-15 февраль)

КУЧКАР *(21.03-20.04). Хезмәтегездә уңышлар юлдаш, тулы аңлашучанлык кичереп яшисез. Унысында эшлекле мөнәсәбәтләр урнашыр, эшкуарлык өлкәсендә яңа мөмкинлекләр ачылыр. 15е көнне яңа проектларга керешү күпкә хәерле. 9,12,13 февральдә бәхәсләрдән, ызгыш-талашлардан сакланыгыз. Сезне бу атнада сәфәр көтә, ул файдалы узар. 11е көнне финанс эшләрендә, акча мәсьәләсендә сак булыгыз.*

ҮГЕЗБОЗАУ *(21.04-21.05). Атна башында хезмәттәшләрегез белән бәхәскә керүдән сакланыгыз. Гаиләгездә иминлек чараларын күрегез. Нигездә бу атна сезгә уңышлар, эшегездә үсеш, төрле эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруда игелек юллый. 12се көнне сез серле көчләр карамагында. Җан теләгән гамәлләрегезне кылыгыз, башкаларга да шәфкатьлелек күрсәтегез.*

ИГЕЗӘКЛӘР *(22.05-21.06). 9,11,12,13,14 февраль – сезнең өчен бик уңайлы көннәр. Күптән хыялланып йөргән эшләрегезгә алыныгыз, яңа проектларга керешегез, үсешкә йөз тотарсыз, чөнки атна дәвамында сез илаһи көчләр карамагында. Тик тирә-юньдәге кешеләргә дә яхшылык эшләргә тырышыгыз. Изге гамәлегез эзсез калмас.*

КЫСЛА *(22.06-22.07). Бәхәсле минутлар килеп чыкса да, сез атнаның бәхетле кешесе. Эшлекле элемтәләр урнаштырасыз, акча керә, зур үсеш кичерәсез. Рухи ихтыяҗыгыз илаһи серле көчләр белән тулылана, һәм сезгә җиңеллек, авыр хисләрдән, хәсрәтле кичерешләрдән арыну килә.*

АРЫСЛАН *(23.07-23.08). Атна башында матди югалту булса да, 14е көнне сезгә мул табыш керәчәк. 11е көнне эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыру бик уңайлы нәтиҗәләр бирәчәк. 9 февральдә акча югалтудан сакланыгыз. 10ы көнне юл йөргәндә, транспортта, эштә бәхетсезлекләр, җәрәхәт алудан сакланыгыз. 14е көнне тирә-юньдәге кешеләр белән бәхәскә кермәскә тырышыгыз.*

КЫЗ *(24.08-23.09). Бу атна сездән сабырлык, игътибарлы булуны таләп итәчәк. 11,14е көннәрендә яңа эшләр башламагыз, гадәти шөгыль белән үткәрегез, гаиләдәге вак-төяк мәшәкатьләрне үз өстегезгә алыгыз. 15е көнне акча мәсьәләсендә сакчыллык күрсәтегез, финанс язуларына кул куярга ашыкмагыз, чөнки үзегезгә зыян килүе бар.*

ҮЛЧӘҮ *(24.09-23.10). Сез атна дәвамында эшлекле партнерлар эзлисез һәм үзара мөнәсәбәтләр урнаштырасыз. Шул максаттан юлга чыгасыз, сөйләшүләр алып барасыз һәм ныклы, ышанычлы эшлекле мөнәсәбәт урнаштырасыз. 10, 15е көннәрендә көтелмәгән вакыйгалар шаһиты булуыгыз ихтимал. Ямьсез, күңелсез күренешләрне читләтеп үтәргә тырышыгыз.*

ЧАЯН *(24.10-22.11). 9,10,12,13 февраль – сезнең өчен уңышлы көннәр. Юлга чыгарсыз, дусларыгызны, туганнарыгызны очратырсыз, рухи канәгатьләнү кичерерсез. 13е көнне акчагызны әрәм-шәрәм итүдән, югалтудан саклагыз.*

УКЧЫ *(23.11-21.12). Сез үсеш юлында. Тагын да дәрәҗәлерәк эшкә күтәрелерсез. Юлга чыгарсыз, эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырырсыз. Ләкин сез рухи канәгатьләнү кичермисез, төшенкелек биләп тора. Кешеләргә күңел җылысын бирегез, җавабын да алырсыз һәм рухи үсеш тоярсыз.*

КӘҖӘМӨГЕЗ *(22.12-20.01). Атна башында урнаштырган эшлекле элемтәләрегез бәхәс тудырса да, соңыннан ул үз нәтиҗәсен китерер. 12се көнне тагын ды зур хезмәттәшлеккә керешә аласыз, эшегез уңар. 13,14е көнне күңелсез хәлләрне, бәхетсезлек очракларын читләтеп үтәргә тырышыгыз, сакланыгыз. Атна ахырында сезне сәфәр көтә.*

СУКОЯР *(21.01-19.02). Атнаның биш көне сезнең өчен бик уңышлы. Гаиләдә, эштә тулы иминлек, бәхетле минутлар кичерерсез. 11е көнне яңа башлангычларга керешмәгез. 14е көнне бәхетсезлекләрдән сакланыгыз: эштә, юлда кагыйдәләрне төгәл үтәгез.*

БАЛЫК *(20.02-20.03). Гаҗәп уңышлы атна. Илаһи көчләр сезнең карамакта. 11,13е көнне финанс мәсьәләләрендә, эшлекле килешүләр урнаштыруда игътибарлы булыгыз.*

Менә сиңа "табиб!"

Мәскәүдә Софья Ковалевская урамында яшәүче имче-табибка (целитель) бала табудан мәхрүм бер хатын дәваланырга йөри. Үткән атнада ул яңадан "сеанс" алыр өчен "табибка" килә. Үзе белән 2 мең доллар акчасы да була. Акча барын белгәч, "табиб", хатынны башына кирпеч белән сугып үтерә дә, үзе юкка чыга. Милиция бу вакыйганы тикшерү вакытында менә нәрсәләр ача: 22 яшьлек хатын, күпме дәваланса да, балага уза алмый. 19 яшьлек беркайда да эшләмәүче Некрасов дигән егет, танышларыннан бу турыда ишеткәч, үзен бу ханым белән таныштыруларын сорый. Аны "экстрасенс" дип элеге хатын белән таныштыралар: янәсе, ул халык медицинасын кулланып дәвалый. Беренче сеанс өчен хатын 300 доллар китерә, сумкасыннан акча алганда, "табиб" аның калган долларларын да күреп ала. Хатынны яткырып, эченә җылы кирпеч куя. Һәм шул кирпеч белән башына сугып үтерә. Милиция аны әти-әнисе фатирында кулга алды.

Жириновскийның исерек ярдәмчесе милиция хезмәткәрен үтерә

Мәскәүдә эре машина һәлакәте булды: Садово-Самотечная эстакадасында берьюлы 5 машина бәрелеште. Нәтиҗәдә, эш урынында үз вазифаларын үтәгән милиция капитаны һәлак булды, 5 кеше тән җәрәхәте алды. Бу һәлакәтнең сәбәпчесе Жириновскийның ярдәмчесе Иван Теологов булып чыкты. Лаякыл исерек депутат ярдәмчесе, әр-яңа "Мазда-626" машинасына утырып, югары тизлектә Садово-Самотечная буйлап чаба. Машинада аның ике өшнәсе дә була. Исерек Теологов, машинасын тыя алмыйча, каршы юлга килеп керә һәм РУВД оператив идарәсе бүлек начальнигы, милиция капитаны Довиденконың "Жигули"ена килеп бәрелә. Капитан һәлак була. Күз ачып йомганчы ике машина җимерекләре өстенә "Ауди", "девятка" һәм "семерка" машиналары килеп менә. Теологов авыр хәлдә хастаханәгә озатыла.

("МК").

Примаков "Мерседес"ына "Джип" бәрелә, Кириенко "Волга"сына– "Жигули" гына

Тышкы эшләр министры Е.Примаковны йөртә торган "Мерседес-280"гә "Садовое" боҗрасын узганда "Чероки" джип машинасы килеп бәрелә, чөнки "Мерседес" кызыл утка кереп чыга. Министр, бәхетенә,машинада булмый. Шул ук көнне ягулык һәм энергетика министры С.Кириенко да, журналистлар белән матбугат конференциясе үткәреп чыккач, "Волга"сына утырып Ленин проспекты буйлап китә. Аңа җиденче модельле "Жигули" килеп бәрелә. С.Кириенконың үзенә берни дә булмый, машинасы зарарлана. Министр башка машинада юлын дәвам итә.

Чукчаларны чит ил кешеләренә күрсәтмиләр

Чукчалар тормышын аларның үз территориясендә өйрәнү моннан соң күп чит ил галимнәренә мөмкин булмаячак. Мәскәүдә урнашкан Чукот автономия округы илчелеге (представительство) хәбәр итүенчә , Русия хөкүмәте карары нигезендә, чит ил гражданнарына сайлап кына күрсәтеләсе территорияләр исемлеге төзелгән. Хәзер чит ил галимнәре, чукчаларны өйрәнергә барганда, Федераль миграция хезмәте һәм Чукотка җирле администрациясеннән рөхсәт алырга мәҗбүр булачак.

("КП").

Аста – гараж, өстә – бию мәйданы

"Оримэкс" фирмасы Казан шәһәрен автомобильләштерүгә үз өлешен кертте. Киров урамында төрек төзүчеләре көче белән җир астында 99 урынлы автостоянкасы булган машиналарга ягулык салу (автозаправка) станциясе төзелеп, шушы елның 14 гыйнварында гамәлгә керде. Бу автостоянка – киләчәктә, 2000 ел башында төзеләчәк мәдәният – ял итү үзәгенең чираттагы корылмасы.

Тәкъдим итү (презентация) вакытында автостоянкада итальян машиналар юу җайланмасында машина юып күрсәттеләр. Машина бер-ике минут эчендә ялт итә, ләкин бәясе "тешли".

Шушында ук эшләргә тиешле машинага ягулык салу станциясе дә, (ул финн проекты белән Эстониядә ясалган), кайбер приборларының төзек булмавы сәбәпле, әлегә үз вазифаларын башкара алмады. Моннан башка җитешсезлекләр дә килеп чыга тора: мәсәлән, туалет һәм душ кабиналарына тиешле краннарны урнаштыргач, краннардан кайнар су килмәве ачыкланды. Төркия климатында салкын су да ярыйдыр, ә безнең климатта кайнар су булу мәҗбүри. Проектны төзәтү мөмкинлеге булмаганга, төзүчеләргә ашыгыч рәвештә 60 литрга исәпләнгән электр белән су җылыту җайланмасы куярга туры килде. Әлбәттә, әле бу гына кайнар суга булган ихтыяҗны тиешенчә тәэмин итми. Капкаларның да ышанычлы ябылмавы беленде, бу дефектны да тиз арада төзәтергә туры килде.

Автостоянка киләчәктә күтәреләсе мәдәният – ял үзәгенең беренче эре обьекты. Аны "ТАИФ" акционерлык җәмгыяте коммерция акчасына (шәһәр бюджетыннан түгел) төзи. Бу эре комплексны төзү идеясе, аның концепциясе – яшь бизнесмен, төзүче-инженер Радик Шәймиевнеке. Проект авторлары – архитекторлар Гөлсинә һәм Виктор Токаревлар.

Бу автостоянка һәм ягулык салу станциясен эксплуатацияләүне "ТАИФ" (татар-американ инвестицияләре һәм финанслары) фирмасы үз өстенә ала. Ләкин әле шундый шик тә бар: Казан Үзәк универсаль кибете (ЦУМ) һәм киләчәктә төзеләсе ял итү үзәге янында (анда бүген дә машина куяр урын җитәрлек), шундый эре корылма төзелү икътисади яктан үз кыйммәтен аклар микән? Казан шәһәре тарихи үзәгендәге архитектура ансамблен бу корылма ямьсезләп тормасмы? Янындагы тарихи биналарны капламасмы? Һәрхәлдә, бу проект шәһәр төзү Советында (градостроительный Совет) уңышлы расланган.

("МК").

"Иномарка" алу хәтәр

Клайпеда шәһәрендә яшәүче чит ил маркалы машина хуҗалары тәмам куркуга төште. Төннәрен кемдер кыйммәтле машиналарны яндырып яки шартлатып йөри. Үткән атнада гына төрле автостоянкаларда торган япон "Джип"ы һәм "Фольксваген-Пассат" машиналары шартлатылды. Соңгысы шулкадәр каты шартлады ки, ватыклары күрше машиналарга төшеп, аларны да зарарлады. Бер-ике көн элек кенә бер-бер артлы дүрт әр-яңа "Опель", "Форд Мондео", "Фольксваген Гольф" һәм "Хюндай Лантра" яндырылган иде. Машиналарның барысы да 1996-1997 елларда чыгарылган. Литва МВДсы хәбәр итүенчә, монда берничә версия бар: яки бу мафиоз сугыш нәтиҗәсе, яки берәр тиле күңел ача, йә булмаса көнчелек үче.

("ВК").

Озын гомерле Мияубикәләр

Англиядә ике озын гомерле мәче яшәве турында "Биополис" журналы яза. Китти исемле мәче 32 яшендә үлә. Киттидән 218 мәче баласы туа, соңгы тапкыр үләренә 2 ел кала бәбиләр таба. Датси исемле мәче Техаста (АКШ) 17 яшендә үлә. Үз гомерендә 420 песи баласы китерә. Икенче бер Мияубикә – Көньяк Америкада яшәүче Блюбел исемле фарсы мәчесе берьюлы 14 бәби алып кайта. Бу – үзенә күрә рекорд.

Ата мәчеләрнең тормышы катлаулырак булса да, алар арасында да озын гомерлеләр очрый. Англиядә яшәгән Пусс исемле ата мәче 36 яшькә кадәр җиткән.

("Мир новостей").

(Л.Г).

Бөгелмә чүлгә күчтеме?

Үткән атнада Татарстанның көньягында урнашкан Бөгелмә шәһәре бер тамчы сусыз кала язды. "ЧП"дан котылу өчен җирле хакимият башлыгы хәтта махсус комиссия төзеде. Бәхеткә, мондый хәл террористлар белән бәйле түгел иде, Зәй – Каратай бистәсе янында, (Лениногорскидан 10 чакрымда) Лениногорски – Әлмәт суүткәргечендә өзеклек барлыкка килеп, су басымы түбәнәйгән булып чыкты. Ләкин бөгелмәлеләр бу хәлләрдән хәбәрдар түгел иде, шәһәргә сусызлык янавын алар авария тәмамлангач кына белделәр. Ремонт белән шөгыльләнгән арада, шәһәр хакимияте, 13 автомашина җибәреп, халыкны су белән тәэмин итүне оештырды. Бер көн эчендә ремонт тәмамланды һәм су өзеклеге бетте.

Дүрт пычак ярасыннан

Казан шәһәренең Яңа Савин районындагы бер гаиләдә тавыш чыга. Ир кеше хатынының "авырткан җиренә" тия. Хатын, ярсып, күкрәгенә һәм эченә дүрт мәртәбә пычак белән кадап, ирен үтерә. Ул аннан 10 яшькә өлкәнрәк һәм медицина хезмәткәре була. Хикмәт бәлки яшь аермасындадыр?

Татар энциклопедиясе битләреннән

ӘБЕЛ-ГАЗЫЙ Баһадур *хан (1603-63), Хива ханы, тарихчы. "Төрекмән Шәҗәрәләре", "Төрекләр шәҗәрәсе" – безгә мәгълүм хезмәтләре.*

ӘБЕЛХӘЕР *(XIX йөзнең икенче яртысы), шагыйрь. Хезмәте: "Кәза китабы мәснәви". (1882. Казан). Тормыш юлы һәм иҗаты аз өйрәнелгән.*

ӘБҖӘЛИЛОВ Хәлил Гали улы *(1896-1963), театр һәм кино актеры, педагог. ТАССР, РСФСР, СССРның халык артисты (1944, 1950, 1957). Ырынбур өлкәсе Мостафа авылында туган. 1916 елда "Ширкәт" труппасында сәхнә эшчәнлеген башлый. 1919 елда Ырынбурда "Көнчыгыш театры" оештыра. Ташкент киностудиясендә фильмнарда (1924-28) катнаша. 1928 елдан Татар академия театрында актер. Татар театрында Станиславскийның алдынгы тәҗрибәсен үзләштерә. Г.Камалның "Банкрот", М.Горькийның "Дошманнар", Т.Гыйззәтнең "Ташкыннар", В.Шекспирның "Король Лир", Н.Исәнбәт әсәрләрендә Сираҗетдин, Яков Бардин, Биктимер, Лир, Хуҗа Насретдин рольләрен башкара. К.Тинчуринның "Җилкәнсезләр"ендә Мисбах роле өчен 1958 елда ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелә. Бөтенсоюз театр эшлеклеләренең Татарстан бүлеге рәисе (1941-53), ТАССРның Югары Советы депутаты (1947-59).*

ӘБЛИЕВ Мөхәммәт Шәриф улы *(1900-41) драматург. Иҗаты: "Шәмсекамәр" драмасы (1938), повесть, хикәяләр авторы. Бөек Ватан сугышында һәлак була.*

ӘБРАРОВ Раил Нурали улы *(1937 елда туган), 1978 елдан генерал-майор. 1975-80 елларда Беларусь хәрби округында танк, мотоукчылар берләшмәләрендә, Ерак Көнчыгыш армия берләшмәсендә командир. 1984 елдан М.Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең җитәкчесе урынбасары, көллият мөдире, кафедра мөдире урынбасары.*

ӘПСӘЛӘМОВ Мифтах Шаһи улы *(1894-1927), актер. 1919 елда Орскида сәхнә эшчәнлеген башлый. 1922 елдан Татар академия театрында. М.Фәйзинең "Галиябану", Н.Исәнбәтнең "Качаклар", А.Толстойның "Иоанн Грозный үлеме" сәхнә әсәрләрендә Бәдри, Гайнетдин мулла, Иоанн Грозный рольләрен башкара. 1926 елда "Хезмәт батыры" исеме бирелә.*

ӘБҮ-БӘКЕР Әхмәт улы *(XII йөз), бакырчы, болгар остазы. Биләр шәһәре табылдыклары арасындагы йозакта 1146-47 ел белән аның исеме бирелгән.*

ӘБҮ-МӨХӘММӘД садр ибне Галәэддин әл-БОЛГАРИ *(XIY йөз), Болгар галиме.*

ӘБҮ-Л Галә Хәмид бине Идрис әл-БОЛГАРИ *(XII йөз), Болгардагы дин эшлеклесе һәм галим.*

ӘБҮБӘКЕРОВ Фуат Хәмит улы *(1944 елда туган), дирижер, Татарстанның халык артисты (1996).*

ӘБҮЛМӘМБӘТОВ Роберт Шәрифҗан улы *(1942 елда туган), актер, театр эшен оештыручы, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

ӘБҮЗӘРОВ Разак Габдрахман улы *(1932 елда туган), педагог, педагогия фәннәре докторы, профессор (1985). 1970 елдан Урал гуманитар университетында укытучы, урыс теле методикасы кафедрасы мөдире. Хезмәте: милли мәктәптә урыс теле укыту.*

ТӨЗӘТҮ. 5 нче санда басылган шушы баганада Гакыйл Атласов урынына Ашмасов дип, үлгән елын 1942 дип укырга.

Атналык манзара

Дүшәмбе
9 ФЕВРАЛЬ
"ТАТАРСТАН"

7.00-8.00 "Чулпан".
17.55 Балалар өчен "Тамчы".
18.10 "Эшмәкәрлек телевидениесе".
18.45, 20.45 "Җиһан". Хәбәрләр.
19.00 "Замандаш" циклыннан. "Үрмәле талларым".
19.45 Яңалыклар.
20.00 "... белән әңгәмә". ТР Премьер-министры Ф.Мөхәммәтшин.
20.30 "Әлли-бәлли-бәү".
21.00 "РАБА ЛЮБВИ". (21.45 – "Яңалыклар").

"ЭФИР"

6.00, 11.30, 14.10 Музыкага чикләр юк.
6.15 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
6.45 "Республика" информацион-аналитик программасы.
7.20 Информацион-күңел ачу программасы: "Уян һәм жырла!".
8.45 "ПИРАТЫ XX ВЕКА".
10.40 "ВАВИЛОН-5".
11.45, 14.45 "Даруханә".
12.00, 15.00 "ТСН-6".
12.10 "НИЧЕГО СВЯТОГО".
13.40 Тамаша залы.
15.10 "Я СЛЕДОВАТЕЛЬ...".
16.40 Мультфильм.
17.00, 19.30, 22.10 "Шәһәр" информацион программасы.
17.15 И.Демидов шоуы: "Күзәтү".
18.20 "ВАВИЛОН-5".
19.10 Мультфильм.
20.00 "ДОЖИВЕМ ДО ПОНЕДЕЛЬНИКА".
22.40 Юл патруле.
23.00 "НИЧЕГО СВЯТОГО".

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 "Хәерле иртә!"
9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.30 Яңалыклар.
9.15 "РОКОВОЕ НАСЛЕДСТВО".
10.00 XYIII кышкы Олимпия уеннары. Биатлон. 15 чакрым. Хатын-кызлар. Чана. Ирләр. Наганодан тапшыру.
12.15 "Бергә".
13.05 "ДЕЛО БЫЛО В ПЕНЬКОВЕ".
15.20 Мультсериал: "Розовая пантера".
15.45 "Марафон-15".
16.05 "Йолдызлар сәгате".
16.40 "НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ РОБИН ГУДА".
17.10 XYIII кышкы Олимпия уеннары. Чана. Ирләр. Наганодан тапшыру.
18.20 Сериал: "РОКОВОЕ НАСЛЕДСТВО".
19.05 "Җавап тотар чак".
19.30 Телеуен: "Бу көйне беләсеңме?"
20.00 "Без".
20.45 "Тыныч йокы, нәниләр".
21.00 "Вакыт".
21.40 "ПОЛТЕРГЕЙСТ".
22.45 "Хоккей һәм тәмамланмаган роман". "Хатын-кызлар тарихлары" программасында Т.Буре.
23.15 Биатлон. 15 чакрым.
0.50 "ГЛАВНЫЙ ПОДОЗРЕВАЕМЫЙ".

"РУСИЯ"

7.00 Мультфильм.
7.10 Православие календаре.
7.15 "Уян!".
7.30, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.30 Хәбәрләр.
8.00, 1.05 Кизү бүлеге.
8.10 Почта аша әйберләр.
8.15 "Стронг" тәкъдим итә.
8.20 "Хәтер өчен".
8.25 Кышкы Олимпия уеннарында. Чаңгы. Ирләр. 30 чакрым.
10.00 "ГРАФИНЯ ДЕ МОНСОРО".
11.35 "Аншлаг" и Ко.
12.30 Кышкы Олимпия уеннарында. Тау чаңгылары. Сноуборд. Тимераяк. Ирләр.
14.30 "ГОРЕЦ".
16.00 Графоман.
16.10 Акчалар.
16.30 "МАЛЕНЬКИЙ БРОДЯГА".
17.30 Кроссворд.
